# КИТАПХАНӘ ХӘБӘРЛӘРЕ

Фәнни-гамәли журнал

Научно-практический журнал

# БИБЛИОТЕЧНЫЙ ВЕСТНИК

2 (50) 2020





МӨСЛИМ районы Татарстан Республикасының көнчыгыш өлешендә урнашкан. Гаҗәеп матур, игелекле һәм уңган төбәк. Биредә бер генә тапкыр булса да булып киткән һәр кеше кунакчыллык һәм игелеклелекне, районның үзенчәлекле, җылы атмосферасын беркайчан да онытмаячак. Боларның барысын да биредә яшәүче халык тудыра. Мөслим җире гореф-гадәтләрне сакларга һәм шул ук вакытта заман белән бергә атларга сәләтле кешеләре белән дан тота. Аларның тырышлыгы белән район зур бистә буларак чәчәк атты. Ул үзенең данлыклы шәхесләрен саклап, республикабызга – аның иминлегенә кулдан килгәнчә өлеш кертә.

Мөслим районы мәдәният оешмалары структурасына биш мәдәният оешмасы керә: «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе, «Үзәкләштерелгән китапханә» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе, халыкка кино хезмәте күрсәтү буенча муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе, «Мөслим туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе, Мөслим балалар сәнгать мәктәбе.«Үзәкләштерелгән китапханә» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе 29 китапханәне берләштерә: үзәк, үзәк балалар китапханәләре һәм 27 авыл бүлекчәсе.

Район китапханәләре хезмәт күрсәтү зонасында 19 002 мең кеше яши. Район үзәгендә урта мәктәп, лицей, гимназия, «Мизгел» яшьләр үзәге, балалар сәнгать мәктәбе, Мөслим политехника техникумы, балалар иҗаты үзәге, спорт мәктәбе урнашкан. Район буенча барлыгы 3 башлангыч, 11 тугызъеллык, 6 урта белем бирү мәктәбе, 10 балалар бакчасы һәм мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен интернат-мәктәп бар.

МУСЛЮМОВСКИЙ район расположен в восточной части Республики Татарстан. Удивительно живописный, благодатный и гостеприимный край. Каждый, побывавший здесь хотя бы раз, никогда не забудет атмосферы радушия и добра, особой, тёплой ауры района, которую создают прежде всего её коренные жители. Муслюмовская земля славится щедро одарёнными, способными сохранять традиции и в то же время идти в ногу со временем людьми. Их усилиями этот край движется к процветанию, сохраняя свою индивидуальность, органично вливается в целое – нашу Республику Татарстан, – внося свой посильный вклад в её благополучие.

В структуру учреждений культуры Муслюмовского района входят пять учреждений культуры: Централизованная библиотека, Районный дом культуры, Муслюмовский краеведческий музей, Муслюмовская детская школа искусств и МБУК по киновидеообслуживанию населения.

Муниципальное бюджетное учреждение культуры «Централизованная библиотека» объединяет 29 библиотек: центральную, центральную детскую и 27 сельских.

В зоне обслуживания библиотек района более 19-ти тыс. человек. В районном центре расположены средняя образовательная школа, лицей, гимназия, молодёжный центр «Мизгел», детская школа искусств, Муслюмовский политехнический техникум, центр детского творчества, спортивная школа. Всего по району 3 начальных, 11девятилетних, 6 средних образовательных школ, 10 детских садов и школа-интернат для детей с ограниченными возможностями здоровья.

БУ САНДА:

В НОМЕРЕ:

**Татарстан китапханәләре: Мөслим • Библиотеки Татарстана: Муслюмовский район**

*Р. Муллин.* Хөрмәткә лаеклы хезмәт ....2
*Р. Муллин.* Труд достойный уважения ....2
*И. Салихҗанов.* Рухи мирасыбыз югалмый ....3
*А. Мадьярова.* Үткәннәрне барлап, киләчәккә карап....4
*А. Мадьярова.* Анализируя прошлое, с надеждой на будущее ....4
*Д. Кашапова.* Мөслим район үзәк китапханәсе тарихы битләреннән ....8
*Д. Кашапова.* Заманча китапханә: үсеш юллары ....14
*А. Мадьярова.* Проектная деятельность библиотек ....18
*Л. Садриева.* Шигырь ....22
*З. Кашапова.* Үзәк балалар китапханәсе тарихын барлау юлында ....22
*Д. Кашапова.* Күпкырлы талант иясе ....25
*Д. Кашапова.* Обладатель многогранного таланта ....25
*А. Романова.* Яңару юлында....30
*Ф. Садриев.* Китапханәче җаваплылыгы ....32
*Г. Мәүлиева-Шәмси.* Эшкә куанып бару – бәхет ул! ....35

**Татарстан Республикасының Милли китапханәсе • Национальная библиотека Республики Татарстан**

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең яңартылган бинасы ....37
Обновленная Национальная библиотека Татарстана ....37

**Истәлекле даталар • Знаменательные даты**

*М. Ибрагимов.* «Ты для того лишь и пришёл в наш мир, чтобы в своём народе стать поэтом»: к 120-лет со дня рождения Хасана Туфана....42
М. Ибрагимов. Заговорили ивы по-татарски…» ....45

**Татарстан АССР оешуга 100 ел • 100 лет образования Татарской АССР**

*К. Фатхеева.* Мероприятия Республиканской библиотеки Татарии им. В. И. Ленина к дням XXV-летия Татарской АССР в год великой Победы ....48

**Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә – 155 ел • Национальной библиотеке 155 лет**

*Р. Елизарова.* Рассказывают протоколы партийных собраний ....52

**Республика китапханәләрендә • В библиотеках республики**

*Г. Фахруллина, Г. Хәмидуллина.* Буыннарны тоташтыра китап....57

**Актуаль тема • Актуальная тема**

*Г. Аюпова, Н. Валиахметова.* Как мы работаем в сети. Национальная библиотека Республики Татарстаи и Интернет ....68
*Л. Хәмидуллин.* Китапсыз дөнья сансыз....70

**Мирас • Наследие**

*Р. Мәрданов.* Сугыш хатлары ....73
*И. Мөстәкыймов.* «Әхмәт мирза кире кайткан, ислам динен сагынып» ....77

**Социологик тикшеренүләр • В ракурсе социологии**

*Э. Хусаинова.* Структура чтения пользователей библиотек Татарстана....79

**Эш тәҗрибәсе • Опыт работы**

*Н. Клдрова.* Как организовать файндрайзинговую компанию: из опыта работы ....82

**Һөнәрдәшләребездә • У наших коллег**

*Г. Хәсәенова.* «Китап апай» ....84

**Татарстан китапханәләре хакында вакытлы матбугат • О библиотеках Татарстана в периодической печати** ....85

**Вакыт-вакыйга • Хроника**

Милли китапханә тарихы – яңа китапларда....90
Вехи истории Национальной библиотеки Республики Татарстан ....91
«Мәдәният» илкүләм проекты. Татарстанның Биектау районында модель китапханә ачылды ....92
Национальный проект «Культура». Открылась модельная библиотека в Высокогорском муниципальном районе Татарстана....93
Кукмараның капиталь төзекләндерелгән Үзәк китапханәсе кабат ишекләрен ачты....94
В Кукморе после капитального ремонта открылась Центральная библиотека ....95
Китапханәгә кыйммәтле бүләк ....96
Бесценный дар....96

КИТАПХАНӘ ХӘБӘРЛӘРЕ

№ 2 (50) 2020

ФӘННИ-ГАМӘЛИ ЖУРНАЛ

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе тарафыннан 1996 елның май аеннан башлап нәшер ителә. Елга 2 тапкыр татар һәм рус телләрендә чыгарыла.

Баш мөхәррир
Р. И. Вәлиев

Редколлегия:
М. Ф. Тимерҗанова,
И. Г. Һадиев, Ә. Х. Мушинский (баш мөхәррир урынбасарлары),
Р. Ә. Хөсәенова (җаваплы сәркятиб),
А. Р. Габделхакова,
А. Җ. Заһидуллин

БИБЛИОТЕЧНЫЙ ВЕСТНИК

№ 2 (50) 2020

НАУЧНО-ПРАКТИЧЕСКИЙ ЖУРНАЛ

Издается Национальной библиотекой Республики Татарстан с мая 1996 года. Выходит 2 раза в год на татарском и русском языках.

Главный редактор
Р. И. Валеев

Редколлегия:
М. Ф. Тимерзянова,
И. Г. Хадиев, А. Х. Мушинский (заместители главного редактора),
Р. А. Хусаинова (ответ. секретарь),
А. Р. Абдулхакова,
А. З. Загидуллин

**_Рамил МУЛЛИН,_**
_ТР Мөслим муниципаль районы башлыгы_

**_Рамиль МУЛЛИН,_**
_глава Муслюмовского муниципального района РТ_

# Хөрмәткә лаеклы хезмәт

ҺӘР нәрсәнең үз башлангычы, үз тарихы бар. Беренче язмалар, китаплар барлыкка килү, кешеләрдә әкренләп ул китапларны уку, файдалану ихтыяжы үсү китапханәләрне барлыкка китергән. Китапханәләрдә бәяләп бетергесез байлык тупланган. Сүз матди байлык турында гына бармый, ә рухи, тарихи байлык, халкыбызның мәдәният үсеше ядкарьләре турында бара. Китапханәләр безне – китап укучыларны әнә шул тарихи һәм мәдәни байлыкка якынайталар, күз карасыдай саклап буыннан-буынга тапшыралар, аң-белем тараталар, тарихи истәлекләрне барлыйлар.

Мөслим муниципаль районындагы беренче китапханә тарихы район төзелгән1930 нчы елдан башлана. Яңа тормыш төзү идеяләре, наданлыкны бетерүгә юнәлдерелгән илкүләм чаралар, халыкның белемгә омтылуы, китап укучылар санының елдан-ел күпләп артуына китерә, бу үз чиратында китапханәләр челтәрен үстерергә мөмкинлек бирә. Район китапханәләре 90 ел эчендә күп үзгәрешләр кичерә. Бу үзгәрешләр аларның заманча биналарга урнашуы, җиһазлар белән тәэмин ителүләрендә, китаплар, вакытлы матбугат фонды арту, халыкка хезмәт күрсәтү өчен шартларның яхшыруы, формасы, сыйфаты күтәрелүдә чагыла. Мин районда яшәүчеләрнең китапка тартылуы, китапханәләргә йөрүләрендә китапханәчеләрнең һөнәри осталыгы, үз эшенә җаны-тәне белән бирелгән булуы зур роль уйный дип саныйм. Бәхеткә каршы, андый китапханәчеләребезне буыннан-буынга күпләп атарга мөмкинлегебез бар.

Китапханәләрнең эшчәнлеге, илдә барган сәяси, икътисади үзгәрешләр белән тыгыз бәйләнгән. Китапханәләр заманча технологияләр белән бер адымда атлыйлар. Районыбыз китапханәчеләренә ныклы сәламәтлек, матур әдәбиятны таратуда, халыкның рухи үсешен тәэмин итүдә уңышлар, китапханәче һөнәренә тугры калып, халыкка армый-талмый хезмәт итүләрен телим.



# Труд достойный уважения

_ВСЁ имеет своё начало, свою историю. Появление первых письменностей, книг, постепенное развитие у людей потребности в чтении и использовании этих книг привело к созданию библиотек. В библиотеках накопилось бесценное богатство. Речь идёт не только о материальном богатстве, но и о духовном, историческом богатстве, памятниках культурного развития нашего народа. Библиотеки приближают нас, читателей, к этому историческому и культурному богатству, передают его из поколения в поколение, распространяют знания, хранят исторические воспоминания._

_История первой библиотеки в Муслюмовском муниципальном районе начинается с 1930-х годов, когда и был создан район. Идея построения новой жизни, меры, направленные на ликвидацию неграмотности, стремление населения к знаниям, приводят к тому, что с каждым годом увеличивается количество читателей, что, в свою очередь, позволяет развивать у нас сеть библиотек. За девяносто лет районные библиотеки претерпели много изменений. Эти изменения отражаются на их расположении в современных зданиях, оснащении оборудованием, увеличении фонда книг, периодической печати, улучшении_

***Ирек САЛИХҖАНОВ,***
*ТР Мөслим муниципаль районы мәдәният бүлеге җитәкчесе*

# Рухи мирасыбыз югалмый

КИТАПХАНӘ – ул мәгълүмат чыганагы гына түгел, ә бәлки тарихи ядкарьләр, аң-белем хәзинәсе, кешелекнең гасырлар буена тупланган хәтере. Үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк, ә тарих – ул китап киштәләрендә, китап битләрендә саклана.

Нәкъ менә китапханәләрнең, халыкны агарту, заманга лаек булырга сәләтле шәхесләр тәрбияләү кебек мөһим эш башкарулары, җәмгыятьтә аларның тоткан урынын билгели.

Район мәдәният бүлегенең бер тармагы булган китапханәләр эшчәнлеге безнең һәрчак күз уңында. Бүгенге көндә районыбыз халкына Мөслим үзәк китапханәсе, үзәк балалар китапханәсе һәм 27 авыл китапханәсе намуслы хезмәт күрсәтә. Сер түгел, дөньяда яңа технологияләр өстенлек иткән заманда, укучыны китапханәләргә җәлеп итү җиңел эш түгел, бу хәл китапханәчеләр алдында торган җаваплылыкны икеләтә арттыра. Замана таләбенә яраклашу, аның белән бергә атлау өчен, китапханәләр эшчәнлегендә яңа технологияләр кулланып, яңа форматта эшләү үзбурыч булып тора. Халыкка китапханә хезмәте күрсәтүнең формасын һәм методларын камилләштерү, сыйфатын күтәрү, китап фондларын тулыландыру, китап укучылар белән төрле мавыктыргыч чаралар үткәрү белән бергә китапханә хезмәткәрләре ел саен Россиякүләм, регионара, республика тарафыннан оештырылган төрле бәйгеләрдә актив катнашып, зур уңышлар яулап киләләр. Кызганыч, китапханәчене китап киштәләре арасында кул кушырып



утыручы дип кенә кабул итүчеләр дә юк түгел. Бу – зур ялгышлык! Киресенчә, бүгенге көндә китапханә тормышы яңа аерткан умарта күчен хәтерләтә дияр идем. Агымдагы бетмәс-төкәнмәс рәсми документ эшләреннән тыш, аларның хезмәте бит әле иҗат белән бергә үрелеп тә бара. Район китапханәләрендә әледән-әле оештырылып торган әдәби кичәләр, фестивальләр, бәйге-конкурслар, әдәби проектлар, интеллектуаль һәм квестуеннар, китапханәчеләр хезмәтенең иҗаттан аерылгысыз булуын сөйли. Китапханә хезмәткәрләре район үзәгеннән тыш, авыл җирлекләрендәге мәдәният йортлары, мәктәпләр белән хезмәттәшлек итәләр, җәмәгать эшләрендә, район күләмендә үткәрелгән чараларда актив катнашып, алгы позицияләрдә баралар. Горурланып әйтәм: «Үзәкләштерелгән китапханә» коллективында иң кыю максатларны да тормышка ашырырлык кызлар эшли. Җәмгыятебезнең рухи халәтен агартудагы уңышлары, тырыш хезмәтләре өчен рәхмәт аларга!

*Библиотека – это не только источник информации, но и историческое наследие, сокровище знаний, память, сохранившаяся веками. Нет будущего у того, кто не знает и не помнит свое прошлое. А наша история хранится именно в книгах.*

*В нашем районе работают Муслюмовская Центральная библиотека, Центральная детская библиотека и 27 сельских библиотек. В современном мире нелегко првлечь людей в библиотеку. Для того, чтобы шагать вместе со временем, мы ищем новые форматы работы, внедряем новые технологии в библиотечную деятельность, проводим интересные и увлекательные мероприятия. Наша цель – просвещение народа.*

*условий для обслуживания населения. Я считаю, что большую роль в привлечении жителей района к чтению, посещении библиотек играет профессионализм библиотекарей, преданность своему делу. К счастью, у нас есть возможность назвать таких библиотекарей из поколения в поколение.*

*Деятельность библиотек тесно связана с общественно-политическими, экономическими изменениями, происходящими в стране. Библиотеки шагают в ногу с современными технологиями. Желаю библиотекарям района крепкого здоровья, успехов в распространении знаний, в обеспечении духовного роста населения, верности профессии библиотекаря, неустанной службы народу!*

*Айсылу МАДЬЯРОВА,*
*«Үзәкләштерелгән китапханә» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры*

*Айсылу МАДЬЯРОВА,*
*директор муниципального бюджетного учреждения культуры «Централизованная библиотека»*



# Үткәннәрне барлап, киләчәккә карап

КИТАП – кешелек тарихының барлыкка килүеннән башлап гасырлар буе тупланган хәтере, халыкның мәдәни үсеш күрсәткече, рухи дөньясының көзгесе. Китапханәчеләр исә киңкырлы иҗат эшчәнлеге аша халкыбызның тарихи истәлекләрен җыеп, саклап, буыннан-буынга җиткерүчеләр.

Китапханәләрнең тарихы, үсеш дәрәҗәсе дә илдәге вакыйгалар, үзгәрешләр белән тыгыз үрелеп бара. Аларның да үз тарихы, үз кыйбласы, үзләренә генә хас эш юнәлеше бар һәм ул һәр төбәк тарихының аерылгысыз бер мөһим тармагы.

Тарих битләренә күз салсак, китапханәләр«кызыл почмак», «уку йортлары»ннан башлап үзләренең укучылары белән бергә үсеп,заманча мәгълүмат һәм

# Анализируя прошлое, с надеждой на будущее

КНИГА – это память, накопленная веками с момента зарождения человеческой истории, показатель культурного развития народа, зеркало его духовного мира. Библиотекари же через обширную творческую деятельность писателей, журналистов, мемуаристов, историков собирают и хранят исторические воспоминания нашего народа, передают их из поколения в поколение.

История и уровень развития библиотек тесно переплетаются с событиями, происходящими в стране и мире. И хотя у книгохранилищ – своя история, своя ценность, своё направление работы,



*Район Үзәк китапханәсе бинасы*

*Фасад Центральной библиотеки района*



*Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шагыйрә Лилия Садриева белән, 2017 ел*

*Президент Татарстана Рустам Минниханов с поэтессой Лилией Садриевой, 2017 год*



*Район Башлыгы Р. Х. Муллин Татарстанның халык шагыйре Р. И. Вәлиев белән, 2015 ел*

*Глава района Р. Х. Муллин с народным поэтом Татарстана Р. И. Валеевым, 2015 год*

мәдәният үзгенә кадәр озын юл үткән, һәм бүгенге көндә дә тормышыбызда зур әһәмияткә ия.

Бүгенге көндә районыбыз халкына 29 китапханә хезмәт күрсәтә. Район китапханәләрендә 41 китапханәче хезмәт куя. Шуларның 19 ы югары, 19 ы махсус урта белемле. 2019 нчы елда 23 китапханә хезмәткәре өстәмә белем бирү курсларында укып профессиональ белемнәрен күтәрделәр.

Бүгенге көндә 329 071 данә китап, журнал һәм аудиовизуаль материаллардан торган китап фонды район халкының милли хәзинәсе. Аны яңарту, тулыландыру, аларның сакланышын тәэмин итү – район китапханәләренең төп бурычларының берсе булып санала.

Районда биш модель китапханә эшли: үзәк

жизнь их – это неотъемлемая часть истории народа и родного края.

Если посмотреть на страницы истории, то библиотеки прошли долгий исторический путь от «красных уголков», изб-читален до центров современной информации и культуры, играющих сегодня большую роль в нашей жизни.

Жителей района обслуживает сегодня 29 библиотек. В них работает 41 библиотекарь. По образованию они делятся на две равные части: девятнадцать человек с высшим образованием и также девятнадцать – со средним специальным. В 2019 году 23 библиотечных работника прошли курсы дополнительного образования.

На сегодняшний день книжный фонд, состоящий из 329 071 экземпляров книг, журналов и аудиовизуальных материалов, – это подлинное национальное достояние жителей района. Одной из основных задач наших библиотек является их обновление, пополнение, обеспечение сохранности. В Муслюмовском районе это хорошо понимают, и в этом направлении ведётся определённая работа. Здесь действуют пять модельных библиотек: центральная, детская, Тойгельдинская, Новоусинская и Тат. Буляровская сельские библиотеки.

В новых многофункциональных центрах разместились Елгабашевская, Мари Булярская, Уразметьевская, Мелля Тамакская, Михайловские Рус. Шугановская



*«Тел. Милләт. Дин» дип исемләнгән «түгәрәк өстәл»*

*«Круглый стол» на тему «Язык. Нация. Вера»*



*Үзәк китапханә коллективы*

*Коллектив центральной библиотеки*



*«Без – Тукай оныклары» шигырь бәйгесе*

*На конкурсе «Мы – внуки Тукая»*

китапханә, балалар китапханәсе, Тат. Бүләр, Тойгелде, Яңа Усы авыл китапханәләре.

Рус. Шуган, Елгабаш, Мари Бүләр, Үрәзмәт, Мәллә Тамак, Михайловка авыл китапханәләре яңа төзелгән күп тармаклы үзәкләргә урнашты. Эшләрен бөтен уңайлыклары булган бүлмәләрдә алып баралар. Әлеге китапханәләргә яңа матур стеллажлар, өстәл, урындыклар кайтартылды.

2018–2019 нчы елларда республика һәм район бюджеты хисабына район мәдәният учаклары-матди-техник базасы ныгытылды, Иске Карамалы, Әмәкәй, Баек, Олы Чакмак, Югары Табын, Тат. Бүләр, Тойгелде,Яңа Усы авылы мәдәният йортларында һәм шул биналарда урнашкан китапханәләрдә капиталь төзекләндерү кебек зур эшләр башкарылды. Моннан тыш, Татарстан

сельские библиотеки. Они оснащены новым оборудованием, мебелью, стеллажами.

В 2018–2019 годах за счёт республиканского и районного бюджета укреплена материально-техническая база центров культуры. Были проведены капитальные ремонты в библиотеках сёл Старые Карамалы, Амикеево, Баюково, Большой Чакмак, Верхий Табын, Тат. Буляр, Тойгельде, Новые Усы. Все они расположены в зданиях домов культуры. Кроме того, участвуя в конкурсе «Лучшая библиотека на территории сельского поселения Республики Татарстан», проведенном Министерством культуры РТ, Октябрьская, Тугашевская, Тойгильдинская сельские библиотеки выиграли грант в размере 100 тысяч рублей и были обеспечены необходимым оборудованием.

В своей работе чувствуем поддержку Национальной, Республиканской юношеской библиотек и руководства



*Газеталар укыйбыз*

*Читаем прессу*



*Китапханәләрдә төрле буын вәкилләре эшләсә дә, хезмәт коллективы үзара дус-тату һәм ярдәмчел*

*Разные поколения наших библиотекарей живут и работают одной большой семьёй*

Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан үткәрелгән «Татарстан Республикасы авыл җирлеге территориясендә урнашкан иң яхшы китапханә» конкурсында катнашып, Октябрь, Тугаш, Тойгелде авылы китапханәләре 100әр мең сум күләмендә грант отып, кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителде.

Милли китапханә, Республика яшүсмерләр китапханәсенең терәгеп, район житәкчелегенең ярдәмен, тоеп эшлибез. Халыкка китапханә хезмәте күрсәтү мәдәният йортлары, мәктәпләр һәм җирле үзидарәләр белән берлектә төзелгән планнар нигезендә оештырыла. Китап укучыларның аерым группалары белән эш тә китапханәләребезнең игътибар үзәгендә, бу мәктәпләр, аграр көллият студентлары, сугыш һәм хезмәт ветераннары, укучыларның аерым группалары белән китапханәләрдә оештырылган шөгыльләр буенча клублар, түгәрәкләр, уздырылган кызыклы әдәби кичәләр эшендә ачык чагыла.

Китапханә эше тагы да нәтиҗәле булсын өчен китапханәчеләр Россиякүләм, регионара, Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, Республика яшүсмерләр китапханәсе тарафыннан оештырылган конкурсларда актив катнашалар, хезмәтебезнең уңай нәтиҗәләре дә бар. 2019 нчы елда үзәк китапханә хезмәткәрләре өч грантка, шул исәптән Россия Федерациясе Президентының «Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә проектларга ярдәм итү» номинациясендә ике грантка лаек булдылар: Әлеге грант акчасы китапханәне техник яктан җиһазландыруга, китап фондын тулыландыруга тотылды.

Китапханәчеләр җәмәгать эшләрендә, район күләмендә үткәрелгән чараларда актив катнашалар. Хәзерге вакытта район территориясен төзекләндерүгә һәм яшелләндерүгә зур игътибар бирелә. Китапханә хезмәткәрләре бу юнәлештә дә зур җаваплылык белән үз өлешләрен кертәләр: җир кишәрлекләрен тигезләп үлән чәчү, агач-куаклар утырту, чәчәкләр үстерү һәм башка эшләр белән шөгыльләнәләр.



*«Иң яхшы укучы гаилә» конкурсы*
*Конкурс «Лучшая читающая семья»*

района. Библиотечное обслуживание населения осуществляется на основе планов, составленных совместно с Домами культуры, школами и местным самоуправлением. Ведётся дифференцированная работа с отдельными группами читателей, которая ярко отражается в работе клубов по интересам, различных кружков, литературных вечеров, организованных совместно с коллективами школ, студентами аграрного колледжа, ветеранами войны и труда.

Мы активно участвуем в конкурсах, организованных Министерством культуры РТ, Национальной, Республиканской юношеской библиотеками, а также в российских и межрегиональных мероприятиях. В 2019 году сотрудники центральной библиотеки выиграли три гранта, в том числе два гранта Президента Российской Федерации в номинации «Поддержка проектов в сфере культуры и искусства». Эти средства были использованы на техническое оснащение библиотеки и пополнение книжного фонда.

Наши библиотекари охотно принимают участие в общественной жизни района, в мероприятиях районного масштаба. В настоящее время особое внимание уделяется благоустройству и озеленению района. Сотрудники библиотек ответственно и с большой заботой относятся к родной природе, к вопросам экологии края, где они живут и работают.

Наш библиотечный коллектив сложился в одну большую и дружную семью, в которой содержательные и прогрессивные идеи сплачивают людей, где царят дух творчества и взаимопонимания, где во главу угла поставлены любовь к Её Величеству Книге и интересы читателей.



***Дилбәр КАШАПОВА,***
*китап туплау һәм эшкәртү бүлеге китапханәчесе*

*Китаплар – балачактан ук минем иң якын дусларым. Бу дөньяның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында шул дусларым белән без гомер буе серләшәбез. Шуңа күрә китапханәгә атлап кергәндә ымсындыргыч очрашу җылысы биләп ала.*

Ф. Садриев, халык язучысы

# Мөслим район үзәк китапханәсе тарихы битләреннән

МӨСЛИМ авылында Октябрь революциясенә кадәр укый-яза белүчеләр бик сирәк булган. Авылда өч кенә мәдрәсә эшләп, анда да дини сабаклар гына укытылган. Җирлектә китапханәләр бөтенләй булмаган. 1930 нчы елның 10 августында Бөтенсоюз Үзәк Башкарма комитеты карары нигезендә ТАССР составында 46 район оештырыла. Шуларның берсе – туган төбәгебез Мөслим районы. Район төзелгәннән соң, Мөслим авылында 1930 нчы елда бер клуб һәм бер китапханә ачыла.

Нажия Исхакова, Асия Шәфыйковалар әйтүенчә, беренче китапханә Кооператив урамында, иске мәчет бинасының беренче катында урнашкан була.

Китапханәче булып Рәшидә Хөсәен кызы Галимова эшли башлый, ә 1941 нче елда аның урынына Разыя Шәфыйкова килә. Разыя Шәфыйкованың кызы Асия апа (80 яшь) әйтүенчә, китапханәдә китаплар өчен махсус кулдан ясалган 5–6 шкаф торган. Разыя апа китапханәче вазыйфасын башкарган, шул ук вакытта бүлмәне дә үзе җыештырган, утын кисеп мичен яккан, бинаны җылыткан.

1943–1944 нче еллар тирәсендә китапханә Банк урамындагы эшче-крестьян мәктәбе бинасы (РКШ) янында урнашкан мәчет бинасына күчә (хәзерге Банк урамы, 23 йорт). Разыя апа хезмәт юлын балалар бакчасында дәвам итә. 1945 нче елдан аның урынында Хафаса Хөснулла кызы Мөхәмәтҗанова эшли башлый.

Китапханә тарихын язганда безгә күп кенә өлкән яшьтәге кешеләр белән аралашырга туры килде. «Сез китапханәне хәтерлисезме, китапханәгә йөргәнегез булдымы?» дип сорагач: «Әйе, анда Хафаса апа эшли иде,» – диләр. Чыннан да, Хафаса апа Мөхәмәтҗанова китапханәдә озак еллар эшләп, заман авырлыкларына бирешмичә, район китапханәләрен торгызуга зур өлешен керткән шәхес. Үзенең тырышлыгы, таләпчәнлеге, оеш-



Рәшидә Галимова



Разыя Шәфыйкова



Хафаса Мөхәмәтҗанова



*Х. Ә. Спиридонова (уңнан 1 нче), Х. Ф. Фәттахова (уңнан 3 нче) китап укучылар белән очрашу вакытында*



*Район мәдәният хезмәткәрләре һәм китапханәчеләр, 1962 ел*

тыру сәләте белән аерылып торган ханым була.

Бүгенге көндә Банк урамында яшәүче өлкән яшьтәге Ләйсирә апа Хантимерова ул чорларны болай дип искә ала: «Мин кечкенәдән китап укырга яраттым. Банк урамындагы китапханәгә яратып йөргәнемне хәтерлим, китапханәдә махсус ясалган агач китап киштәләре бар иде, рус, татар телендә китаплар бик аз, китаплар күбрәк латин хәрефләре белән язылган. Балалар да, зурлар да шул китапханәгә йөри иде. Укучы балалар күп, китаплар җитми. Хафаса апа: «Укымый алып киләсездер әле...» дип, китапларның эчтәлеген сөйләтә иде».

1946 нчы еллар тирәсендә китапханә Бакча урамына күчерелә. Китапханә артык зур булмаса да, матур итеп бизәлә, китаплар агач киштәләрдә, күп укыла торганнары аерым тартмаларга урнаштырыла. Бу чорда китапханә гөрләп эшли, китапханәгә йөрүче күп, аеруча татар әдәбияты белән кызыксынучылар күп булган. Бигрәк тә Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз», Г. Бәшировның «Намус» романнарын, Т. Гыйззәт, К. Тинчурин, М. Фәйзинең драма әсәрләрен чират торып яратып укыганнар.

Китапханәне Гөлзада Арыслангали кызы Хәйруллина (Арсланова)якты хатирәләр белән искә ала: «Минем балачак, яшьлек елларым Бакча урамында үтте. Шул урамда урнашкан район китапханәсен бик яхшы хәтерлим. Ул алты почмаклы агач бинага урнашкан иде. Хуҗасы – ачык йөзле, үз эшенә чын мәгънәсендә бирелгән Хафаса апа. Китапханә үзенең җылысы белән күпләрне тартып тора иде. Андагы тәртип, чисталык, тәрәзә төпләре тулы гөлләр. Атна саен барсаң да, күзләрне кызыктырырлык итеп эшләнгән китап күргәзмәләре хәзер дә күз алдымнан китми. Шул ук вакытта таләпчәнлек: алган журналыңны, китабыңны сак кына тотасың, кайда анда берәр битен ертып алу яки астына сызу. Китапханәгә кире илткән китапны Хафаса апа җентекләп тикшереп ала.

Шул кечкенә бинада бик уңайлы уку залы бар иде. Китапханә иртәнге сәгать уннан кичке унга кадәр эшләде. Өлкән кешеләр шунда китап, журналлар укырга җыйналалар иде. Ул уку залының буш булганын хәтерләмим. Гомумән, район китапханәсе ул чорда кешеләр өчен гыйлем үзәге булып торды».

1950 нче елдан башлап китапханәгә Алабуга китапханәчеләр техникумын тәмамлап, бер-бер артлы яшь белгечләр килә: 1950 нче елның 26 июленнән уку залына Мөшәрәфә Сабирова, 1952 нче елда Халисә Фәттахова, 1953 нче елда Җәүһәрия Сабирова район китапханәсенә китапханәче булып эшкә киләләр. Кызлар барысы да Сарман районныннан булалар. Хафаса Мөхәммәтҗанова яшь кадрларны эшкә өйрәтә, тәҗрибәсе белән уртаклаша, яшьләргә үзенең киңәшләрен бирә.

1953–1975 нче елларда төрле оешмаларда, терлекчелек йортларында, кыр станнарында, китапханә булмаган авылларда күчмә китапханәләрнең эше җанланып китә, аларны даими рәвештә газета-журналлар һәм китаплар белән тәэмин итеп торганнар. Мәсәлән, ул чорда күчмә китапханә мөдире Энҗе Әбелхарис кызы Әгъзамова районнан шактый ерак Катмыш, Нарат Асты, Торыш, Чия Түбә, Дусай, Сәфәр авылларына кадәр кыш көне чаңгыда аркасына китаплар асып барып, күчмә китапханәләрнең китапларын яңартып, эңгәмәләр үткәрә торган булган.

Бу елларда китапханәчеләрне бик күп җәмәгать эшләренә җәлеп иткәннәр: спектакльләр кую, плакатлар язу, агитбригада төркеме белән чыгышлар ясау, кыр эшләрендә колхоз-совхозларга булышу һәм башкалар.

Еллар авыр булса да, халык



*Дания Гәрәева, Фәрдия Гәрәева, Халисә Фәттахова, Энҗе Әгъзамова*



*Халыкка китапханә хезмәте күрсәтү бүлеге (абонемент)*

белемгә омтылган, китапка тартылган, үткәрелгән чараларда актив катнашкан. Өлкәннәрнең сөйләүләренә караганда, мәктәп белән берлектә клубта үткәрелгән Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» романы буенча китап укучылар конференциясендә халык залга сыймыйча ачык ишектән, тәрәзәләрдән тыңлап торган. Г. Әпсәләмов үзе килгән.

Үзебезнең җирлектә яшәүче күренекле кешеләр белән дә очрашулар еш оештырылган. Шундый зур чараларның берсе булып район клубында эшләүче Бөек Ватан сугышы ветераны, Кремльдә Сталин каршында тальян гармун уйнап җырлаган Фатыйма Һадиева белән очрашу укучылар күңелендә онытылмаслык хатирә булып калган.

Үзәк китапханә хезмәткәрләре китап укучыларны китапханәгә күпләп тарту, китап пропагандалау алымнарын авыл китапханәләренә дә җиткерү буенча зур эш башкарганнар. Эш тәҗрибәсе уртаклашу максатыннан ике көнлек семинарлар уздырылган. Әлеге чаралар кысаларында методик ярдәм йөзеннән авыл китапханәчеләре эшләрендә үрнәк итеп кулланырлык китап укучылар конференцияләре, викториналар, бәйгеләр, әдәби кичәләр оештырылган.

Ул елларда район китапханәләрендә авыл хуҗалыгында алдынгы тәҗрибәне яктырткан китапларга ихтыяҗ арта. Китапханәчеләр көннең ике сәгатен терлекчеләр, игенчеләр янында үткәрә торган була. Урак өстендә басуларга барып кыр эшчәннәрен эш нәтиҗәләре, көн яңалыклары, яңа кайткан китап, газет-журналлар белән таныштыру, бюллетеньнәр чыгару, эш күрсәткечләрен ындыр табагындагы күрсәткеч такталарына һәркөн язып элү кебек эшләр башкарганнар.

Авыл хуҗалыгы белгечләре белән тыгыз элемтәдә торып игенчелек, терлекчелек буенча китапларны пропагандалауга зур игътибар бирелгән: мәгълүмати кичәләр, очрашулар, күзәтүләр, әңгәмәләр дә уздырылган. Чараларда колхозчыларның киң кырлы хезмәте яктыртылган. Шул ук вакытта китапханәчеләр үзләре дә авыл хуҗалыгы эшләрендә актив катнашканнар: чөгендер эшкәртү, көз көне аны алу, ындыр табагында икмәк чистарту, мал абзарларыннан тирес чыгару, кычыткан, яфрак киптерү кебек эшләр башкарганнар.

1970 нче елның 12 нче маеннан Хафаса Мөхәммәтҗанова лаеклы ялга китә, китапханә мөдире булып Халисә Фәрхетдин кызы Фәттахова билгеләнә. Бу вакытта китапханә штатында 4 кеше эшли: китапханә мөдире – Халисә Фәттахова, халыкка китапханә хезмәте күрсәтү бүлеге мөдире – Фәрдия Гәрәева, уку залы мөдире – Энҗе Әгъзамова һәм күчмә китапханә мөдире – Дания Гәрәева.

1976 нчы елда китапханәчеләрнең хыялы тормышка аша – китапханә ике катлы бинага күчә: (Пушкин урамы, 35 нче йорт). Китапханәнең мәйданы барлыгы – 619,63м². Беренче катта халыкка китапханә хезмәте күрсәтү бүлеге (абонемент), икенче катта 150 китап укучыга исәпләнгән уку залы урнаша.

Яңа бинага күчү бик мәшәкатьле булса да, китапханәчеләр шатланып, җиң сызганып эшкә тотыналар. Китапханәнең ихатасы әйләндереп алына, аның тирәсенә чыршы, чәчәкләр һәм тәрәзә төпләренә күп итеп гөлләр утыртыла. Китапханәнең абонемент, уку залы матур итеп җиһазландырыла. Яңа тимер стеллажлар, өстәл, урындыклар кайта. Китапханә халыкның яратып йөри торган урынына әверелә, китап укучылар саны арта.

1974 нче елның 26 нчы декабрендә чыккан «Хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдә һәм фәнни-техник прогрессын үстерүдә китапханәчеләрнең роле» турындагы карар нигезендә, 1977 нче елның 1 нче октябреннән район китапханәләре үзәклəш-

терелгән китапханәләр системасына берләштерелә. Үзәк китапханә һәм аның балалар бүлеге булдырыла. Ә авыл китапханәләре үзәк китапханәнең филиаллары буларак эшли башлый. Барлыгы 27 филиал була. Яңа штат расписаниесе төзелә. Китапханәнең үз мөһере һәм боерык кенәгәсе булдырыла.

Үзәкләштерү авыл филиаллары өчен бик файдалы була. Үзәк китапханә аларны административ-хуҗалык эшләреннән, китап туплау һәм эшкәртүдән азат итә. Кадрлар белән эшләү, аларның белем дәрәҗәсен арттыру да үзәк китапханә өстендә була. Иң мөһиме – бердәм китапханә фонды тупларга, укучыларның ихтыяҗларын тулы канәгатьләндерергә мөмкинлек бирә.

1977 нче елда үзәк китапханәнең китап фонды – 26 668 данә. Китап укучылар саны – 3 550. Китап бирелеш – 64 443. Укылыш – 18. Әйләнеш – 2,1.

Бу чорда үзәк китапханәнең китап туплау һәм эшкәрту бүлегендә зур күләмле эш башкарыла. Топографияләр ясала, барлык китапханәләрнең китап фондлары барлана. Иске китапларны фондтан чыгару, инвентарь һәм суммар китапларын тәртипкә китерү, алфавитлы һәм системалы каталогларны төзү, китап фондын яңа библиографик классификация таблицасына (ББК) күчерү, газета-журналлар картотекасы алып бару кебек эшләр башкарыла.

Үзәк китапханә каршында «Китап сөючеләр», «Сердәш», «Ягез әле, кызлар», «Аш осталары» кебек шөгыльләр буенча клублар эшли башлый. «Картаймагыз әле, ветераннар» клубы оештырылып, аның аерым уставы, программасы булдырыла һәм айның билгеле бер көннәрендә системалы рәвештә эшли башлый. Клубларга халык бик теләп йөри. Клуб әгъзаларының туган көннәрен билгеләп үтү, тантаналы рәвештә котлау күркәм гадәткә керә.

1981 нче елда китапханәдә «Китап сөючеләр җәмгыяте» («Общество книголюбов») оештырыла. Аның рәисе итеп Зөләйха Назыйф кызы Шабаева билгеләнә. Җәмгыять китапханәчеләр каршында оештырылган советларга таянып эш итә. Аларның 37 башлангыч оешмасы булып, аларда 869 әгъза исәпләнә. Җәмгыять совет членнары һәм активистлар белән берлектә китапханәгә укучылар тарту, массаларны коммунистик рухта тәрбияләү, авыл хезмәтчәннәрен хуҗалык алдында торган бурычларны хәл итүгә рухландыру буенча киң кырлы эш башкара.

1980–1987 нче елларда үзәк китапханәдә капиталь төзекләндерү эшләре башкарыла. Китапханәнең материаль-техник базасы ныгытыла, яңа төр инвентарьлар белән тулыландырыла: радиола, ротатор, фильмоскоплар, 3 телевизор, 10 өстәл лампасы, 40 өстәл, 6 язу машинкасы, 10 китап шкафы, 100 урындык, 2 магнитофон, 60 тәрәзә пәрдәсе кайтартыла.

1990 нчы елның февраль аеннан «Авыл утлары» газетасында «Китап сөючеләр клубы» сәхифәсе чыга башлый. Анда район китапханәчеләренең хезмәте, китапханәләрнең эшчәнлеге яктыртыла.

1977–1992 нче елларда район үзәкләштерелгән китапханәләр системасы тынгысыз хезмәтләре өчен «Иң яхшы китапханә», «Иң яхшы күчмә китапханә» дигән мәртәбәле исемгә, дүрт мәртәбә КПСС өлкә Комитетының һәм Министрлар Советының күчмә Кызыл байрагына лаек була.

1992–1996 нчы елларда үзәкләштерелгән китапханәләр системасын районыбызда яшәп иҗат итүче Фоат Миңлеәхмәт улы Садриев җитәкли. Фоат Садриев район китапханәләренең, шул исәптән үзәк китапханәнең, матди-техник базасын ныгыта. Үзәк китапханәнең җылылык системасы тулысынча алыштырыла. Фоат Миңлеәхмәт улы район халкының рухи үсеш дәрәҗәсен күтәрүгә, мәгърифәтен арттыруга зур өлеш кертә. Бу елларда Республикабызның иҗат эшлекләренә, районыбызда туып үскән язучы һәм шагыйрьләр:



*Уку залы*



*Китап туплау һәм эшкәрту бүлеге китапханәчеләре*


«Авыл утлары»

Китап сөючеләр клубы

Өметебезне аклый

Бергәләп, ярдәмләшеп


«Авыл утлары»

Китап сөючеләр клубы

Яңа басмалар

Кыйммәтле хәзинә

*«Авыл утлары» газетасында урын алган Китап сөючеләр клубы*

Х. Әюпов, З. Маликов, Ш. Җиһангирова, А. Минһаҗева, Ф. Гыйльми, М. Әхмәтҗанов һәм башкаларның иҗатларын пропагандалауга аеруча зур игътибар бирелә.

1996 нчы елда үзәкләштерелгән китапханәләр системасының директоры итеп Сәкинә Исмәгыйль кызы Ильясова билгеләнә. Махсус югары белемле, китапханә эшен тирәнтен белүче, эшен тәгәл, җиренә җиткереп башкаручы, таләпчән җитәкче була ул.

Бу чорда китапханә Республика мәдәният министрлыгы, Милли китапханә, Яшүсмерләр китапханәсе оештырган бәйгеләрдә актив катнаша, күп төрле мактау грамоталарына лаек була.

2000 нче еллар башында тормышның барлык тармакларына, шул исәптән китапханә эшенә дә, алдынгы технологияләр үтеп керә. 2002 нче елның декабрь аеннан үзәк китапханәдә хокук белемнәрен нигезле үзләштерү өчен «Консультант-Плюс» электрон белешмә-хокук базасы кертелә, 2003 нче елдан АИБС «Марк» программасы буенча электрон каталог һәм системалы картотека төзү буенча эш башлана.

2005 нче елдан район буенча «Һәр авылга – үрнәк мәдәният учагы» дигән ярыш уздырыла башлый һәм ул бик нәтиҗәле була. Ярышта бер генә китапханә дә катнашмый калмый. Һәр китапханәче үзенең китапханәсен матурлый, үз территориясен яшелләндерә, гөлләргә төрендерә. Соңыннан мәдәният хезмәткәрләренең район конференциясендә йомгак ясала. Бу ярышта үзәк китапханә дә бик теләп катнаша һәм ел саен үзенең матур бизәлеше белән аерылып тора, призлы урыннарга лаек була.

Үзәк китапханә хезмәткәрләре район күләмендә үткәрелгән бер генә чарадан да читтә калмый: Яңа ел, 8 нче март, Бөек Җиңү, Сабантуй кебек бәйрәмнәрдә, сайлау, бөтенроссия сан алу кампанияләрен оештыру һәм үткәрүдә актив катнашалар.

Китапханәчеләр 8 март-халыкара хатынкызлар көнендә,2006 нчы елдан китапханәдә мәгълүматихокукый үзәк (Центр правовой информации) эшли башлый. Аның төп бурычы – һәр кешене хокукый мәгълүмат белән таныштыру, көндәлек тормышта килеп чыккан катлаулы юридик проблемаларны хәл итүдә ярдәм итү. Үзәкнең фондында энциклопедия, сүзлек, хокук фәне буенча яңа китаплар, вакытлы матбугат басмалары туплана.


*Язучылар белән очрашу*

2009 нчы елның май аеннан декабрь аена кадәр үзәкләштерелгән китапханәләр системасы җитәкчесе булып Лариса Николай кызы Садилова эшли. Бу елларда үзәк китапханәдә капиталь ремонт эшләре башкарыла. Мөслим үзәк китапханәсенең үз сайты булдырыла.

2010–2011 нче еллар эчендә үзәкләштерелгән китапханәләр система-



Үзәк китапханә хезмәткәрләре



Китапханәдә – яңа технологияләр

сының ике мәртәбә статусы үзгәрә:

2010 нче елның 11 нче ноябреннән Мөслим муниципаль районы башкарма комитетының 2010 нчы ел, 11 нче ноябрь, № 1239 санлы карары нигезендә «Мөслим үзәкләштерелгән китапханәләр системасы – «Үзәкләштерелгән китапханә» муниципаль учреждение» дип үзгәртелә.

2011 нче елның 30 нчы ноябреннән Мөслим муниципаль районы башкарма комитетының 2011 нче ел, 30 нчы ноябрь, № 924 санлы карары нигезендә «Үзәкләштерелгән китапханә» муниципаль учреждение – «Үзәкләштерелгән китапханә» Муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе» дип үзгәртелә.

2011 нче елдан МБМУ «Үзәкләштерелгән китапханә» коллективын Лилия Яссир кызы Садриева җитәкли. Лилия Яссир кызы җирлегебездә һәм башка төбәкләрдә яшәп иҗат итүче шагыйрьләр, язучылар белән тыгыз элемтәдә торып, районыбыз китапханәләре эшен тагын да җанландырып җибәрә. Республиканың танылган язучылары, күренекле шәхесләре китапханәбезнең даими кунаклары булып, алар катнашында китапханәдә бик күп чаралар үткәрелә. Лилия Яссир кызы бу чараларны үзенең кеше күңеленә үтеп керерлек чыгышлары, үзе иҗат иткән шигырьләре белән бизи, аның җитәкчелегендә үткәрелгән әлеге чаралар күпләрнең күңелендә озак саклаunion.

Лилия Яссир кызы эшләгән елларда үзәк китапханә бинасы керамогранит белән тышланды, түбәсе алыштырылды, идәннәр тулысынча яңартылды, китапханәгә керү өчен тротуар җәелде, бинаның тышкы ягын яктырту буенча эшләр башкарылды.

*Статья посвящена истории одной из старейших библиотечных систем Республики Татарстан – Централизованной библиотечной системе Муслюмовского района.*

*В 1930 году Указом Исполнительного Комитета ТАССР в республике были организованы 46 районов, среди них – Муслюмовский район, в котором были открыты клуб и библиотека. Учреждения культуры стали основными центрами просвещения и пропаганды в крае.*

*Первым библиотекарем стала Рашида Хусаиновна Галимова. В разные годы библиотекой руководили Р. Шафикова, Х. Мухаметзянова, М. Сабирова, Х. Фаттахова, Ж. Сабирова, С. Ильясов, а с 2011 года библиотеку возглавляет Л. Садриева.*

*Библиотека всегда была центром продвижения литературы, творчества национальных авторов, таких как Г. Абсалямов, Г. Баширов, Т. Гиззат, К. Тинчурин, М. Файзи и др.*

*В 1977 году в результате централизации библиотеки района были объединены в единую библиотечную сеть, в которую вошли 27 филиалов.*

*При библиотеке организованы многочисленные клубы по интересам: «Любителей книги», «А ну-ка, девушки», «Не стареют ветераны!», «Общество книголюбов» и др.*

*В настоящее время библиотека является участницей многих республиканских проектов, достойно выполняя миссию сохранения и продвижения национального и мирового духовного наследия.*

*Дилбәр КАШАПОВА,*
*китап туплау һәм эшкәртү*
*бүлеге китапханәчесе*

# Заманча китапханә: үсеш юллары

## РАЙОН ҮЗӘК КИТАПХАНӘСЕ БҮГЕНГЕ КӨНДӘ

*Китап – ул бик борынгыдан*
*килә торган кыйммәт.*
М. Әхмәтҗанов,
балалар шагыйре



*Китапханәнең яңа бинасы*

БҮГЕНГЕ көндә район үзәк китапханәсе халыкка модель китапханә буларак хезмәт күрсәтә. Ул әлеге яңалыкка таянып җиһазландырылган, компьютерлар белән тәэмин ителгән, интернет челтәренә тоташтырылган, рәхәтләнеп ял итү, фикерләшү мөмкинлеге тудырылган. Укучыларга өй эшләрен эшләргә, кирәкле мәгълүматны китаплардан яисә интернеттан табу да уңайлы.

Китапханәдә хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәле системасы да булдырылган.

Фондлар автомат рәвештә АКМС (автоматлаштырылган китапханә мәгълүмат системасы) «Руслан» программасы аша исәпкә алына һәм эшкәртелә. Китапханәчеләр кулланучыларга тиешле мәгълүматны компьютер технологияләре ярдәмендә, электрон хезмәт күрсәтү, китапларны электрон формулярлар аша бирә башлау юнәлешендә эш алып баралар.



*Китапларны исәпкә алу*

Соңгы елларда район хакимияте дә китапханә эшчәнлегенә зур ярдәм күрсәтә. Аеруча район Башлыгы Рамил Хәмзә улы Муллин китапханәләрне социаль-мәдәни һәм мәгълүмати үзәк буларак үстерүгә, китапханә эшендә гадәти булмаган яңа ысуллар куллануга зур игътибар бирә. Башка төбәк китапханәләренең эшчәнлеге, аларда кулланылучы алдынгы технологияләр белән кызыксынып, район китапханәләренең эш сыйфатын яхшырту максатында еш




*Китап сайлау*

кына үз фикерләрен, тәкъдимнәрен җиткерә. Үзәк китапханәдә башкарылган күп кенә үзгәрешләр дә Рамил Хәмзә улы Муллин, мәдәният бүлеге җитәкчесе Ирек Фаяз улы Сәлихҗановларның башлангычы һәм ярдәме белән эшләнде. Китапханәбез сокланып туймаслык матур. Беренче кат төрле зоналарга бүленеп, яңа уңайлы диваннар, йомшак кәнәфиләр, өстәл-урындыклар, идәннән түшәмгә кадәр матур биек стеллажлар булдырылды. Китап фонды икенче катка күчерелеп, яңа әдәбият белән тулыландырылды.

Китапханәнең эш сәгате кичке 20. 00 сәгатькә кадәр озынайтылды. Болар барысы да район халкына тиешле мәгълүмат бирү һәм белем алуны нәтиҗәле итү өчен эшләнде.

Китапханәдә укучыларның китапка, мәгълүматка булган ихтыяҗын канәгатьләндерү максатында берсеннән-берсе кызыклы, мавыктыргыч чаралар үткәрелә. Мәсәлән: соңгы елларда җирлегебездә күренекле татар язучыларын, фән һәм сәнгать эшлеклеләрен чакырып «Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре» үткәрү матур традициягә әйләнде. Шул уңайдан район үзәк китапханәсендә «Дәверләрне ачар ачкычым бар», якташ язучыларыбыз Факил Сафинга багышланган «Чаба гомер аты», Татарстан Республикасының халык язучысы Фоат Садриевка багышланган «Халык язучысы» дигән бик матур әдәби очрашу кичәләре узды. Быел да 21–22 нче сентябрь көннәрендә Мөслимгә бертөркем татар язучылары, галимнәр белән бергә дин әһелләре дә килде. Үзәк китапханәдә «Тел. Милләт. Дин» дип исемләнгән «түгәрәк өстәл» үтте. Очрашуда язучылар, килгән кунаклар татар телен, әдәбиятын, милләтне саклау турында үз фикерләрен җиткерделәр.



*Кунакта Фәрит Мөхәммәтшин, 2014 нче ел*

Республикабызның танылган язучылары, күренекле кешеләре китапханәбезнең даими кунаклары, һәр чарада аларның тормыш юлларын, иҗат җимешләрен халыкка җиткерергә тырышабыз.

Китапханәбезнең мәртәбәле кунаклары: Татарстан Президенты Р. Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе Ф. Мөхәммәтшин, язучы, шагыйрь, күренекле җәмагать һәм сәясәт эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре Р. Вәлиев, Татарстан



*Татарстанның танылган язучылары үзәк китапханәдә, 2015 ел*



*Татарстан Республикасы мәдәният министры И. Х. Аюпова үзәк китапханәдә, 2020 ел*



*Якташыбыз, халык язучысы Фоат Садриев «Картаймагыз әле, ветераннар» клубы әгъзалары белән очрашу кичәсендә, 2019 ел*

Республикасы Мәдәният министры И. Аюпова һәм башкалар.

Районыбыз язучыларга бик бай. Җирлегебездә яшәп иҗат итүче Татарстанда танылган язучы-драматург, Тукай премиясе лауреаты, халык язучысы Ф. Садриев, балалар шагыйре М. Әхмәтҗанов, Л. Садриева, Р. Хәбибуллина. Башка төбәкләрдә яшәп иҗат итүче И. Нәбиуллина, Ш. Җиһангирова, Ф. Әмәк, З. Дәүләтов, Ф. Баһаутдинов, Л. Лерон һәм башкалар бар. Якташ язучыларыбыз белән тыгыз элемтәдә торабыз. Һәрбер язучының яңа чыккан китабын көтеп алабыз, төрле масса чаралары аша аларны халыкка җиткерергә тырышабыз.

Яшь буынны татар эстрадасы артистлары белән якыннан таныштыру, укучыларда сәнгатькә мәхәббәт уяту максатыннан «Йолдызга 10 сорау» исемле татар эстрадасы йолдызлары белән очрашу кичәләре үткәрү дә бер традициягә әйләнде. Мөслим районына концерт белән килгән Алмаз-Зөлфирә Мирзаяновлар һәм Динә Закирова, «Казан егетләре» төркеме, Татарстанның атказанган артисты Фирдүс Тямаев, Әбри Хәбриев тамашачылар белән очрашып, аларны кызыксындырган сорауларга җавап бирделәр. Проект кысаларында һәр очрашуда концертка билетлар уйнатыла, килгән кунакларга якташ язучыларның китаплары бүләк ителә.

Үзәк китапханәдә башка төбәк язучылары белән очрашулар да еш үткәрелә. Мәсәлән, Башкортстан Республикасыннан Айгиз Баймөхәммәтов, Яр Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче язучы, шагыйрә Айгөл Габдулла кызы Әхмәтгалиева, язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан журналистлары бер-



*Ризат һәм Зинира Рамазановлар, 2018 ел*



*«Лилияләр» төркеме, 2019 ел*

леге әгъзасы Гөлсинә Наил кызы Галимуллина,күренекле татар шагыйре, публицист, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Р. Миңнуллин, Зифа Кадыйрова, Венер Исхаков кебек танылган язучылар белән кызыклы очрашулар үтте.

Габдулла Тукайның туган көненә багышланган «Кунакчыл йортта – кунак бар» дип исемләнгән «Библиокич» тә катнашучыларның күңеленә хуш килде. Чарада өлкәннәр белән беррәттән мәктәп укучылары һәм балалар бакчасына йөрүче кечкенәләр дә катнашты. Тукай әкиятләре геройлары Су анасы, Кәҗә белән Сарык бәйрәмне тагын да бизәделәр. Кичәдә барлыгы 100дән артык кеше катнашты.

Яшүсмерләр, яшьләр белән эш алып бару – китапханә хезмәткәрләре өчен бүгенге көндә актуаль һәм үзенчәлекле бурычларның берсе булып тора. Яшьләр аудиториясен күздә тотып, Борис Васильевның «А зори здесь тихие...», «В списках не значился», Ю. Бондаревның «Горячий снег» повестьлары, Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» буенча квест-уены үтте. Бәйгедә Район мәдәният йортының «Сәхнә», «Мизгел» яшьләр үзәгенең «Волонтеры. ru» спорт мәктәбе командалары беренче урынга, спорт чаралары дирекциясе икенче урынга, Мәлләтамак авыл җирлегенең «Кәеф» командасы өченче урынга лаек булдылар. Шулай ук китапханәдә Брейн-ринг уены, төрле викториналар, квест-уеннар оештырыла. Яшьләр бу чараларда бик теләп катнаша.

Хезмәтебезнең тагын бер юнәлеше булып өлкән буын, сугыш һәм хезмәт ветераннары, инвалидлар белән эш тора. Менә ничә ел инде «Картаймагыз әле, ветераннар» клубы өзлексез үзенең эшчәнлеген дәвам итә. Дәрт-дәрманлы, сәләтле, тормышка гашыйк өлкәннәребез актив тормыш позициясе белән яшиләр, китапханәдә үткәрелгән масса чараларында бик теләп катнашалар. Китапханәчеләр клуб эшен камилләштерү өстендә киңкырлы эш алып баралар, очрашулар үткәрәләр.



*Язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ф. Сафин (беренче рәттә, уңда) һәм якташ язучылар белән очрашу, 2019 ел*

Китапханә эше муниципаль берәмлекләр порталында, «Вконтакте», «Instagram» социаль челтәрләрендә, районның «Авыл утлары» газетасында һәм радиосында даими яктыртылып бара.

*Статья рассказывает о сегодняшнем дне Центральной районной библиотеки Муслюмовского района Республики Татарстан. Сегодня это современная библиотека, оснащенная компьютерной и оргтехникой. Библиотека работает в системе РУСЛАН, налажены автоматизированные рабочие места, обеспечен доступ к электронному каталогу.*

*Библиотека является активным пропагандистом литературы и искусства. Традиционными стали проводимые здесь Дни татарской литературы и искусства, встречи с деятелями культуры, земляками, среди которых Ф. Садриев, М. Ахметзянов, Л. Садриева, Р. Хабибуллина, а также И. Набиуллина, Ш. Зигангирова, Ф. Эмэк, З. Давлетов, Ф. Багаутдинов, Л. Лерон и др.*

*Гостями библиотеки были президент РТ Р. Н. Минниханов, народный поэт Р. И. Валеев, министр культуры республики И. Х. Аюпова и др.*

*Особым направлением своей деятельности библиотека избрала работу с ветеранами войны и труда. В библиотеке работает клуб «Не старейте, ветераны».*

***Айсылу МАДЬЯРОВА,***
*директор МБУК «Централизованная библиотека»*




# ПРОЕКТНАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ БИБЛИОТЕК

*Библиотека под открытым небом*





В СОВРЕМЕННЫХ условиях библиотека не может развиваться без постоянного совершенствования своей деятельности. Проектно-инновационная деятельность – необходимый элемент развития. Сотрудники центральной библиотеки принимают активное участие в различных конкурсах и проектах. Есть и положительные результаты проделанной работы.

В 2018 году, участвуя в конкурсе, проведённом Министерством культуры Республики Татарстан, «Поддержка проектов творческих коллективов муниципальных учреждений культуры и искусства» совместно с проектом «Современное библиотечно-информационное пространство» мы выиграли грант на сумму 176 тысяч рублей. Целью данного проекта было создание современного библиотечно-информационного пространства, приобщение к чтению и пользованию библиотекой широких социальных слоев – детей, молодёжи и взрослой аудитории, повышению значимости библиотеки как центра информации.

В результате реализации проекта на улице Г. Тукая, рядом со средней образовательной школой была установлена библиотечно-информационная конструкция в виде уличной библиотеки. Поставлены скамейки и оборудованы книжные полки. Приобретена необходимая литература. В настоящее время ассортимент книг в уличной библиотеке постоянно пополняется. На этой территории для привлечения детей и жителей района к чтению проводятся раз-

личные мероприятия на свежем воздухе. Создание библиотечного пространства позволило сделать библиотеку ещё более комфортной и удобной для пользователей.



*Литературное кафе в Муслюмове*

В 2019 году сотрудники центральной библиотеки участвовали в конкурсе проектов Президента Российской Федерации в номинации «Поддержка проектов в сфере культуры и искусства» с двумя проектами: «Литературное кафе в библиотеке» и «Расти с книгой, малыш» и выиграли грант на общую сумму 334 тысячи рублей.

Целью проекта «Литературное кафе в библиотеке» было создание литературного кафе на базе центральной библиотеки, которое будет сочетать в себе элементы библиотеки и кафе, наиболее полно отвечающие информационным и социально-культурным запросам жителей района.



*Прекрасен кофе в литкафе*



В рамках реализации проекта были приобретены кресла, диваны, шкаф для посуды, кофемашина, чайный и кофейный сервизы, оформлена вывеска.

В данном кафе усилиями сотрудников библиотеки была сооружена декоративная печька. Рядом с печью поставили специальные приспособления – ухват и деревянную лопатку, над печкой повесили подзор из бязевой ткани, а на пол постелили хлопковые коврики с кисточками. Благодаря этим деталям кафе выглядит очень уютным местом, где приятно попить кофе, пообщаться с друзьями, почитать книги…

За время работы по проекту было проведено большое количество мероприятий, направленных на укрепление престижа чтения и библиотеки. Например: «Пресс-банкет» (торжественное открытие литературного кафе), конкурс «Читатель года» с участием самых активных читателей районных библиотек, литературный фестиваль «Китап корты», фото-конкурс «Лучшая читающая семья», интеллектуальная игра «Поле чудес», викторина «Я люблю читать книгу», квест-игра «Моабитские тетради» и другие.

Литературный фестиваль «Китап корты» прошёл в зоне отдыха «Кояшлы Ык». Девять площадок, расположенных вокруг центральной сцены, работали для жителей района. Для любителей литературы этот фестиваль был настоящим праздником. Фестиваль сопровождался выступлениями местных писателей и почётных гостей, с участием детей.

Многие организации района стали проводить мероприятия на базе нашей библиотеки, и заканчиваются эти мероприятия задушевным разговором за чашкой чая и кофе, знакомством с новинками литературы и периодики.

За время работы литературного кафе было получено множество положительных отзывов от представителей разных социальных слоёв населения. Проект реализован успешно, он имеет устойчивое развитие и востребован в обществе.

Проект «Создание нового пространства в библиотеке и развитие услуг для семей с маленькими детьми «Расти с книгой, малыш» начал свою работу в июле 2019 года. Целевая аудитория – дети до 7 лет, родители и другие члены семьи, сотрудники детских учреждений, учреждения, занимающиеся ранним развитием малышей.

Цель данного проекта – пробудить в детях любовь к чтению с первых лет жизни, установив устойчивую эмоциональную связь между ними и взрослыми на основе книги, привлечь всех заботящихся о маленьких детях (родителей, опекунов, педиатров, логопедов, специалистов в области образования) к сотрудничеству с библиотекой.

В ходе реализации первого этапа проекта были приобретены оборудования для занятий и учёбы, детские книги. Комната обставлена мебелью, создано пространство для детей.

С целью привлечения молодых родителей в библиотекув общественных местах и учреждениях рай-



*Квест-игра «Моабитские тетради»*



*Интеллектуальная игра «Поле чудес»*

она были розданы информационные листы о реализации проекта «Расти с книгой, малыш».

Преодоление нарушений речевого развития в дошкольном возрасте имеет огромное значение в последующей жизни ребёнка. В целях предупреждения задержки и отклонений речевого развития детей в центральной детской библиотеке были организованы информационные встречи для родителей и детей дошкольного возраста с логопедом района Флёрой Наилевной Харрасовой на следующие темы: «Знатоки правильной речи», «Развитие речи ребёнка от одного года до семи лет», «Преодоление общего недоразвития речи у дошкольников», «Игры и упражнения для детей от 1,5 до 3 лет» и другие. На мероприятия приглашались дети из всех дошкольных учреждений района. В ходе мероприятий Ф. Н. Харрасова в игровой форме проверяла речевые отклонения у детей, нуждающихся в логопедическом воздействии. А также рассказала о возможных причинах нарушения речевого развития у детей, о возможностях родителей в домашних условиях развития артикуляционной моторики, дыхания, показала родителям, какие необходимо делать упражнения с ребёнком.

С целью формирования определённой культуры отношения к укреплению здоровья детей, профилактики заболеваний с учётом потенциальных и имеющихся проблем были проведены встречи с педиатром Муслюмовской центральной районной больницы К. К. Садриевой на следующие темы: «Как сохранить здоровье ребёнка», «Растим здорового ребёнка», «В ожидании чуда», «Искусство быть мамой», «Растём вместе» и другие.

В районном центре осуществляют деятельность пять детских садов: «Лэйсэн», «Кояшкай», «Карлыгач», «Милəшкəй», «Күбəлəк». В рамках реализации проекта по привлечению детей к чтению сотрудники детской библиотеки провели более 15 тематических мероприятий на следующие темы: «Викторина по сказкам», «Да здравствует книга!», «Книга – наш лучший друг», «Открывая книгу– открываю мир»и другие. Кроме того, были проведены экскурсии по библиотеке. В ходе мероприятий дети ознакомились с книжками-игрушками, книжками с сюрпризами, голограммой.

В рамках проекта провели кон-



*Расти с книгой, малыш!*



*Рагозины изучают алифбу, село Каенсаз*



*Маленькая София тоже любит книги*



*Учимся правильно говорить*



*Встреча членов клуба «Зульфат» с детским поэтом М. Ахметзяновым*

курс фотографий «Папа, мама, я – читающая семья», в котором участвовали 50 семей района. По итогам конкурса все участники получили поощрительные призы и подарки.

В поддержку семейного чтения и приобщения к книге с самого раннего возраста в детской библиотеке было проведено мероприятие на тему: «Рожденный читать». В рамках мероприятия библиотекари посетили 50 семей с новорожденными детьми, были вручены подарочные пакеты (книги для малышей, памятки с советами по чтению). Родители ощутили внимание и заботу со стороны сотрудников детской библиотеки.

В целях привлечения детей в библиотеку сотрудниками детской библиотеки была организована фотогалерея «Малыши творят красками» (галерея детских рисунков, созданные детьми в возрасте от 0–7 лет). В мероприятии приняли участие и сельские библиотекари района со своими маленькими участниками. Всего в мероприятии участвовали 30 детей со всего района.

В детском и стационарном отделении детской больницы были установлены три книжных шкафчика – «Библиотечка для малыша».

Положительный результат реализации проекта «Расти с книгой, малыш» в том, что у большинства родителей и их детей проявляется устойчивый интерес к книге, они активно участвуют в мероприятиях, регулярно посещают библиотеку.

В том же году, участвуя в конкурсе Министерства образования и науки Республики Татарстан с проектом «Литературно-поэтический клуб одарённых детей «Зульфат», мы выиграли грант в размере 200 тысяч рублей. Возраст детей, на которых рассчитана реализация проекта: дети школьного возраста.

Целью данного проекта было выявить, раскрыть, помочь и содействовать развитию таланта среди детей, особенно – из малообеспеченных семей, детей сирот и детей-инвалидов. В результате реализации проекта были организованы встречи с писателями и поэтами района, проводились занятия, посвящённые азам стихосложения, мастер-классы по поэтическому искусству. По итогам проделанной работы был издан сборник стихов литературно-поэтического клуба одарённых детей «Зульфат» под названием «Кояшлы Ык» («Солнечный Ик») и тиражом 500 экземпляров.




*Хәзерге заман шартларында китапханә һәрвакыт камилләшеп торырга тиеш. Үсеш элементларының берсе – инновацион эшчәнлек. Үзәк китапханә хезмәткәрләре төрле конкурсларда, проектларда актив катнашалар. 2018 елда «Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү» конкурсында катнашып, китапханә 176 меңлек грантка ия булды. 2019 елда Россия Федерациясе Президенты проектлары конкурсында катнашып, шулай ук 334 мең сум грант оттык. Проект эше барышында «Пресс-банкет», «Ел укучысы», «Китап корты» һ. б. конкурслар, фестивальләр оештырылды.*



**_Лилия САДРИЕВА,_**
_җирлегебездә яшәп иҗат итүче шагыйрә, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, 2011–2018нче елларда Мөслим районының «Үзәкләштерелгән китапханә» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе җитәкчесе_

* * *

Күпме гыйлем, күпме серләр саклап
Киштәләргә китап тезелгән.
Күңелләргә күпме нур салынган
Олуг әдипләрнең сүзеннән.

Ташка баскан бу сүзләрдән башка
Яшәп булмас төсле бер көн дә.
Әйтерсең лә нурлы ызбалардан
Балачагым исе бөркелә.

Үтәр еллар, үтәр гасырлар да
Гөрләп килер ашкын язлары.
Җуелырлар эзләр, тарих саклар
Акка-кара белән язганны.

Буыннардан-буыннарга илтеп
Бәндәләрнең ниләр әйтерен
Шул китаплар сөйли бәйнә-бәйнә –
Китаплар ул гасыр хәтере...

Талчыкканда, рухи сусаганда
Китапханә назлап каршы алыр.
Күңелеңә мәңге җуелмаслык,
Аң-белемен, якты нурын салыр.

Стихотворение о библиотеке от поэтессы-землячки, члена Союза писателей РТ Лилии Садриевой. В 2011–2018 годах она возглавляла Муслюмовскую районную Централизованную библиотеку

**_Зилә КАШАПОВА,_**
_балалар китапханәсе мөдире_

_Балалар шуны белсеннәр иде. Бу кызыл сүзләр түгел. Китаптан беркайчан да аерылырга ярамый, чөнки китапларда иң бөек, иң кадерле, иң изге сүзләр язылган_
М. Әхмәтҗанов, балалар шагыйре

# Үзәк балалар китапханәсе тарихын барлау юлында

ЯШЬЛИ дөрес тәрбия алган, китап укырга, аны яратырга өйрәтелгән бала беркайчан да тайгак юлга басмас. Киләчәк буынны әдәпле-әхлаклы, белемле, киң эрудицияле кешеләр итеп тәрбияләү юнәлешендә башка тәрбия учаклары белән беррәттән балалар китапханәләре дистә еллар буена тырыш хезмәт куйганнар. Яшь буынны тәрбияләүдә гаилә, балалар бакчасы, мәктәп һәм иҗтимагый оешмаларның ныклы терәге һәм булышчысы булганнар.

Хисап битләреннән күренгәнчә, Мөслим район балалар китапханәсе егерменче гасырның 50 нче елларында ачыла. Китапханә Бакча урамындагы Тәүхидә Мәхмүтовалар гаиләсе яши торган 73 нче йортның бер бүлмәсенә урнаша. Балалар китапханәсенең беренче мөдире итеп Гайниямал Садыйкова билгеләнә.

Гайниямал Садыйкованың 1951 нче елда язган отчетында менә мондый юллар бар: «Балалар китапханәсенең укучы балаларны тәрбияләү өстендә төп эше, укучы массага мәдәни хезмәт күрсәтү юнәлешендә алып барыла. Бу бурычлар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: китап укучылар санын арттыру, мәдәният хезмәте күрсәтүне тиешле югарылыкка кую, укучылар өчен китап укучылар конференцияләре, әдәби кичәләр үткәрү, балаларга матур әдәбият белән беррәттән юлбашчыларның тормышын өйрәтү, авыл хуҗалыгы, техник


Гайниямал Садыйкова (1950–1951 нче еллар)


Гөлсинә Гарипова (1951–1952 нче еллар)


Әскыя Вәлиева (1952–1955 нче еллар)

китапларны пропагандалау бурыч итеп куелды. Беренче кварталда китапханәгә 771 укучы йөреп, аларга 9269 данә китап бирелде».

1952–53 нче елларда балалар китапханәсе зурлар китапханәсенә, ә 1953 нче елда Пушкин урамында урнашкан яңа агач бинага күчерелә. Китапханәнең бер бүлмәсендә китап фонды, икенче бүлмәсендә 80 урынга исәпләнгән уку залы, өченче бүлмәсендә мәдәният бүлеге урнаша.

1954 нче елның июль аеннан Мәдинә Хантимерова олылар китапханәсеннән балалар китапханәсенә эшкә күчә. Читтән торып Алабуга мәдәни-агарту училищесын тәмамлап кайткач, 1957 нче елның 25 нче августыннан балалар китапханәсе мөдире итеп билгеләнә.

1960 нчы елларның отчет битләреннән алынган мәгълүматларга карасак, китапханәнең китап фонды бибколлектордан (нәшриятлар белән элемтәдә торып) һәм китап кибетеннән сатып алынган китаплар белән тулыландырылган. Китаплар кабул итү белән, үз вакытында эшкәртелеп, классификацияләнгән, суммар һәм инвентарь кенәгәләренә исәпкә алынган. Китапханәдә алфавитлы һәм системалы каталоглар, газета-журналлар картотекасы алып барылган. Дублет китаплар авыл



*Балалар китапханәсе бинасы. 1950 –1988*

китапханәләренә таратылган.

Китапханәчеләр эти-әниләр, сыйныф җитәкчеләре, пионер оешмалары белән һәрчак элемтәдә торган. Мәктәпләрдә үткәрелгән ата-аналар җыелышларында балаларның китап уку күрсәткечләре, китапханәгә йөрүе, нинди китапларны аеруча яратып укулары хакында сөйли торган булганнар. Бердәм оештырылган чаралар мәктәп укучыларының интеллектуаль үсешен арттырган, әдәбиятка мәхәббәт уяткан.

Китапханәдә 7 кешедән торган совет эшләгән. Укучыларны җәйге чорда китап белән тәэмин итү йөзеннән профсоюз һәм «Киров» колхозы каршында оештырылган пионер лагерьларында укучылар өчен күчмә китапханәләр хезмәт күрсәткән.

ТАССР Министрлар советының 1974 нче елның 26 нчы декабрендә «Хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдә һәм фәнни-техника прогрессын үстерүдә китапханәчеләрнең роле» турындагы карары нигезендә 1977 нче елның 1 нче октябреннән район китапханәләре үзәкләштерелгән китапханәләр системасына берләштерелә.

Балалар китапханәсе дә әлеге үзәкләштерелгән китапханәләр системасына кертелә һәм алга таба балалар белән эшләүче методик үзәккә әйләнә, авыл китапханәләренә якыннан торып ярдәм итә башлый.

1988 нче елда балалар китапханәсе район мәдәният йортының икенче катында урнаша (адресы: Пушкин урамы, 42 йорт).

Балалар китапханәсе барлыгы 250 м$^2$ мәйдан били, уку залы 60 китап укучыга исәпләнгән. Китап фонды ул елны – 24138 данә тәшкил итә, укучылар саны – 2035.

1997 нче елдан балалар китапханәсен Сәхбетдинова Ханә Госсам кызы җитәкли. Ул тынгысыз хезмәткәр була. Аның кул астында эшләүчеләр дә нәкъ үзенә охшаганнар, аның кебек тынгысыз булып, бер генә минутларын да бушка уздырмыйлар, укыйлар, эзләнәләр, яңалыкка омтылалар.

Китапханәдә Ханә Госсам кызының җитәкчелеге астында нәни укучылар өчен Г. Тукайның «Шүрәле», «Кәҗә белән сарык» әкиятләре геройларының кызыл балчыктан матур итеп ясалган



*2012 елга кадәр Балалар китапханәсе урнашкан мәдәният йорты*



*Китапханәчеләр Х. Г. Сәхбетдинова, Р. Ф. Габдрахманова, Э. Г. Фатыйхова*



*Г. Р. Исәнбаева, А. В. Мадьярова, Э. Д. Мәгалимова, 2019 ел*



*Хәзерге көндә балалар китапханәсенең эчке күренеше*

сыннары, Бөек Ватан сугышына багышланган композицияләр ясала, балаларның күңелләрен җәлеп итәрлек китап күргәзмәләре эшләнә.

Китапханә каршында балаларның ялын файдалы үткәрү максатыннан төрле кызыклы түгәрәкләр: «Китап сөючеләр», «Оста куллар», «Сәйлән» драмтүгәрәге эшли башлый. «Оста куллар» түгәрәгенә йөрүче балаларның кул эшләреннән (кәгазьдән, картоннан ясалган, чигелгән, бәйләнгән, тегелгән уенчыкларыннан) күргәзмә оештырыла.



«Сәйлән» драмтүгәрәгенә йөрүче балалар белән Г. Бакирның «Серле йомгак», Г. Нәбиуллинның «Харис бабайлар өендә!» татар халык әкиятләре буенча сәхнәләштерелгән «Кабартма» пьесалары нәни тамашачыларга күрсәтелә.

2012 нче елның март аеннан балалар китапханәсе үзәк китапханә бинасына күчерелә (Пушкин урамы, 35 йорт).

Хәзерге көндә балалар китапханәсе модельле-мәгълүмати, мәдәни һәм ял итү функцияләрен үти. Китапханә фондында 19582 данә китап исәпләнә, китап укучылар саны 2104 тәшкил итә, шул исәптән 1746 сы – 14 яшькә кадәрге балалар.

Балалар китапханәсенең үзәк китапханә бинасына күчүе төрле буын китап укучыларына зур уңайлыклар тудырды. Балалар әти-әниләре, әби-бабайлары белән бергә китапханәгә йөри алалар.

Китапханә заманча җиһазландырылган, зәвык белән бизәлгән. Биредә укучыларга дәрестән соң килеп, китап укырга, өй эшләрен эшләргә, яшьтәшләре белән төрле уеннар уйнарга, ял итәргә мөмкинлекләр тудырылган.

Китапханәдә бик күп мавыктыргыч чаралар уза, тематик кичәләр, бәйгеләр, очрашулар үткәрелә. Моннан тыш төрле түгәрәкләр дә эшли: «Рәсем», «Тылсымлы пластилин», кәгазьдән уенчыклар ясау сәнгате буенча «Оригами» түгәрәкләре.

Төрле сәбәпләр аркасында сәламәтлек мөмкинлеге чикләнгән балаларга, коррекция мәктәбендә тәрбияләнүче балаларга китапханәчеләр аерым игътибар бирә. Балалар китапханәсе каршында мондый балалар өчен квестуеннар, кызыклы викториналар, кычкырып укулар оештырыла.

Үсеп килүче буында китапка карата хөрмәт тәрбияләгәндә, туган якка ихтирам белән карaганда, милли мәдәниятебезне һәм традицияләребезне саклап, үз өлешебезне керткәндә, киләчәгебез якты һәм ышанычлы булачак. ■

*Ребенок, который с малых лет правильно воспитан, любит читать книги, в жизни никогда не оступится. Воспитать детей образованными, эрудированными – миссия библиотекарей.*

*Муслюмовская районная детская библиотека открылась в 50 годы 20 века. Первым директором этой библиотеки была Гайниямал Садыйкова. И в то время цель библиотеки была увеличить число читателей, усовершенствовать обслуживание, провести конференции, литературные вечера и т. п.*

*В 1960 годы в библиотеки ввелись алфавитные и систематические каталоги, картотеки газет-журналов.*

*В 1977 году детская библиотека вошла в состав Централизованной библиотечной системы. И со временем превратилась в методический центр, занимающийся детьми.*

*Сейчас в библиотеках для детей проводятся увлекательные кружки как «Любители книг», «Умелые руки» и др. Есть все возможности для чтения, отдыха и развития.*

***Дилбәр КАШАПОВА,***
*китап туплау һәм эшкәртү бүлеге китапханәчесе*

***Дильбар КАШАПОВА,***
*библиотекарь отдела сбора и обработки книг*



# Күпкырлы талант иясе

**ЯКТАШЫБЫЗ, БАЛАЛАР ШАГЫЙРЕ М. ӘХМӘТҖАНОВНЫҢ 70 ЯШЬЛЕК ЮБИЛЕЕ УҢАЕННАН**

МӨСЛИМ ягы талантларга бик бай. Монда танылган язучылар, күренекле шагыйрьләр, атказанган артистлар, композиторлар туып үскән. Алар үзләренең иҗатлары белән татар сәнгать дөньясын баеталар һәм туган ягыбыз данын еракларга тараталар. Шундый шәхесләрнең берсе – туган төбәгебез Мөслимдә яшәп, иҗат дәрьясында кайнаучы һәм күп кенә китаплар авторы, балалар шагыйре Мөҗәһит Әхмәтҗанов. Абдулла Алиш, Сажидә Сөләйманова исемендәге бүләкләр иясе, халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы, 1995нче елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Мөслим районының мактаулы гражданины Мөҗәһит Әхмәтҗанов гаиләсе җирлегебез өчен үрнәк.

Әхмәтҗанов Мөҗәһит Заһит улы 1950нче елның 15 нче декабрендә Мөслим районы, Түреш авылында туган. 1968нче елда Күбәк урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1968–1973нче елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты

# Обладатель многогранного таланта

**К 70-ЛЕТИЮ ЗЕМЛЯКА, ДЕТСКОГО ПИСАТЕЛЯ М. АХМЕТЗЯНОВА**

МУСЛЮМОВСКАЯ земля богата талантами. Здесь родились и работают известные писатели, поэты, заслуженные артисты, композиторы... Своим творчеством они обогащают мир татарской культуры и прославляют свой родной край. Один из них – Музагит Ахметзянов, проживающий в Муслюмове, автор многих книг, детский поэт. Он – лауреат премий имени Абдуллы Алиша и Сажиды Сулеймановой, кроме того – Заслуженный учитель Татарстана, Почётный гражданин Муслюмовского района...

Ахметзянов Музагит Загитович родился 15 декабря 1950 года в селе Тюреш Муслюмовского района. В 1968 году он окончил Кубяковскую среднюю школу, 1968–1973 годах учился в Казанском государственном университете на отделении татарского языка и литературы. Прослужив офицером Советской Армии два года на Дальнем Востоке, вернулся в свой родной район. В течение шести лет работал в районных комитетах комсомола, партии. С 1982 года был назначен директором Муслюмовской средней школы. Занимал эту должность до 1995 года. И после ухода на заслуженный отдых Музагит Ахметзянов продолжает жить активной жизнью. Выпускает одну книгу за другой.

Музагит Ахметзянов – поэт, посвятивший своё литературное творчество детям. Он начал писать стихи ещё в школьные годы. Его первые творческие произведения были напечатаны в районной газете, республиканской «Яшь Ленинчы» (ныне «Сабантуй»), а также на страницах журнала «Ялкын». В 1993 году вышла его первая книга – сборник стихов для детей младшего школьного возраста «Я учусь считать». Каждая строка стихотворений Музагита-



*Тормыш иптәше Бания ханым белән*



*Выставка книг*

бүлегендә югары белем ала. Ерак Көнчыгышта офицер дәрәҗәсендә ике ел хәрби хезмәттә булып, туган районына эшкә кайта. Алты ел дәвамында районның комсомол, партия комитетларында эшли. 1982 нче елдан Мөслим урта мәктәбенә директор итеп билгеләнә. 1995нче елга кадәр шул вазыйфаны алып бара. Лаеклы ялга чыккач та, Мөҗәһит Әхмәтҗанов актив тормыш белән яшәвен дәвам итә. Китап арты китап әзерләп чыгара.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов әдәби иҗатын балаларга багышлаган шагыйрьләрдән. Ул мәктәптә укыган елларында ук шигырьләр яза башлый, аның беренче иҗат җимешләре район газетасында, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында һәм «Ялкын» журналы битләрендә басыла. Ә 1993нче елда аның беренче китабы – кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Мин санарга өйрәнәм» дигән шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Мөҗәһит абый шигырьләренең һәр юлында балаларны яратуы, җылылык, ихласлык бөркелеп тора. Ул ел фасылларының үз ямен, тәмен таба белә, һәр агачның, кошның сулышын тоя. Аның абый веет любовью к детям, теплотой, искренностью. Он умеет находить свою необычную красоту во всех временах года, ощущает дыхание каждого дерева, птицы... В его стихах слышится искренний смех малышей, чувствуются тонко уловимые настроения школьников.

Поэт умеет находить неожиданные смыслы в обыденных вещах, видеть то, что мы обыкновенно не замечаем. А ещё Музагит-абый сочиняет остроумные загадки. Нам хорошо известнен написанный для детей его сборник загадок «Тапкырлар тапмый калмас» («Находчивые найдут»), «Зирәк булу кирәк» («Нужно быть смекалистым»), «Акыллыга сүз әйттем» («Слова для умных»).

Книги «Очты, очты...» («Полетели, полетели...», 2000), «Акыллыга сүз әйттем» («Слова для умных», 2012) покорили детские души и на конкурсе «Книга года» для детей заняли второе место. А книга «Баллы җәй» («Медовое лето», 2016) вышла на третье место.

Вместе с супругой Банией-апой они вырастили троих сыновей. Именно об их детях можно сказать, что они нашли своё место в жизни. Сегодня Музагит-абый



*Оныклары белән*



*С внуком и внучкой*

шигырьләреннән мәктәп укучыларының елмаюын тоеп, сабыйларның ихлас көлгән тавышларын да ишеткәндәй буласың.

Гади генә әйбердән дә мәгънә таба, без күрмәгәнне күрә белә әдип, табышмаклар иҗат итә. Балалар өчен язылган «Тапкырлар тапмый калмас», «Зирәк булу кирәк», «Акыллыга сүз әйттем» табышмак җыентыклары һәркемгә яхшы таныш.

«Очты, очты...» (2000), «Акыллыга сүз әйттем» (2012) китаплары, балалар күңелен яулап, «Ел китабы» конкурсында икенче урынга, «Баллы җәй» китабы (2016) өченче урынга лаек булды.

Тормыш иптәше Бания апа белән алар өч ул тәрбияләп үстерделәр. Тормышта үз урыннарын тапкан дип нәкъ менә аларның балалары турында әйтергә була. Бүгенге көндә Мөҗәһит абый белән Бания апа оныкларына тәрбия бирүдә зур өлеш кертәләр.



Инструменты всякие нужны

Оныгы Булат: «Әбием белән бабам мине укырга, язарга, тәрбияле булырга өйрәттеләр. Бабам уйнаган барлык уен коралларында уйный белүем – бабамның үрнәге нәтиҗәсе», – ди. Ә оныгы Алинә: «Минем бабам безгә багышлап күп кенә шигырьләр иҗат итә, һәм без оныкларына багышлап, укырга кергәндә, китап язып бүләк итә. Без ул китапларны кадерләп саклыйбыз, андагы шигырьләрне яттан сөйләп йөрибез», – ди.

*Улым Айдар китте минем юлдан,*
*Оныкларым мине кабатлый.*
*Булат уйный, Зөлфәт очып бии,*
*Алинәбез яңа җыр ятлый...*
*Барыбыз да сәнгать яратабыз,*
*Барыбыз да бүген сәнгатьтә.*
*Сәхнәләрдән төшәр исәп тә юк*
*Һәм әле юк аңа сәбәп тә.*

(М. Әхмәтҗанов)

Балалар бакчаларында, мәктәпләрдә узучы нинди генә чараны алма, сабыйлар аның шигырен яттан сөйли. Ник дигәндә, балалар теле белән язылган шигырьләре җиңел укыла, җиңел истә кала, тәрбияви мәгънәдә булуы белән аерылып тора. Ул шигырьләр балаларга гына түгел, укытучы коллегаларын да истә тотып, дәрестә куллану өчен менә дигән чыганак буларак иҗат ителгәннәр. Күп кенә татар теле дәреслекләрендә шигырьләре, табышмаклары урын алган.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов тынгысыз шәхес, балалар иҗаты белән генә чикләнми, аның иҗат тематикасы киңкырлы. Башка өлкәләргә багышланган китаплары да бик күп.



На сцене, на конкурсе...

и Бания-апа много внимания уделяют воспитанию внуков. Его внук Булат говорит: «Бабушка и дедушка научили меня читать, писать, играть на музыкальных инструментах». А внучка Алина сказала: «Мой дедушка сочиняет хорошие стихи, посвященные нам. Когда мы поступаем учиться, он пишет книгу и преподносит с дарственной надписью. Мы бережно храним эти книги, читаем вслух и наизусть стихи из них».

Какое бы мероприятие ни проводилось в детском саду ли, в школах, в районном Доме культуры, дети по памяти читают стихи Музагита Ахметзянова. А всё потому, что стихи его написаны на доходчивом детском языке, легко читаются и запоминаются. Они востребованы и среди коллег-учителей для использования на уроках. Немало учебников татарского языка содержат его замечательные стихи и загадки.

Музагит-абый Ахметзянов не ограничивается только лишь детской поэзией и загадками, его творческая



О чём задумался поэт?



*Шагыйрь музеенда*



*В музее поэта*

Аның гарәп хәрефләрен өйрәнүчеләр өчен «Гарәп графикасы нигезендә элекке татар язуы», «Күңел нуры» исемле уку әсбаблары, дини эчтәлектәге «Иман нуры», «Яшәү яме» шигырь китапларын күпләр яратып укый.

Якташыбыз, ике сугыш ветераны, күренекле фольклорчы Зариф Мөәминовның 600 битлек иске гарәп язуы белән язылган китабын да кириллицага күчерде районзашыбыз. Соңыннан аны Факил Сафин редакциялəп, кульязма «Мажара» китабы булып дөнья күрде.

Мөслим авылындагы мәчетләр, мәдрәсә, мәктәпләр тарихына багышланган «Кыңгыраулы мәктәп еллары», «Күбәгем – туган төбәгем», «Мәктәп хатирәләрем», Мөслим районындагы фольклор ансамбльләре турындагы «Мөслимем җәүһәрләре», «Сүнмәс дәрт» китаплар авторы. Күптән түгел районддагы музыка мәктәбенең 50 еллыгына багышлап язылган «Сәнгатьтә сынала-быз» китабы да дөнья күрде.

Мөҗәһит Заһитович туган авылын, туган җирен, туган телен ихлас яратучы шәхес. Авыл тормышының матурлыгы, аның кешеләре «Түрешем», «Авылым хатирәләре», «Сандугач оям минем», «Авылдашлар», «Данлы Дусай» китапларында чагыла.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов иҗат иткән брошюралар: Мөслим төбәгеннән чыккан каләм ияләре турында биографик белешмә «Якташ әдипләребез», »Әхлак белеме», «Багышлаулар, котлаулар», «Мөслим энҗеләре», »Васил Әхмәтҗанов», «Әхмәтҗанов Мөҗәһит белән Бания шәҗәрәсе», «Бәйрәмнәр котлы булсын».

Ходай аңа сәләтнең барысын да өеп биргән, кешеләрне сокландыра торган асыл затларның берсе итеп яраткан, музыкаль белеме булмаса да, өздереп баянда, гармунда, курай, кубыз, таш сыбызгы,сорнай кебек уен коралларында уйный.

тематика весьма обширна. Немало книг он посвящает другим областям человеческой жизнедеятельности. Многие с удовольствием читают его учебные посо-бия «Гарәп графикасы нигезендә элекке татар язуы» («Старинная татарская письменность на основе арабской графики»), «Күңел нуры» («Луч души») для изучающих арабскую письменность, книги стихов религиозного содержания «Иман нуры», «Яшәү яме»...

Наш земляк перевёл с арабского на кириллицу 600-страничную книгу ветерана двух войн, известно-го фольклориста Зарифа Муэминова. Представляют собой интерес и публицистика, и краеведческие из-дания, и брошюры о земляках-писателях...Недавно вот вышла в свет книга «Сәнгатьтә сыналабыз», посвященная 50-летию музыкальной школы района.

Музагит Загитович – человек, искренне любящий родную деревню, родную землю, родной язык. Красота сельской жизни, судьбы сельчан отражены в его книгах «Турешем» («Моё Турюшево»), «Авылым хатирәләре» («Воспоминания о моей деревне»), «Сандугач оям минем», («Соловьиное гнездо моё»), «Авылдашлар» («Односельчане») , «Данлы Дусай» («Славный Дусай»).

Кроме литературного дарования наш именитый земляк наделён и музыкальными способностями. Он хорошо играет на баяне, гармонике, на таких инструментах, как курай, кубыз, каменный свисток, сорнай, является бессменным музыкантом народного фольклорного ансамбля «Мөслим тугайлары» («Мус-люмовские долины»). Он участвовал в фольклорных фестивалях, проходивших в Казани, Чебоксарах, Нижнем Новгороде, Баку, где покорял любителей музыки игрой на различных инструментах. Понятно, что в районном Доме культуры ни один концерт, ни один вечер не проходит без его участия.

У Музагита-абый Ахметзянова есть свой сайт, в котором содержится немало информации о Муслю-мове, его писателях, выдающихся людях, а также, естественно, его стихи, предания, фотографии.

Авторның табышмаклар иҗат итүе очраклы түгел. Ул – «Мөслим тугайлары» исемле халык фольклор ансамбленең алыштыргысыз музыканты. Казан, Чабаксар, Түбән Новгород, Баку шәһәрләрендә узган фольклор фестивальләрендә төрле уен коралларында сокландыргыч чыгыш ясады. Укучылар белән очрашуларда да милли уен коралларыбызны пропагандалый.

«Сүнмәс дәрт» ветераннар клубының актив әгъзасы. Район мәдәният йортында бер генә концерт, кичә дә аның катнашыннан башка үтми диярлек.

Мөҗәһит Әхмәтҗановның үз сайты да бар: «Мөҗәһит» «muzagit. ru». Анда Мөслимебез, аның язучылары, күренекле кешеләре турында бик күп мәгълүмат тупланган. Үзе иҗат иткән шигырьләре, шәҗәрәләре, тугралары һәм фотокүргәзмәсе дә урын алган.

Элек өй түрендә гаилә мөһере – тугралар торган. Мөҗәһит абый да әби-бабаларыбыз гадәтенә тугры калып, һәр гаилә әгъзасына гарәп хәрефләре, матур төсләр, һәркайсына үзенә генә хас бизәкләр белән тугралар эшләп куйган.

Мөҗәһит абый район тормышында да актив катнаша. Җәмәгать эшләре дә җитәрлек. Ул яшьтән үк художестволы фотография, кино төшерү сәнгате белән дә мавыга, күпсанлы видеофильмнар, аудиоязмалар авторы. Мөслимебездә гөрләп үткән бәйрәмнәрне, төрле истәлекле вакыйгаларны кино тасмасына елъязма итеп төшергән: «Туган ягым Мөслимем», «Бәхетле булыгыз», «Безнең бәйрәмнәр» һәм башкалар. Гарәп графикасы өйрәнүчеләр өчен үз тәҗрибәсеннән чыгып, Татарстан Мәгариф министрлыгы белән берлектә эшләнгән диафильмы республика буенча таралды. Ул шөгыльләрен әле дә ташламаган. Аның шәхси архивында – мәктәп тарихы, туганнарының, дус-ишләренең, якташларының яшьлеге, туган җиренең гүзәл табигате.

Менә шушындый зур хезмәтләр башкарып та, тыйнаклыгы белән сокландыра шагыйрь! Чыннан да, аның кешене сокландырырлык талантлары аз түгел. Ул балалар ярата торган укытучы булуы өстенә, күп төрле һөнәргә ия. Ходай аңа сәләтнең барысын да өеп биргән, кешеләрне сокландыра торган асыл затларның берсе итеп яраткан. Мөҗәһит Әхмәтҗанов чын мәгънәсендә хөрмәтле шәхес, хөрмәтле укытучы, үрнәк гаилә башлыгы югары дәрәҗәдә зурланырга тиеш. Шушындый кеше белән бер җирлектә яшәү – үзе зур бәхет ул! Гадилеге белән зыялы булган шәхес – Мөслимебез өчен тиңсез хәзинә. ■



*В Национальной библиотеке РТ. М. Ахметзянов – справа*

Раньше в домашнем обиходе нашего народа употреблялась семейный герб-тугра. И Музагит-абый остался верен традициям наших предков, своими руками создал для членов семьи персональные тугры, украсив их арабскими буквами, красивыми узорами – это настоящие произведения искусства.

С ранних лет Музагит-абый увлекался художественной фотографией, киносъёмкой... Он – автор многочисленных видеофильмов, аудиозаписей. Диафильм для изучающих арабскую графику, созданный им совместно с Министерством образования Татарстана, был распространён по всей республике. В его личном архиве и на сайте бережно хранятся многие события, происходившие в районе, история школы, молодость и жизнь родственников, друзей, земляков, прекрасная природа родной земли.

Действительно, немало достоинств у нашего талантливого земляка. Несмотря на это он остаётся очень скромным человеком. Жизнь в одном поселении с ним – большое счастье. Долгие лета, дорогой Музагит Загитович! ■



*Музагит Ахметзянов беседует с художественным руководителем районного Дома культуры Эльвирой Гараевой*

*Альбина РОМАНОВА,*
*Яңа Усы авылы китапханәчесе*

# Яңару юлында
# Яңа Усы авылы китапханәсе

КЕШЕЛЕК дөньясы тарих дәвамында күпме тәҗрибә туплаган булса, барысы да китап киштәләрендә урын алган. Китапханә – серле дөнья, китапханәче – шул серне чишәргә ярдәм итүче. Китапханәгә укучылар тарту, укучыларның зәвыгын өйрәнү, китапны, вакытлы матбугатны, башка төр басма әсәрләрне халыкка җиткерү, халыкның укуга булган ихтыяҗын канәгатьләндерү, матур әдәбиятка кызыксыну һәм иң мөһиме: балаларда китапка карата мәхәббәт уяту ул – безнең китапханәчеләрнең төп бурычы булып тора.

Безнең һәр көнебез яңалыклар белән тулы. 2020 нче елда Яңа Усы авылы халкы өчен бик тә сөенечле вакыйга булды. Мәдәният йортында һәм шул ук бинада урнашкан китапханәдә, музейда капиталь төзекләндерү эшләре башкарылды. Җиде ай эчендә авыл мәдәният йорты танымаслык булып үзгәрде. Мөслим хуҗалыкара төзелеш оешмасы бинаның түбәсен алыштырды, фасадын, диварларын ремонтлады. Яңа ишек-тәрәзәләр куелды, җылылык, электр системалары алыштырылды.

Авылның нәкъ уртасында урнашкан мәдәният йорты бүген әллә каян балкып тора. Музейда борынгы экспонатлар, кульязмалар урын алган.

Ремонт барышында җирлек халкының да ярдәме зур булды. Территорияне чистарту, чәчәкләр утырту – уңган егет-кызларыбызның хезмәте.



*Китапханәче А. Н. Романова*

Мәдәният йорты ачылу тантанасында мәдәният министры Ирада Хафизян кызы Әюпованың катнашуы ямь өстенә ямь өстәде.

– Шәхес тәрбияләүдә сәнгатьнең, мәдәниятнең зур роль уйнавын, күрсәтеп, аңлатып бирү – безнең төп бурычыбыз. Яшь буын тәрбияле, зыялы булып үссен өчен шартлар тудыру мөһим. Авыл клублары, мәдәният йортлары, китапханәләр арадашчы ролен үти. Иҗади яктан үсәр өчен төрле чараларда актив катнашу гына түгел, әлеге чараларга, бәйрәмнәргә үзеңнән дә өлеш кертү зарур. Балаларыбызны мәдәнияткә тарту кечкенәдән башланса гына, уңышлы булачак, – диде министр.

Ирада Әюпова Яңа Усы мәдәният йортының матди-техник базасын яңарту өчен 100 мең сумлык сертификат тапшырды һәм бинаның алга таба да халыкка матур итеп хезмәт күрсәтүен теләде.

Китапханә дигән тылсымлы йортка авыл халкы бик яратып йөри. Анда килеп керү белән, уку залында тудырылган җылы мохит, чисталык үзенә җәлеп итә. Китап сөючеләр өчен барлык шартлар да тудырылган – компьютерлар белән тәэмин ителгән, интернет челтәренә тоташтырылган. Мәктәп укучысымы син, студентмы, өлкән буын вәкилеме – һәр төркем өчен дә аерым бүлек булдырылган.

Китапханәдә туган илебезгә, районыбызда яшәп, иҗат иткән әдипләребезгә, шагыйрьләребезгә багышланган күргәзмә-стендлар эшләнеп куелган. Туган авылыбызга багышланган күргәзмә төп урынны алган. Язучыларга багышланган күргәзмәләр, язучыларның тормышы һәм иҗаты, яңа китаплары белән таныштыра. Рәт-рәт итеп тезелгән китаплар ерак илләргә алып китәрләр, биек күкләргә менгерерләр, күп нәрсәләрнең серенә төшенергә ярдәм итәрләр.

Китапханә Яңа Усы авылыннан тыш, Бикмәч һәм Горбуновка авылларына хезмәт күрсәтә. Елдан-ел яңа китаплар, газета-журналлар белән баетылып тора. Китап фондында 10802 данә китап һәм газета-журнал исәпләнә, шул исәптән 4621 данәсе балалар өчен китаплар. Китап укучылар саны 501.

Җирлегебездә татар, керәшен һәм рус халкы дус-тату һәм матур итеп яши белә. Керәшен татарлары иҗатчыл һәм фольклорга бай халык, аларның үзләре иҗат



*Мәдәният министры Ирада Әюпова.*
*Мөслим муниципаль районы башлыгы Рамил Муллин*



*Яшь укучыларга китапханәдә бик ошый*

иткән бик матур җырлары һәм йолалары бар. Шушы иҗатчыл өлкәннәребез, яшьләребез һәм балаларыбыз ярдәме белән бергәләп халкыбызның буыннан-буынга килгән милли бәйрәмнәре: Май чабу, Нәүруз, Питрау, Сабантуе җирлегебездә гөрләп үтә.

Өлкән буын вәкилләре өчен «Ветеран», «Оста куллар», балалар өчен «Час в библиотеке», «Китап докторы» түгәрәкләре, «Салават күпере» бию төркеме эшли.

Китапханәдә ачык ишекләр көне, балаларга экскурсияләр



*«Салават күпере» бию төркеме*

үткәрү, төрле темалар аша китапның кирәклеген китап укучыларга җиткерү, «Үзең укыган китапны – китапханәгә бүләк ит», «Бәхетле формуляр», «Иптәшеңне китапханәгә алып кил», «Йортларга – китап нуры» акцияләре һәрвакыт үтеп тора.

Мәктәп укучыларында китапка мәхәббәт тәрбияләү, белемнәрен тирәнәйтү ниятеннән чыгып мәгълүмати дәресләр, төрле әдәби кичәләр, викториналар, уеннар оештырыла. Яшүсмерләр өчен наркомания, СПИД кебек яман авыруларны булдырмау йөзеннән,ел дәвамында «Наркомания афәт ул», «Моны һәркем белергә тиеш» дигән күргәзмәләр урын алып тора.

Эстетик тәрбиянең нигезен нытыту өчен дә көч күп куела. Татар язучылары һәм шагыйрьләренең түгәрәк даталары алдан планлаштырылып, күргәзмәләр, китап укучылар конференцияләре оештырыла. Төбәгебездә яшәп иҗат итүче язучыларны чакырып эчтәлекле чаралар уздырыла. Китапханәбездә якташыбыз, шагыйрә Лилия Садриева, язучы, шагыйрь Мөҗәһит Әхмәтҗанов иҗатына багышланган очрашулар бигрәк тә китап сөючеләрнең күңелен рухландырды.

Бөтен республикабызның мәдәният учакларын, китапханәләрен бер уч итеп тоткан мәдәният министрлыгы, башкаладан 319 чакырымда урнашкан Усыбызның эш күрсәткечләрен бәяләп 100 мең сумлык сертификат биргән икән, димәк, безнең эшебезне күрәләр, бәялиләр. Бу безгә киләчәккә өмет уята һәм яңа эш алымнары кулланып эшләргә көч бирә.

Алга таба да авылым халкының аң-белемен арттыруга, аларның күңеленә рухи нур өстәү өчен бар тырышлыгымны куярмын. Мин шундый ышаныч, өмет белән яшим, чөнки кеше язмышында, китап гаять зур урын алып тора.

■

*В 2020 году в культурной жизни деревни Новые Усы Муслюмовского района РТ произошло важное событие – после капитального ремонта было открыто здание местного Дома культуры, в котором расположены библиотека и музей. На церемонии открытия обновленного здания Дома культуры присутствовала министр культуры республики И. Х. Аюпова, которая вручила сертификат на сумму 100 тыс. рублей.*

*Библиотека проводит активную работу по продвижению национальной культуры кряшен, русского и татарского народов. Работают кружки – «Умелые ручки», «Ветеран», «Час в библиотеке», «Радуга», «Книжкин доктор» и др.*

*Во взаимодействии со школами ведется работа по формированию здорового образа жизни, эстетическому и патриотическому воспитанию.*

***Фоат САДРИЕВ,***
*Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе,*
*Татарстанның Халык язучысы*

# Китапханәче җаваплылыгы

КИТАПХАНӘГӘ, китап кибетенә мин балачактан ук тыныч кына керә алмадым. Карыны ачкан кеше берсеннән-берсе тәмле ризыклар уртасында калгандай, күз әле берсенә, әле икенчесенә йөгерә. Өч-дүрт китапны култык астыңа кыстырып, куана-куана өйгә атлаулары ни тора! Иң элек ул китапларның рәсемнәрен карап чыгасың, иң кызыктырганын укый да башлыйсың. Ничәнче сыйныфтадыр, кышкы каникулда Жюль Вернның «Су астында сиксән мең километр» дигән китабы мине су асты көймәсенең серле дөньясына алып кереп китте. Бер көнне иртүк җылы мич башына менеп утырып, шул дөньяның мажараларына чумдым. Бервакыт мич алдында нидер пешереп йөрүче әнкәйнең тавышын ишетәм:

– Улым, Факияттигә бал кертеп чык әле.

– Ярар, – дим, үзем китаптан аерыла алмыйм, ә вакытның үткәне сизелми дә.

Әнкәйнең «кертеп чык» дигәнен тагын ишетәм. Ничә кабатлагандыр, соңгысында тавышның шактый кискен яңгыравы мине айнытып җибәрде. Ярты литрлы банкага тутырылган балны йөгерә-йөгерә Факияттиләргә кертеп бирдем. И, сөенде күрше әбием, аркамнан сөеп, кесәмә берничә уч чикләвек тә салды. Бусы инде бик сирәк эләгә торган нәрсә. Чөнки безнең авыл тирәсендә урман юк. Мәче


*Фоат Садриев*

җитезлеге белән җылы мич башына үрмәләп, чикләвек яра-яра, кабат су асты дөньясына чумдым. Шунда су өстеннән әнкәйнең тавышы ишетелде:

– Чикләвек кайдан алдың, улым?

– Факиятти бирде, – дим чикләвек төшен чәйни-чәйни.

– Анда ник кердең?

– Бал керттем.

– Ай, аңгыра! – ди әнкәй ачулы тавыш белән. – Мин сиңа Фәрхиҗиһан тутаңа кертергә куштым. Хәзер үк алып чык!

Бөтен тәнемне нидер куырып алды. Ничекләр алып чыгыйм?! Ул бит миңа әллә нинди рәхмәтләр укыды.

– Кермим...– дип мыгырдыйм борын астыннан.

– Алып чык! – диде әнкәй тавышын күтәреп. – Ул бит дару өчен юллап табылган бал.

Ничек керим?! Ничек керим?! Ике битем ут яна башлады.

– Алып чык дим...

Их, су астына гына чумып юк булсаң иде хәзер!

Шул чак минем бәхеткә якын туганыбыз Тәзкирә апа килеп керде. Ул балны алып чыгып, Фәрхиҗиһанттиләргә кертеп бирде. Өстемнән тау төшкәндәй булды.

Мондый хәлләр минем китапка булган мәхәббәтемне сүндерә алмады, әлбәттә. Гомерем буе китап җыйдым, аларны үзем дә укыдым, башкалар да рәхәтләнде. Язмышыма язылган булгандырмы, 1959 нчы елда мине туган авылым китапханәсенә мөдир итеп куйдылар һәм мин анда төп-төгәл дүрт ел эшләдем. 1992 нче елда район үзәкләштерелгән китапханәләр системасына директор итеп чакыргач, тагын дүрт ел бу вазыйфаны башкарырга туры килде. Моны искә төшерүем юкка түгел. Гомер буе идеология фронтында, культура тормышының уртасында кайнаган кеше буларак, кайбер уй-фикерләремне китапханәчеләр белән уртаклашырга хакым бар дип уйлыйм.

Сүземне бер бик җитди үзгәрештән башлау хәерле булыр сыман. Совет халкы дөньяда иң күп

укучы халык дип без бик күп еллар горурланып яшәдек. Бу чыннан да шулай иде. Патша Россиясендә 1897 нче елгы җан исәп буенча укый-яза белмәүчеләр 76 процент тәшкил итә. Ә хатын-кызларның 88 проценты надан була. Россиядәге халыклар кебек мәгариф һәм белем яктылыгыннан мәхрүм ителгән кыргый дәрәҗәдәге ил Европада башка юк, дип яза Ленин. Статистлар Европа дәрәҗәсенә җитү өчен Россиягә 120 ел, Кавказ белән Себергә 430, Урта Азиягә 4600 ел кирәк булачак дип фаразлыйлар. Әле 1913 нче елда да Ленин балаларның һәм яшүсмерләрнең биштән дүртесенең укудан мәхрүм ителүен күрсәтә. Караңгылыкның очы да, кырые да күренмәслек тоела. Әмма могҗиза була. Октябрь революциясеннән соңгы 20 елда Советлар Союзы тулысынча укый-яза белүче илгә әверелә. Бу тарихи вакыйга гасырлар буе караңгылыкта мәҗбүри томалап тотылган халыкның күңелендә никадәр көч тупланауын, яктылыкка омтылышының сүнмәслеген бөтен дөньяга күрсәтте. Наданлыкны бетерү курсларыннан, изба-читальнялардан башланган хәрәкәт океандай зур илне галәм биеклекләренә күтәрде. Китапханәчеләр дә грандиоз эшчәнлекнең үзәгендә кайнадылар. Китапханәләр хәтта Бөек Ватан сугышы елларында да ябылмады. Ни аяныч, үткән гасырның туксанынчы елларында халыкның укуга омтылышы кискен кими башлады. Миллионлаган тиражлар белән чыгып килүче китаплар, газета-журналлар ташкыны туктады, чөнки аларны алучылар бик азайды. Дөньяда иң күп укучы халыкка ни булды соң? Әлбәттә, монда телевидениенең, интернетның, телефон, смартфон, планшет кебек гаджетларның да роле зур. Алар ярдәмендә бик күп нәшриятларның фәнни-популяр һәм әдәби продукциясе белән танышып була. Китап укучылар саны чит илләрдә дә кими. Ләкин бу тенденциянең көчәюе Россиядә социалистик системаның җимерелүе, илнең капитализмга күчүе белән аерылгысыз бәйле. Рухи кыйммәтләр артка этәрелде, акча, матди кыйммәтләр беренче планга чыкты. Совет системасы коллективизм идеяләре белән сугарылган булса, хәзер индивидуализм, шәхси милек туплау, лидер булу, теләсә нинди юллар белән максатка ирешү алга куела. Эшсезлек, хезмәт хакының артмавы, инфляция, коммуналь түләүләрнең, вузларда, техникумнарда укуның коточкыч кыйммәтләнә баруы рухи омтылышларны, югары идеалларга табынып яшәүне рәхимсез кысты. Азык-төлек, кием-салым, транспорт, бензин һәм башка киң куллану товарларының бәяләре өзлексез үсеп торганда, халыкның яшәү мотивлары да үзгәрә, прагматизм торган саен кинрәк колач җәя. Кеше яшәү шартларына яраклашырга мәҗбүр. Шулай булмаса, ул яши алмаска мөмкин. Ничек акча күбрәк юнәтеп була – бәндә шул эшкә омтыла. Хәтта үзе яратып сайлаган, гомере буе хыялланган һөнәрен ташларга мәҗбүр. Минем таксист булып эшләүче врач, инженер белән очрашканым бар. Аларның җаваплары югарыда әйтелгәнчә иде. Моның аяныч ягы шунда, әлеге кешеләр үз рухларын, җаннарын изәләр бит! Врачның күзеннән яшьләре генә чыкмый. Мин һәркөн рульгә утырганда, үземне җинаятьче кебек тоям, ди. Димәк, ул көн саен көчле стресста яши. Һөнәр сайлаганда, балаларына, якыннарына нинди киңәш бирер ул? Акчаны, байлыкны абсолют кыйммәткә әвереледерүче җәмгыятьтә шәфкатьлелек, хакыйкать, дуслык, мәхәббәт, намусвөҗдан, патриотизм, коллективизм кебек әхлак сыйфатлары да кимүгә бара.

Шушыңа бәйле рәвештә мине яшь буын язмышы борчый. Бездә элекке кебек халык массалары арасында тәрбия эше алып баручы партия, комсомол, профсоюз оешмалары, агитколлективлар да, бүтән җәмәгать ячейкалары да юк. Тәрбия эшенең чыганагы булып мәгариф, мәдәният һәм дин калды. Телевидениенең яшьләр өчен нинди тәрбия бирүен ничек әйтергә дә белмим. Андагы сериалларның күпчелеге үтерүне, азгынлыкны, көчләүне күрсәтүгә корылган. Аларда кеше күңеленә югары идеяләр, намус-вөҗдан орлыклары чәчәрдәй материал юк. Алар идея-эстетик тәрбия бирүдән ерак торалар. Шундагы сурәтләр, картиналарны карап, кеше зомбилаша. Агуын да, даруын да йота. Ләкин бер нәрсә бәхәссез: китапханәчеләр, нинди генә сәяси гарасатлар уйнаса да, үзләренең изге эшләрен дәвам итәргә тиешләр. Югары идеалларга өндәүче, күңелләрне дулкынландырырлык яхшы әсәрләрнең кыйммәтен ачып, беренче чиратта балаларның, үсмерләрнең дөньяга карашларына уңай йогынты ясарга, аларның күңеленә тамчылап булса да рухи кыйммәтләрне сеңдерергә бурычлылар. Китапханәче моңа ирешүдә бернинди каршылыкларга карамыйча алга омтылырга, үзләрен бүгенге яшәешнең әхлакый әйдәүчеләре дип санарга тиешләр. Халыкны матур әдәбият укырга өйрәтү түбән сыйныфлардан ук башлана. Авыл китапханәсендә эшләгәндә, мин бик кызык күренешкә тарыдым. Бала биш-алты китап алып китә дә, икенче яисә өченче көнне шуларны алып килеп, яңаларын сорый. Монда китапханәчегә психолог булмыйча ярамый.

– Укыдыңмы? – дип сорыйм арадан бер китабын күрсәтеп.

– Укыдым, – ди бала.

Шунда китапның сюжетына, яисә андагы рәсемгә бәйләп сорау бирәм. Ул аптырап кала, ни әйтергә белми. Баланы бик кыен хәлгә куймыйча гына, «шул төшен җентекләп укып кара әле», дигәнрәк сүзләр әйтеп, китапны кабат биргән чаклар да булгалый иде. Бала акрынлап китап укырга өйрәнә, инде аңа сораулар бирүнең кирәге дә

калмый. Сугыштан соңгы елларда бөтен мәктәбебезне зуррак сыйныф бүлмәсенә җыеп, аерым әсәрләрне кычкырып укулар да оештырыла иде. Чиратлап укыйбыз, фикер алышабыз. М. Бубенновның «Совет әдәбияты» журналында басылган «Ак каен» романын укуыбызны бүгенгәчә яхшы хәтерлим. Г. Гобәйнең «Маякчы кызы» повестен укып, мәктәпнең барлык укучылары каршында эчтәлекне чиратлап сөйләгәнебезне дә онуту мөмкин түгел. Әйтергә теләгәнем шул: без матур әдәбият белән яшәдек. Әдәбият безнең өчен уен кебек үк мавыктыргыч шөгыль иде. Язучыларның әсәрләрен без күңелебезгә сеңдердек, алар безне тәрбияләде. Ләкин бүгенге балалар без түгел, аларның рухи ихтыяҗлары башкачарак. Бүгенге башлангыч мәктәп балалары – илнең киләчәге. Аларны әсәр эчендә яшәргә, әсәр персонажлары белән кичерергә ничек өйрәтергә соң? Бу өлкәдә Татарстан китап нәшрияты күпкырлы эш алып бара. Татар, рус, инглиз телләрендә чыккан китапларны кәгазьдә һәм видеоязмаларда да укый ала бүгенге бала. Безнең Мөслим районы китапханәләрендә курчак театрлары эшләүне дә хуплаunion кирәк. Сәхнә баланы саф татар телендә сөйләргә өйрәтә. Әмма сәхнә әсәрләре юк дәрәҗәсендә. Без үскәндә, китапханәләргә ел саен диярлек «Пионер сәхнәсе», «Мәктәп сәхнәсе» исеме белән пьесалар җыентыклары чыга иде. Анда татар драматурглары әсәрләре белән бергә чит ил язучыларының тәрҗемәләре дә булды. Без аларны көтеп алдык, күбесен сәхнәләштердек. Мин укытучылар, китапханәчеләр белән сөйләшкәндә, балаларның драма әсәрләрендә уйнарга ашкынып торуларын әйтәләр. Нишләп соң без моны файдаланмыйбыз? Нишләп без төрлечә сүккән совет системасы мондый җыентыкларны чыгарып килгән дә, бу эш хәзер туктаган? Атнага ике сәгать татар теле укытылуына драма әсәрләрен сәхнәләштерү җавап булмас идемени?

Яшүсмерләр белән эшләү – ул галәмгә тиң. Яшьлек хыяллана. Егетләр-кызларның омтылышлары бернинди чикләрне белми. Шушы вакытта нинди юнәлеш бирүгә карап, яшьләр бөек идеалларга да омтылырга, үз гомерләрен эгоистик максатларга да багышларга мөмкиннәр. Китапханәченең арсеналында Г. Тукай, Һ. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил, Т. Миңнуллин китаплары бар. Әгәр без аларның яшәү үрнәкләрен, әсәрләрен яшүсмерләргә тәкъдим итеп, рухларына сеңдермәсәк, китапханәче дигән исемне күтәреп йөрергә дә лаек булмас идек. Үрнәк – бөек тәрбия чарасы. Китапханәче бөек кешеләр тормышы турында язылган әсәрләр белән яшьләрне рухландырырга тиеш.

Шушы урында минем әдәби

*Народный писатель Республики Татарстан, лауреат премии им. Г. Тукая Фоат Садриев вспоминает как в детстве, заходя в библиотеку или в книжный магазин, разбегались его глаза. Потом, захватив 3-4 книжки, добегал до дома и, сидя на печке, начинал читать.*

*Он всю свою жизнь любил книги, собирал их, читал. В 1959 году Фоат Садриев начинает работать библиотекарем в родном селе, а в 1992 году его назначают на должность директора в Районную Централизованную библиотеку.*

*По его словам, когда-то Советский народ считался самым читающим. Как пишет Ленин, в 1897 году в России 76% людей не умели ни писать, ни читать. И только после Октябрской революции стал Советский Союз грамотной страной. В борьбе с безграмотностью приложили свои силы избы-читальни, библиотеки. Библиотеки не закрывались даже во время Великой Отечественной войны. Но в девяностые годы прошлого века число читающих резко сократилось. Что случилось? Конечно же, повлияли телевидение, интернет, смартфоны и другие гаджеты. С их помощью с информацией можно знакомиться раньше газет-журналов. Это еще тесно связано с тем, что в нынешнее время материальные ценности ставятся выше духовных.*

*Телевидение, интернет, где откровенно показываются убийства, насилие, разврат, явно несет негативный характер при формировании мировоззрения молодежи. В нашем мире идет процесс зомбирования. Но одно бесспорно: даже в таких обстоятельствах библиотекари не имеют права забывать о своей миссии. Мы должны донести до молодежи моральную ценность произведения, пробудить любовь к книге. Это должно происходить с малых лет.*

*Наша вторая миссия – пропаганда литературы. Почему на татарском телевидении и прессе нет программы, пропагандирующей хорошую литературу. Произведения должны читаться народом. Мы должны призвать людей к высоким духовным идеалам.*

Социалистическим соревнованием было охвачено большинство сотрудников библиотеки. Договор на 1945 год был составлен на основе индивидуальных социалистических обязательств сотрудников и отделов. Вопросы соцсоревнования неоднократно обсуждались на совещании заведующих отделами, по отделам и на общих собраниях коллектива. В ходе социалистического соревнования была проведена взаимопроверка с участием представителей от каждого коллектива и с участием представителя от Наркомпроса ТАССР.

Первое место в соревновании занял абонемент (заведующая Лапаева Ольга Сергеевна); 2 место – справочно-библиографический отдел (зав. Гуревич Мира Иосифовна); 3 место – методический кабинет (заведующая Рязанская Лидия Иосифовна).

В связи с 25-летием Татарской АССР 3 сотрудника Республиканской библиотеки им. В. И. Ленина получили благодарность от Председателя Комитета по делам культпросветучреждений при Совнаркоме РСФСР тов. Зуевой:

Валентина Александровна Шевалина – библиотекарь абонемента;

Зайнаб Шакировна Хабибуллина – библиотекарь-библиограф;

Рифгат Мухаметзянович Габидуллин – заведующий справочно-библиографическим отделом, инвалид войны.

Сотрудники абонемента, справочно-библиографического отдела и методкабинета получили денежные премии от дирекции библиотеки за успешную работу.

Юбилей образования Татарской АССР Республиканская библиотека им. В. И. Ленина отметила достойно и интересно.

*ТАССР оешуның 25 еллыгы авыр-катлаулы да, шатлыклы да 1945 елда Республиканың һәр өлкәсендә билгеләп үтелгән: төзелештә, сәнәгать җитештерүендә, авыл хуҗалыгында, шулай ук – китапханә эшендә дә.*

*25 еллык юбилейга Республика китапханәсе тарафыннан чыгышлар һәм әңгәмәләр өчен темалар тәкъдим ителә, методик җыелышлар уздырыла, күргәзмәләр оештырыла, библиографик күрсәткечләр, әдәбият исемлекләре, библиографик белешмәлекләр, альбомнар төзелә; лекцияләр, әдәби кичәләр оештырыла.*

*Коллектив Казан университеты китапханәсе белән социалистик ярыш оештырган. Нәтиҗәле эш өчен макталган һәм акчалата бүләкләнгән хезмәткәрләр дә булган.*

***Римма ЕЛИЗАРОВА,***
*ведущий научный сотрудник*
*отдела рукописей и редких книг*
*Национальной библиотеки Республики Татарстан*



# Рассказывают протоколы партийных собраний

## ИЗ ИСТОРИИ НАЦИОНАЛЬНОЙ БИБЛИОТЕКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Источниковедческая база, позволяющая проследить историю развития Национальной библиотеки Республики Татарстан, включает широкий круг неопубликованных и опубликованных материалов. Начиная с 1917 г. , в силу ряда исторических обстоятельств библиотека неоднократно меняла свой статус: Центральная городская библиотека, Губернская библиотека, Областная массовая библиотека имени В. И. Ленина Татарской АССР, Республиканская библиотека имени В. И. Ленина. Основным держателем большого спектра документов стал фонд Р5892 «Республиканская научная библиотека им. В. И. Ленина Министерства культуры Республики Татарстан». Различные исторические документы, также освещающие историю библиотеки, рассредоточены в фондах Р3682 «Министерство образования Республики Татарстан», Р271 «Отдел народного образования Казанского губернского исполнительного комитета рабочих, крестьянских и красноармейских депутатов», П15 «Татарский республиканский комитет коммунистической партии Советского Союза, г. Казань, ТАССР», П973 «Первичная организация коммунистической партии Советского Союза Республиканской научной библиотеки им. В. И. Ленина, Вахитовский район, г. Казань».

Остановимся на рассмотрении документов первичной организации коммунистической партии Советского Союза, созданной в Республиканской научной библиотеке им. В. И. Ленина. Оставляя в стороне вопросы планирования деятельности и отчетности самой первичной партийной организации, учета кадров и партийной дисциплины, рассмотрим другие вопросы. В их числе: насущные задачи хозяйственной деятельности библиотеки, включая расширение рабочей площади, ремонт помещений и подготовку к зиме; вопросы многообразной производственной деятельности, рассматриваемые на открытых и закрытых партийных собраниях; работа в условиях военного времени.

Вопросы организационно-хозяйственной деятельности неоднократно обсуждались на партийных собраниях; они были связаны как с проблемами расширения производственной площади библиотеки (освобождением ее помещений от других учреждений, занимающих ее комнаты), так и с проблемами отопительной системы и подготовки к холодному зимнему времени, ремонтом отдельных помещений или здания библиотеки.

На закрытом партийном собрании первичной парторганизации от 15 апреля 1947 г. присутствовали члены Всесоюзной коммунистической партии (большевиков)



ПРОТОКОЛ №7
собрания Первичной Парторганизации Республиканской Библиотеки
ТАССР имени В.И.ЛЕНИНА
от 27 марта 1948 г.

ПРИСУТСТВОВАЛО: членов ВКП/б/ – 6 чел.
кандит.ВКП/б/ – 1 "

ПОВЕСТКА ДНЯ:

1. О подготовке ремонта библиотеки – т. УСМАНОВ.
2. О выполнении партпоручений.
3. О весенне-посевной кампании – т. УСМАНОВ.
4. Утверждение плана работы на апрель м-ц 1948 г. – т.МАКАРЬВИЧ.

СЛУШАЛИ 1: О подготовке к ремонту библиотеки – т. УСМАНОВ.

По плану на 1948 год мы должны будем провести капитальный ремонт всего здания, как внутри, так и снаружи. Нам отпущено 150 тысяч рублей. Этих денег достаточно, чтобы провести тщательный ремонт. Так как хозяйственным путем мы ремонт делать не имеем права, то и хлопочем сейчас, чтобы нам дали лимит на ремонт в тресте Казаньстроя, пока что все наши хлопоти безуспешны. Сейчас наш вопрос о включении нас на ремонт стоит в Совете Министров ТАССР. В этом году мы покроем крышу – ассигновано 40 тыс.руб., побелка и штукатурка внутри здания – 35 т.р., побелка фасада – 20 т.р.; смена электропроводки, оборудование, озеленение грота и др. работы входят также в план ремонта на 1948 г.

В этом году мы имеем по плану увеличение денежных средств по зарплате на 17 тыс.руб. и в два раза увеличивается сумма на приобретение литературы.

Ввиду того, что мы в прошлом году так удачно оборудовали отопительную систему, мы имеем экономию за счет топлива около 70 т. р.

Сейчас мы имеем возможность начать заготовку топлива на следующую зиму – дело только за транспортом.

Все мероприятия, намеченные на этот год, мы должны будем провести, как можно лучше, быстрее и экономнее.

*Протокол №7 собрания первичной парторганизации Республиканской библиотеки ТАССР им. В. И. Ленина*

[ВКП(б)] – А. З. Усманов, Л. И. Рязанская, Юзликеева, Козьмина, Бахтиярова, Покка; кандидат в члены ВКП(б) Матросова. Отсутствовали Р. З. Мухитдинова (по болезни), Гиниятуллина (уехала), А. Гилева (работала). Специфической особенностью делопроизводства периода 1940–1950-х годов является употребление фамилий сотрудников библиотеки без инициалов. Поэтому в данной статье приведены фамилии с инициалами только в тех случаях, когда их удалось установить.

В протоколе №23 закрытого партийного собрания первичной парторганизации зафиксировано сообщение заместителя директора по хозяйственной части А. З. Усманова о подготовке к предполагаемому ремонту библиотеки в 1947 г. [1]. В сообщении он отметил, что на ремонт просили 380 тысяч рублей, утвердили 105 тысяч рублей. Основной ремонт (замена котла) потребовал 52 тысячи рублей. Дополнительно необходимо было сделать: частичный ремонт крыши, заменить водосточные трубы; покрасить фасад в честь 30-летия Октября; побелить несколько комнат; провести добавочное центральное отопление в 2-х комнатах.

А. З. Усманов отметил, что только для обмуровки котла требуется 6 тысяч кирпичей. Запланированные работы по установке котла должны были продлиться с 20 апреля по 1 августа 1947 г. При заключении договора было необходимо иметь 50 тысяч рублей в апреле месяце, но денег не было, и Управление не обещало. Частным путем ремонт производить было нельзя, только через строительную организацию.

Годом позже, 27 марта 1948 г. , на собрании первичной парторганизации Усманов выступал также по вопросу подготовки к ремонту библиотеки. В протоколе №7 отражены планы проведения капитального ремонта на 1948 г. всего здания, как внутри, так и снаружи. По его мнению, выделенных 150 тысяч рублей достаточно было для того, чтобы провести тщательный ремонт. Осложняло ситуацию необходимость получения лимита на ремонт в тресте Казаньстроя. Вот какие задачи озвучил А. З. Усманов: «Сейчас наш вопрос о включении нас на ремонт стоит в Совете Министров ТАССР. В этом году мы покроем крышу – ассигновано 40 тысяч рублей, побелка и штукатурка внутри здания – 20 тысяч рублей; смена электропроводки, оборудование, озеленение грота и другие работы входят также в план ремонта на 1948 г. ».

Сложным вопросом деятельности библиотеки был вопрос обеспечения топливом. Проведенное в 1947 г. переоборудование отопительной системы позволило экономить за счет топлива около 70 тысяч рублей. Эти средства дали возможность начать заготовку топлива уже на следующую зиму. Выступившая в прениях сотрудница Макаревич отметила: «В эту зиму мы убедились, что ремонт в прошлом году был сделан на должной высоте. Всю зиму у нас было тепло, библиотекари работали без пальто и платков и имели более культурный вид» [2].

24 марта 1952 г. на партийном собрании первичной парторганизации был поднят вопрос о расширении рабочей площади библиотеки. Дело в том, что на протяжении многих лет помещение библиотеки занимала детская парикмахерская. А. З. Усманов сказал о том, что в помещении, занимаемом парикмахерской, отказали. Он предложил отчислить от пользования залом студентов Казанского государственного университета, «потому что



*Коллектив библиотеки. 1945 г.*
*Фотография из архива Национальной библиотеки Республики Татарстан*

при университете есть своя большая библиотека, и этим разрядить тесноту в наших читальных залах». Важно, чтобы университетская библиотека не замыкалась от читателей-студентов и открыла доступ к своим книжным богатствам широкому кругу читателей.

В выступлении А. З. Усманов подчеркнул, что размещение вновь поступающей литературы зашло в тупик. «Все свободное пространство библиотеки занято стеллажами. Новые стеллажи ставить некуда, а делать надстройки ввысь – это значит усложнить подачу книг читателю. Книги теперь у нас уже складываются на полу и между стеллажами. У нас нет достаточного надзора за комплектованием, имеются случаи многодублетности» [3].



ПРОТОКОЛ № 23.

открытого партийного собрания первичной партийной организации Республиканской библиотеки им.В.И.Ленина от 29 августа 1955 г.

Присутствовали: Члены КПСС Бахтиярова, Гилева, Мухитдинова, Усманов, Шайхутдинов, члены МК Лапаева и Шафран, секретарь комсомольской организации Брюханова, представитель охраны труда Грибова и член редколлегии Сайгина.

Председатель собрания Гилева.
Секретарь собрания - Усманов.

ПОВЕСТКА ДНЯ:

1. О подготовке к зиме. Инфор.тов.Шайхутдинов.

2. О начале партийной учебы. Инфор.тов.Усманов.

Слушали: Инфор.тов.Шайхутдинова о подготовке к зиме.

По смете 1955 г. по ст.16 /Кап.ремонт/ нами планировалось произвести следующие работы по ремонту здания библиотеки: окраска и побелка внутри здания /отд.обработки книг, корридоры, вестибюль и т.д./, лепные работы, переоборудование гаража, окраска фасада, ремонт отопительной системы, капитальный ремонт здания филиала и строительство моста в филиале.

На все эти работы предусмотрено 70 тыс.руб. /Из них 20 тыс. руб. для филиала./.

Несмотря на то, что мы ремонт начали с апреля м-ца, по вине подрядчика некоторые виды по сегодняшний день еще незакончены. Например, ремонт отопительной системы из-за отсутствия специалистов затянулся и обещают закончить и сдать в эксплуатацию только к 5 сентября.

Ремонт здания филиала пришлось приостановить, т.к. строительство моста филиала требовало дополнительные средства против предусмотренных по смете. На сегодняшний день строительство моста почти закончено, лишь остались некоторые недоделки. Что касается переоборудования гаража, надо сказать, что домоуправление до сих пор не закончило переоборудование санузла для общего пользования с чем связана наша работа по переоборудованию гаража, как закончится эта работа мы приступим к переоборудованию гаража. Все виды работ, планированные по мелкому текущему ремонту выполнены. Предложенный охраной труда ряд видов работ, кроме вентиляции внутри помещений выполнены. Исправление вентиляционной сети из-за отсутствия схемы /плана/ невозможно, и требует большие затраты средств для восстановления.

На 1956 г. планируется произвести следующие работы по кап. ремонту здния биб-ки и филиала:

*Протокол №23 собрания первичной парторганизации Республиканской библиотеки ТАССР им. В. И. Ленина*

Годом ранее секретарь партийной организации А. Гилева писала в статье «Наш опыт работы с читателями», опубликованной в газете «Советская Татария» о том, что руководство библиотеки четыре года добивается выселения расположенной в нижнем этаже парикмахерской и предоставления ей другого помещения. Итогом стало специальное решение горисполкома, вынесенное по данному вопросу. Выполнить его было поручено жилищному управлению, но здесь дело и затормозилось [4]. Помещение парикмахерской планировалось использовать для расширения читального зала и книгохранилища.

Вопросы ремонта здания библиотеки были актуальными и в 1950-ые годы. Об этом свидетельствуют записи протокола №23 открытого партийного собрания первичной партийной организации Республиканской библиотеки имени В. И. Ленина от 29 августа 1955 г. На нем присутствовали кроме членов КПСС (Бахтиаровой, А. Гилевой, Р. З. Мухитдиновой, А. З. Усманова, Шайхутдинова) также члены местного комитета (О. С. Лапаева, Шафран), секретарь комсомольской организации Брюханова; представитель охраны труда М. П. Грибова; член редколлегии Е. Е. Сайгина.

Заместитель директора Шайхутдинов перечислил запланированные по

смете 1955 г. по статье 16 (капитальный ремонт) следующие работы по ремонту здания библиотеки: окраска и побелка внутри здания (отдел обработки книг, коридоры, вестибюль и т. д. ), лепные работы, переоборудование гаража, окраска фасада, ремонт отопительной системы, капитальный ремонт здания филиала и строительство моста в филиале. На все эти работы было предусмотрено 70 тысяч рублей (из них 20 тысяч рублей для филиала). Несмотря на то, что ремонт был начат с апреля месяца, по вине подрядчика ремонт отопительной системы из-за отсутствия специалистов затянулся, сдача в эксплуатацию планировалась только к 5 сентября.

На 1956 г. были запланированы следующие работы: сделать угольную яму (люк), оборудовать механический подъемник в книгохранилище, и обязательно восстановить вентиляционные сети, частичный ремонт отопительной системы и ремонт здания филиала. Уже на августовском собрании было отмечено наличие необходимого количества топлива на 1955/1956 отопительный сезон для библиотеки и филиала, а также наличие привезенных дров для работников библиотеки в количестве 63 кубометров.

Выступления, прозвучавшие на собрании, содержали много критики. Так, М. П. Грибова отметила, что фактически еще ремонт не закончен, и качество выполненных работ очень низкое. В числе недостатков она назвала: затянувшееся восстановление вентиляции; недостаточность ежедневной уборки помещения и отсутствие пылесосов; медленное выполнение предписаний охраны труда. Необходимо было, по ее мнению, приобрести дорожки, сделать отопление рабочих мест сотрудников библиотеки. Жесткой критике подверглось руководство библиотеки за проявленную пассивность по расширению помещения: кроме жалобы на недостаток площади практически ничего не сделано. «Тов. Мухитдинова и тов. Шайхутдинов, видимо, не замечают, как на абонементе и в книгохранилище книги валяются на полу из-за отсутствия площади. Почему мы плохо занимаемся вопросом расширения площади библиотеки. Надо мобилизовать общественность, еще раз сигнализировать в печати» [5].



*М. П. Грибова, зав. отделом МБА. 1950-е гг.*
*Фотография из архива Национальной библиотеки Республики Татарстан*

Другая сотрудница О. С. Лапаева в своем выступлении предложила организовать ежедневный прием работы уборщицы со стороны завхоза, чтобы зав. отделами также строго требовали от уборщицы качество работ, перераспределение участков работ уборщиц. При приемке работы по ремонту отопительной системы она предложила провести несколько пробных топок, чтобы не осталось ни одной батареи, которая не грелась; установить на абонементе дополнительные батареи.

Сотрудница Бахтиарова критиковала администрацию за то, что последняя недостаточно заботится о рабочих местах, до сих пор не созданы условия работы на абонементе, в книгохранилище и месте, где производится выдача газет. «У нас, – говорила она, – постоянный сквозняк. Совершенно невозможно работать без того, чтоб не заболеть гриппом, ангиной. Тов. Мухитдинова иногда проходит мимо нас, и на другой день она обязательно на работу приходит больная или укутанная до головы. Спрашивается, как мы работаем в таком сквозняке по 15-20 лет, а она только прошла мимо нашего рабочего места – уже больная. Вот, товарищи, как у нас заботится директор – коммунист Мухитдинова и заместитель директора – коммунист Шайхутдинов».

Член редколлегии Сайгина отметила, что сотрудники библиотеки совершенно не пишут в стенгазете о недостатках, которые имеются в работе администрации. Выступавшие товарищи, считала она, могли дать заметки о тех или других недостатках в работе администрации, сигнализировать через стенную газету. Через работу стенной печати она предложила ликвидировать все недостатки, как в работе администрации, отделов, и недостатки отдельных работников.

Секретарь парторганизации А. Гилева, обобщив прозвучавшую критику, сказала, что партийная организация справедливо требует от членов партии тт. Мухитдиновой и Шайхутдинова в кратчайший срок ликвидировать все недостатки в работе администрации библиотеки и встретить зиму в полной готовности.

В протоколе партийного собрания были указаны имевшиеся недостатки:

– не проверено специалистом качество выполненных работ по ремонту здания;

– не закончен ремонт отопительной системы и не поставлены дополнительные батареи согласно акта охраны труда;

– не обеспечены условия работы на отдельных участках (газетный отдел, абонемент, книгохранилище).

Решением партийного собрания постановили: обязать коммуниста Шайхутдинова в кратчайший срок ликвидировать отдельные недостатки по ремонту помещения, по улучшению нормальных условий работы по всем отделам; обязать всех коммунистов активно участвовать в стенной печати библиотеки, тем самым способствовать изжитию недостатков; обязать секретаря парторганизации А. Гилеву проверить выполнение решений данного открытого партсобрания.

По имеющимся протоколам партийных собраний можно проследить решение многих вопросов производственной деятельности библиотеки, включая комплектование и обработку фонда, методическую работу, межбиблиотечный абонемент и другие направления деятельности. Документы из фонда П973 «Первичная организация коммунистической партии Советского Союза Республиканской научной библиотеки им. В. И. Ленина» являются интересным источником информации по истории Национальной библиотеки Татарстана. ■

*Литература:*


1. Протокол №23 закрытого партсобрания первичной парторганизации Республиканской библиотеки имени В. И. Ленина от 15 апреля 1947 г. // Государственный архив Республики Татарстан. – Ф. П973. – Оп. 1. – Д. 23. – Л. 58.
2. Протокол №7 собрания первичной парторганизации Республиканской библиотеки ТАССР имени В. И. Ленина 27 марта 1948 г. // Государственный архив Республики Татарстан. – Ф. П973. – Оп. 1. – Д. 24. – Л. 18 – 18 об.
3. Протокол №1 партийного собрания первичной парторганизации Республиканской библиотеки ТАССР имени В. И. Ленина 24 марта 1952 г. // Государственный архив Республики Татарстан. – Ф. П973. – Оп. 1. – Д. 28. – Л. 12 – 12 об.
4. Гилева А. Наш опыт работы с читателями // Советская Татария. – 1951. – 3 октября.
5. Протокол №23 открытого партийного собрания первичной партийной организации Республиканской библиотеки имени В. И. Ленина от 29 августа 1955 г. // Государственный архив Республики Татарстан. – Ф. П973. – Оп. 1. – Д. 31. – Л. 56-5


*Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең үсеш тарихын ачыкларга ярдәм итүче күпсанлы чыганаклар, тарихи документлар сакланып калган.*

*Китапханәнең партия җыелышларында хуҗалык-оештыру эшләре, җылыту системасын көйләү, китапханә бинасын төзекләндерү, сугыш чорындагы эшчәнлек турында мәсьәләләр тикшерелгән.*

*Партҗыелыш беркетмәләренең берсендә китапханәдә 1947 елда булачак төзекләндерү эшләренә әзерлек турында сүз бара. Хуҗалык эшләре буенча директор урынбасары А. З. Усманов сүзләренчә, төзекләндерү эшләренә 380 мең сум акча соралган булса да, 105 меңен генә раслыйлар.*

*Китапханәне ягулык белән тәэмин итү зур проблемаларның берсе саналган. Төзекләндерүдән соң ягулыкны экономияләү 70 мең сумны янга калдырган.*

*1952 елгы партия җыелышында китапханәнең мәйданнарын киңәйтү мәсьәләсе каралган. Чөнки күп еллардан бирле бинада балалар чәчтарашханәсе урнашкан булган. Ул мәйданны китапханәнеке итә алмагач, Усманов Казан дәүләт университеты студентлары шөгыльләнә торган залны бушатуны тәкъдим иткән. Моннан тыш яңа әдәбиятны саклау өчен дә урыннар җитмәгән, китаплар идәнгә, киштәләр арасына куелган.*

*Сыйфатлы төзекләндерү булмау сәбәпле, хезмәткәрләрне уңайлы эш урыннары белән тәэмин итә алмаганнар: бина салкын, тузанлы, кысан, бүлмәләрдә җил уйнаган. Партия җыелышында җитәкчелеккә алга таба китапханә бинасын төзекләндереп, җитешсезлекләрне бетереп, эшчеләргә уңайлы шартлар тудыру бурычы йөкләнгән.*

*Партия җыелышлары беркетмәләре китапханәдә фондны эшкәртү, методик эш, китапханәара абонемент һәм башкалар турында да мәгълүмат алырга ярдәм итә.*

# КИТАП БУЫННАРНЫ ТОТАШТЫРА

***Гөлүсә ФӘХРУЛЛИНА,***
*Яр Чаллы шәһәре «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең методик бүлеге белгече;*

***Роза ХӘМИДУЛЛИНА,***
*Яр Чаллы шәһәре «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең «Әдәбият тарихы музее» мөдире*

*Мәңге яшәргә теләсәң, и угыл,*
*Ал гыйлем, чөнки тереклек суы ул.*

Габдерәхим Утыз Имәни

*Китаплар – кешелекнең хәтере.*

Фәнис Яруллин

## ЯР ЧАЛЛЫ КИТАПХАНӘЛӘРЕ ТАРИХЫ

ЯР ЧАЛЛЫ шәһәре китапханәләре тарихы Татарстан Республикасында китапханә эше үсешенең аерылгысыз өлеше булып тора.

Беренче мәдәни-агарту учреждениесе буларак Чаллы авылында 1904 елның декабрендә **А. С. Пушкин исемендәге җәмәгать китапханәсе ачыла**. Ул Кама ярындагы Үзәк урамда урнашкан сәүдәгәр Баутин чәйханәсе коридорында эшли башлый. Аның турында кайгыртуны химаяче (попечитель) Иванов үз өстенә ала. Китапханәне китап һәм газета-журналлар белән тулыландыру максаты белән җирлек идарәсе (земство) тарафыннан елына 300 сум акча бүлеп бирелә. Китапханәче хезмәтенә түләү булмаганлыктан, китап сөючеләрне дежур торучы аерым кешеләр генә каршы ала. Китапханә зур өзеклекләр белән эшли, ә 1908 елның 13 августыннан 1909 елның 13 декабренә кадәр бөтенләй ябылып та тора.

1910 елда А. С. Пушкин исемендәге китапханәне җирле табибның хатыны Л. Ф. Чуфарская кабул итеп ала. Акт буенча 755 данә китап, 304 данә вакытлы матбугат басмалары кабул ителә. Китапханәнең бюджеты елга 600 сумны тәшкил итә. Китапханәченең еллык хезмәт хакы 180 сум, җыештыручыга 72 сум түләнә, бюджетта каралган калган акчалар бинадан файдаланган, аны яктырткан, ягып җылыткан өчен түләргә, китап, газета-журналлар алдыруга тотыла. Еллык отчётында Л. Ф. Чуфарская, спектакльләр куеп, бюджетны 134 сум 63 тиенгә тулыландырганын күрсәтә. Бу акчага 224 данә зурлар һәм балалар китаплары сатып алына, газета-журналларга язылу үткәрелә. Ел азагына кадәр китапханәдә 475 китап укучыга хезмәт күрсәтелә, шуларның 270-е – балалар, нәтиҗәдә халыкка 5176 данә китап бирелә, шул исәптән 4313-е – балаларга. 1913 елда китапханә губерна земствосы карамагына тапшырыла.

1914 елда 40 сум айлык хезмәт хакы белән китапханә мөдире итеп Артем Ильич Катаев билгеләнә. Бу вакытта китапханә фондындагы 1352 китапның 200-е балалар өчен була. Китап укучылар саны 314-кә җитә. 1918 елда А. С. Пушкин исемендәге китапханә Красная урамында урнашкан мәктәп бинасына күчерелә.

Бөтенроссия Үзәк башкарма комитеты Декреты нигезендә 1920 елның 27 маенда РСФСР составында Татар Автоном Совет Социалистик Республикасы төзелү татар мәдәнияте үсешендә, шулай ук китапханәләр эшендә зур үзгәрешләр тудыра.

1920 елда Минзәлә өязе составындагы Чаллы кантоны ТАССР составына керә. Җирле пропаганда бүлеге кантон китапханәләрен, халык йортларын һәм клубла-

рын үз карамагына ала. Ләкин, авыр матди шартлар, китаплар азлыгы һәм аларны сатып алуга акча булмау, әзерлекле белгечләр җитмәү аркасында, 1921 елның 1 декабреннән кантонда мәдәни-агарту учреждениеләре, китапханәләр киметелә. Чаллы кантонынына кергән 19 китапханә, 90 уку ызбасы (изба-читальня), 14 халык йорты калдырыла, ә калганнарына үз хисапларына яшәргә тәкъдим ителә.

1922 елның гыйнварыннан авыл китапханәләре А. С. Пушкин исемендәге Үзәк китапханәгә берләштерелә. Китапханәдә рус, татар һәм аз санлы милләтләр өчен өч бүлек оештырыла. Финанс кыенлыклары аркасында 1922 елның мартында Чаллы авылы Үзәк китапханәсен партия китапханәсе белән кушу һәм аның каршында сәяси бүлек оештыру турында карар кабул ителә.

1922 елның августыннан китапханә мөдире булып М. Н. Грибова эшли башлый. Озакламый ярдәмгә Татарстан өлкә советы партия мәктәбенең китапханә бүлеген тәмамлаган В. Алемасова җибәрелә.

1924 елның көзендә китапханәдә гражданнарның үзлегеннән белем алу түгәрәге эшли башлый. Анда 14 яшьтән 17 яшькәчә булган 30 кеше йөри. Түгәрәктә бергәләп яшьләрнең сәяси белемнәрен арттыралар, стена газеталары чыгаралар, революцион бәйрәмнәр вакытында чыгыш ясау өчен текстлар әзерлиләр. Түгәрәккә йөрүчеләр елына 2-3 спектакль куялар, язын китапханә каршында физкультура мәйданчыгы төзиләр, футбол командасы оештыралар. Алар китапханәнең активына әверелә: китаплар эшкәртүдә, китапханәгә китап укучылар җәлеп итүдә булышалар.

1925 елның азагында китапханә клуб бинасына күчерелә. Бина кысан булганлыктан, актив белән эшләү, массакүләм чаралар үткәрү өчен бирелә



Салиха Гали кызы Вәлиева



Галина Васильевна Сотникова (Платонова)

мөмкинлекләр булмый. М. Грибова Чаллыдан күчеп китү сәбәпле, китапханә мөдире итеп В. Огородникова билгеләнә.

1929–1930 елларда ТАССР административ берәмлекләргә бүленә, 12 кантон һәм 125 волость урынына 43 район төзелә. Һәр районда сәяси-агарту эшләре бүлеге яки советы булган район халык мәгарифе бүлеге (РОНО) оештырыла. Яңа административ-территориаль бүленеш кертелү сәбәпле, авыл җирлегендәге китапханә системалары үзгәртеп корыла.

СССР Үзәк Башкарма комитеты карары нигезендә 1930 елның 10 августында Чаллы авылына шәһәр статусы бирелә. Ул вакытта биредә 9 300 кеше яши. Ә А. С. Пушкин исемендәге Үзәк китапханә **Чаллы районы Үзәк китапханәсе** булып эшли башлый.

Әлеге китапханә авыл китапханәләренә методик ярдәм күрсәтүче һәм Чаллы районының колхозлары, совхозлары һәм МТС хезмәткәрләре өчен күчмә китапханәләр оештыручы үзәк буларак билгеләнә. Мәсәлән, 1935 елның урып-җыю чорында район китапханәсе 4 күчмә китапханә оештыра, ә 1936 елгы язгы чәчү вакытында колхозчыларны 8 күчмә китапханә китаплар белән тәэмин итә. Район китапханәсе хезмәткәрләре, районның төрле авылларына барып, китапханә эшен җайга салуда җирле китапханәчеләргә ярдәм күрсәтәләр.

Чаллы районы Үзәк китапханәсе 1935 елда шәһәрнең Үзәк урамындагы пионерлар клубы каршында урнашкан була. Анда барысы өч хезмәткәр эшли: китапханә мөдире Н. Калясева һәм ике китапханәче – В. Панкова белән С. Г. Вәлиева. Фондта 3000 данә китап исәпләнә. Китапханәгә 250 кеше йөри, шулар арасында – балалар, эшчеләр, колхозчылар, төрле хезмәткәрләр. Район китапханәсендә әдәби түгәрәк эшли, аңа 32 кеше йөри. Әдәби түгәрәктә дәресләр Мәскәүдән җибәрелгән «Крестьян газетасы» программасы буенча алып барыла: М. Горький, В. Маяковский, М. Шолохов кебек совет язучыларының әсәрләре өйрәнелә. Кычкырып укулар үткәрелә.

1937 елда Чаллының Үзәк урамында шәһәр Советы бинасы төзелә. Аның беренче катында китапханә өчен гомуми мәйданы 100 квадрат метрдан артык булган иркен бүлмә бүлеп бирелә. Китапханә структурасында балалар өчен мөстәкыйль бүлек ачу мөмкинлеге барлыкка килә. Фондта инде 3700 данә китап исәпләнә, китап укучылар саны да 350 кешегә җитә, шуларның 97-се татарлар була.

Чаллы шәһәрендә китапханә эшен күтәрүгә зур өлеш керткән кешеләрнең берсе – 35 елдан ар-

тык гомерен район китапханәсе белән бәйләгән Вәлиева Салиха Гали кызы. С. Г. Вәлиева авыр сугыш елларында да үз һөнәренә тугры булып, китапханә эше белән беррәттән, Калинин фронты сугышчыларына хатлар һәм посылкалар җибәрүне оештырган. Салиха Гали кызы эшләгән дәверендә ике тапкыр шәһәр һәм район советына депутат итеп сайлана. Озакка сузылган хезмәт биографиясе дәвамында С. Г. Вәлиева күп тапкырлар Мактау грамоталары белән бүләкләнә, «Фидакяр хезмәт өчен» һәм «Германияне җиңгән өчен» медальләренә лаек була.

1940 елда смета буенча китапханәгә 19 000 сум акча бүлеп бирелә. Китаплар сатып алуга 8 490 сум тотыла. 3 китапханәче, 1 җыештыручы эшли.

1940 елның 18 сентябрендә Пермь техникумын бетергән Галина Васильевна Сотникова (Платонова) Чаллы районы Үзәк китапханәсендә уку залы мөдире булып эшли башлый. 1942 елның маенда Сотникова фронтка китә, аңа 23 яшь була. 1942 елның 7 июненнән 1945 елның Җиңү көненә кадәр Г. В. Сотникова 170 нче полк штабында телеграфист-морзист булып хезмәт итә. Сугышчы-элемтәче буларак, ул бөтен Төньяк Кавказны йөреп чыга. Галина Васильевна «Кавказ оборонасы өчен» медаленә лаек була. Сугыштан соң ул китапханәгә кире эшкә кайта.

1941 елда С. Г. Вәлиева җитәкчелегендәге китапханә коллективы зур нәтиҗәләргә ирешә: китап фонды 7 720 данәгә җитә, укучылар саны 1046 кешегә кадәр арта, 22 493 данә китап бирелә. Китапханәгә йөрүче Чаллы халкы һәм якын-тирә авылларда яшәүчеләр аның иркен уку залыннан файдаланалар.

Бөек Ватан сугышы китапханә хезмәткәрләре алдына яңа бурычлар куя: барлык мәдәният учреждениеләре эше илне саклауга юнәлтелгән була.



*Чаллы районы Үзәк балалар китапханәсе хезмәткәрләре*

Китапханәчеләргә, әдәбият белән кызыксындыруның иң массакүләм һәм үтемле формалары буларак, газета һәм китапларны кычкырып уку, әңгәмәләр оештыру кебек алымнар тәкъдим ителә. Бу гомуми эшкә Чаллы районы китапханәсе хезмәткәрләре дә үз өлешләрен кертә.

Сугыш елларында китапханәләргә яңа әдәбият һәм газета-журналлар килү кискен кыскартыла. Аларны кирәкле барлык басмалар белән тәэмин итү өчен төрле чаралар күрелә. Китапханәләргә массакүләм басмалар: «Правда», «Фронт китапханәсе» брошюралары, листовкалар, плакатлар таратыла. Үзәк һәм җирле газеталар биреп барыла. Әмма сугыш чорында китапханә фонды тулыланмый. Бу елларда газеталар белән эшләү аеруча зур әһәмияткә ия була. Китапханәләр янында үзәк һәм җирле газеталар, газета кисемтәләре урнаштырылган витриналар куела. Газета материаллары нигезендә политинформация, әңгәмәләр һәм кычкырып укулар үткәрелә. Китапханәчеләр кызыл почмакларда лекцияләр һәм докладлар белән чыгыш ясый, күмәк радиотыңлаулар оештыра.

Сугыш чорында Чаллы районы китапханәсе хезмәткәрләре Тарловка санаториенда дәваланучы яралы сугышчылар өчен китаплар туплауда һәм оборона фонды өчен акча, җылы киемнәр җыюда катнашалар.

Матди кыенлыкларга да карамастан, сугыштан соңгы елларда Чаллы районы китапханәсенең сыйфат һәм сан ягыннан үсешен билгеләп үтәргә кирәк. 1946 елда шәһәр территориясенә кергән **Орловка авылында китапханә** ачыла. Башта ул клуб бинасында урнаша, ә 1948 елда аерым бинага күчерелә. 1955 елга кадәр биредә китапханәче булып А. А. Мухин эшли. Халык бик теләп китапханәгә йөри, төрле чараларда катнаша. Балалар һәм яшьләр аеруча актив була. Бу китапханә Чаллы шәһәр ҮКСы составына 19 нчы номерлы филиал буларак 1984 елда күчә. Китапханәдә озак еллар Зиновьева Любовь Васильевна хезмәт куя.

1948 елда Чаллы районы Үзәк китапханәсенең балалар бүлеге мөстәкыйль китапханә булып аерылып чыга, аңа Чаллы районы Үзәк балалар китапханәсе статусы бирелә. Ул шәһәрнең Үзәк урамында, сәүдәгәр Стахеев йортында ур-



*1953 елда китапханә мәдәният йортына күчерелә*



*Китап туплау һәм эшкәртү бүлеге хезмәткәрләре*

наша. Озак еллар китапханә шәһәр территориясендә бердәнбер махсуслаштырылган балалар китапханәсе булып кала һәм бер үк вакытта район авыл китапханәләре өчен балалар белән эшләү буенча методик үзәк булып тора. Китапханәгә башта рус һәм татар телләрендә 2,5 мең данә балалар әдәбияты бүлеп бирелгән була. Китапханә китап укучыларга кытлык кичерми, аларның китапханәгә йөреше катгый бер тәртипкә салына – балалар сыйныфлары белән билгеләнгән көннәрдә киләләр. 1994 елда, китапханә челтәрен үзгәртеп кору нәтиҗәсендә, әлеге китапханә район балалар китапханәсе статусын югалта һәм Чаллы шәһәре Үзәк китапханәсенә кушыла. Китапханәдә А. С. Крапивина, Ф. М. Шиһапова, Х. И. Сәлимгәрәева, А. С. Спиридонова, Г. К. Саляева озак еллар дәвамында балаларга хезмәт күрсәтәләр.

1949 елда Чаллы районы Үзәк китапханәсе фонды 5148 данә китапка, укучылар саны 1352 кешегә җитә, укучыларга 22351 данә китап бирелә. Китапханәдә махсус урта белемле дүрт китапханәче хезмәт куя: С. Г. Вәлиева, Г. И. Платонова, Н. Хәйруллина, С. С. Бикташева. Абонемент һәм уку залыннан тыш, китапханә структурасында барлыкка килгән күчмә фонд бүлеге нигезендә район халкына китапханә хезмәте күрсәтелә. Укучылар арасында авыл хуҗалыгы белгечләре, совхоз директорлары, колхоз рәисләре, партактив була. Китап укучылар күп булу сәбәпле, китапханәчеләргә киеренке шартларда эшләргә туры килә. Ветеран китапханәчеләр истәлекләреннән күренгәнчә, абонементта да, уку залында да һәрвакыт чиратлар булган, уку залына чиратны иртә таңнан ук алганнар.

1950 нче елларда шәһәрдә китапханә мәйданын киңәйтү зарурлыгы туа. Китапханәне зуррак бинага күчерүне сорап китапханәчеләр Район мәдәният бүлегенә хат язалар. Ниһаять, 1953 елда китапханә шәһәрнең Үзәк урамында урнашкан район мәдәният йорты бинасының икенче катына күчерелә.

Чаллы районы Үзәк китапханәсе шәһәр һәм авыл китапханәләре белән җитәкчелек итә. Бу елларда Чаллы районында 47 китапханә исәпләнә. Китап укучылар санын 63263 кеше тәшкил итә.

1960 нчы елларда Чаллы шәһәрендә 4 китапханә ачыла. Укучыларның төп контингентын җирле предприятие эшчеләре һәм укучылар тәшкил итә.

1965 елдан Татарстанның төньяк-көнчыгышында куәтле Түбән Кама территориаль-сәнәгать комплексы формалаша: Зәй ГРЭСы, Түбән Кама ГЭСы төзелә башлый, зур йөк автомобильләре җитештерү буенча СССРда иң эре КамАЗ заводы, башка эре предприятиеләр төзү планлаштырыла.

1969 елда Чаллы шәһәрендә авыр йөк машиналары җитештерү буенча завод төзү турында карар кабул ителә. Шәһәребез зур үзгәрешләр кичерә, монда илебезнең төрле төбәкләреннән эшче яшьләр агыла башлый. Чаллы зурлыгы буенча Татарстанның икенче шәһәренә әверелә.

1969 елда Чаллы районы Үзәк китапханәсе шактый бай китап фонды туплаган китапханә була. Китапханә хезмәткәрләре



*Чаллы районы Үзәк китапханәсенең уку залы*



Яр Чаллы шәһәре Үзәк китапханәсен ачу тантанасы

алдына ГЭС һәм КамАЗ төзүчеләрен китаплар белән тәэмин итү бурычы куела. Кыска гына вакыт эчендә эшчеләр тулай торакларында һәм житештерү мәйданнарында 30 күчмә китапханә оештырыла, массакүләм эш актив алып барыла.

1970 елда Чаллыда 37,9 мең кеше исәпләнә. Шәһәр халкына 2 район, 4 шәһәр, 6 профсоюз һәм 5 мәктәп китапханәсе хезмәт күрсәтә. Бу елларда Чаллы шәһәрендә **«КамГЭСэнергострой» һәм «КамАЗ» житештерү берләшмәләренең профсоюз китапханәләре ачыла**.

1971 елда 8/24 йортының кызыл почмагында «КамГЭСэнергострой» берләшмәсенең профсоюз китапханәсе ачыла. Китапханәгә барысы 300 ләп кеше йөри.

1975 елда «КамГЭСэнергострой» профсоюз китапханәсенә 10/14 йортыннан биш фатир бирелә, ә 8/24 йортында урнашкан китапханә күчмә китап бирү бүлеге булып кала. КамАЗ төзелеше башланган елларда әлеге китапханәнең фонды, филиаллары, китап укучылар саны арта. Шәһәребез оешмаларында, төзелеш мәйданнарында, эшчеләр посёлокларында, тулай торакларда 50-гә якын күчмә китапханә оештырыла.

«КамГЭСэнергострой» китапханәсенең беренче житәкчесе – Любовь Васильевна Черненко, аның кул астында Г. С. Козлова, М. М. Акбашева эшлиләр.



Ф.Җ. Фәйзуллина



Л. В. Черненко

1972 елның июлендә 4/06 йортында **«КамАЗ» профсоюз китапханәсен** ачу тантанасы уза. Завод төзелешендәге кебек үк, китапханә фондын тулыландыруда бөтен ил катнаша. «КамАЗлыга – китап!» өндәмәсе буенча китапханәгә бүләккә Чиләбе, Свердловск, Магнитогорск, Горький, Курск, Казан, Харьков, Ленинград һәм Советлар Союзының башка шәһәрләре китапханәләреннән дистә меңләгән китап җибәрелә. Баштагы чорда китапханәнең китап фонды 28 мең данәне тәшкил итә. Ә укучылар саны артканнан-арта бара. «КамАЗ» житәкчелеге китапханәнең халыкка кирәклеген аңлап, аның өчен 3/09 йортында фатирлар бүлеп бирә. Китапханәчеләр КамАЗ эшчеләре яшәгән тулай торакларда китап күргәзмәләре, әдәби кичәләр һ. б. чаралар үткәрә.

1974 елдан «КамАЗ» профсоюз китапханәсенең беренче директоры булып Фагыйлә Җиһангир кызы Фәйзуллина эшли башлый. Ул зур осталык белән көчле коллектив туплый, китап фондын тулыландыруга, көннән-көн укучылар санын арттыруга күп тырышлык куя. Фагыйлә Җиһангир кызы 1979 елга кадәр житәкче эшен намус белән алып бара.

1972 елда Мәдәният министрлыгы тарафыннан Яр Чаллы шәһәрендә Үзәк китапханә ачу турында карар кабул ителә. Өч ел дәвамында Татарстанның В. И. Ленин исемендәге Республика фәнни китапханәсе китап фондын булдыру һәм каталоглар төзү буенча зур эш башкара. Фондны тулыландыручы төп база булып Россия дәүләт яшүсмерләр китапханәсе тора. Китапханәгә «Новый мир» журналы редакциясе ун мең данә китап бүләк итә, бер өлеш китапларны М. Е. Салтыков-Щедрин исемендәге Дәүләт китапханәсе, В. И. Ленин исемендәге СССР дәүләт китапханәсе, Бөтенроссия дәүләт чит ил әдәбиятлары китапханәсе тапшыра. КамАЗ төзүчеләр өчен китапларны илнең төрле урыннарыннан машиналарга төяп, поезд һәм самолет белән кайтаралар.

1975 елда мәртәбәле кунаклар, язучылар, хезмәт коллективлары вәкилләре катнашында китапханә тантаналы рәвештә үз ишекләрен ача һәм беренче укучыларын кабул итә. Әлеге китапханә ГЭС бистәсендәге С. Есенин тыкрыгы, 4 (8А/2) йортының беренче катында урнаштырыла. Бу вакытка китап фонды 54 000 данәгә житә.

Шәһәр Үзәк китапханәсенә герой шагыйрь Муса Җәлил исеме бирелә. «Китапханәгә Муса Җәлил исеме бирелүдә тирән мәгънә ята, – ди СССР Язучылар берлеге әгъзасы Р. Мостафин тантаналы ачылуда ясаган чыгышында. – КамАЗда һәрвакыт фидакярлек, героизм, туган җиргә карата мәхәббәт хисләре, ягъни Муса Җәлилгә хас булган рухи халәт белән очрашып торасың».

Китапханәне оештыруга зур көч керткән Гафарова Люция Әмир кызы – аның беренче мөдире дә була.


*Л. Ә. Гафарова*

КПСС ҮКның махсус Карары нигезендә (08. 05. 1974), илдә **китапханәләр челтәрен үзәкләштерү** үткәрелә башлый. Республикада беренчеләрдән булып 1975 елның ноябрендә **Чаллы районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы** оештырыла. Аңа 22 китапханә берләшә. Системаның китап фонды 160858 данә була. Үзәкләштерелгәннән соң Үзәк китапханәдә яңа бүлекләр ачыла: китап укучыларга хезмәт күрсәтү; китап туплау һәм эшкәртү; методик-библиография; китапханәара абонемент һәм китапханәләрнең бердәм фонды.

1976 елның 20 апрелендә РСФСР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә Чаллы районы Тукай районына үзгәртелә һәм **Чаллы районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы Тукай районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы** дип йөртелә башлый. Шулай ук Үзәк китапханә дә Тукай районы Үзәк китапханәсе дип үзгәртелә.

1976 елның 15 гыйнварыннан шәһәр Үзәк китапханәсе, унбер филиал (бишесе – балалар өчен) **«Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы»**на берләштерелә. Үзәкләштерелгән китапханәләр системасының бердәм китап фонды, штаты, бюджеты, административ һәм хуҗалык җитәкчелеге булганга, халыкны китап белән тәэмин итү эшенең сыйфаты да югары дәрәҗәгә менә.

Шәһәр Үзәк китапханәсе филиалларының беренче мөдирләре: О. С. Солтанова (№ 1), Т. А. Коренева (№ 2), Ф. И. Илһамова (№ 3), Т. А. Гадаева (№ 4), М. Л. Галиуллин (№ 5), А. А. Боброва (№ 6), Н. Е. Муханова (№ 7), Т. Д. Максимова (№ 8), Л. А. Одринская (№ 9), Л. И. Мещанова (№ 10), А. М. Заһидуллина (№ 11).

1980 нче еллар башында шәһәр халкына китапханә хезмәте күрсәтү зур үсеш чорын кичерә. Китапханәләрдә укучылар саны арта, китап фондлары туплана, укучыларга «Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы», «КамГЭСэнергострой», «КамАЗ» җитештерү берләшмәләренең профсоюз китапханәләре, «Тукай районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» ның китапханәләре хезмәт күрсәтә.

Бу елларда «КамГЭСэнергострой» җитештерү берләшмәсенең профсоюз китапханәләре системасында 18 китапханә эшли, китап укучылар саны 12 мең кешегә җитә. «КамГЭСэнергострой» профсоюз китапханәләре системасы директоры булып Русалеева Лидия Андриановна билгеләнә (1972–1990 елларда эшли). Оештыру сәләте, бай тәҗрибәсе, тирән белеме булган җитәкче бар тырышлыгын китапханәләр эшен зур дәрәҗәгә күтәрүгә багышлый. Ул «КамАЗ төзелеше ударнигы», «РСФСРның, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре», «Хезмәт ветераны», «Төзелеш ветераны» исемнәре белән бүләкләнә.


*Л. А. Русалеева*

1986 елның 2 августында китапханә ГЭС бистәсенең 4/14 йортына – махсус төзелгән бинага күчә. Китапханәнең ярты миллионлык фонды, 6 махсус бүлеге, 7 уку залы, тавыш яздыру студиясе, әкият бүлмәсе, төрледән-төрле остаханәләре 2670 кв. м. лы мәйданда урнаша. Шул ук вакытта хезмәт күрсәтү зоналары арта, күчмә китап бирү пунктлары 71-гә җитә. КамГЭС китапханәсе бинасын төзетү – Л. А. Русалееваның иң зур казанышларының берсе. Мондый бина ул вакытта Республика китапханә системалары арасында беренче һәм, мөгаен, бердәнбере була.

«КамГЭСэнергострой» китапханәләр системасында озак еллар А. П. Мадурова, Л. П. Рутковская, В. И. Вяткина, Л. Н. Галкина, Н. Н. Карпова, Л. С. Сафина, З. П. Шевченко, М. В. Цимболенко, Ф. Ф. Сәмигуллина, Н. Н. Исрафилова h. б. хезмәт куя.

1991 елның 1 гыйнварында «КамГЭСэнергострой» Үзәк китапханәсе нигезендә «Эврика» мәдәният үзәге ачыла. Үзәк эшчәнлегенең төп юнәлешләре китапханә хезмәте күрсәтү, күргәзмәләр, бәйрәмнәр, иҗади очрашулар, концертлар оештыру була.

2002 елда «КамГЭСэнергострой» җитештерү берләшмәләренең профсоюз китапханәләре ябыла.

1980 нче елларда **«КамАЗ» җитештерү берләшмәсенең профсоюз китапханәләре системасында** 22 филиал санала. Китап фонды 680 мең данәгә җитә. КамАЗ предприятиеләрендә һәм тармакларында 80-нән артык күчмә китапханә һәм китап бирү пунктлары эшли. 1983 елда **«КамАЗ» профсоюз китапханәсе** Татарстан Республикасы профсоюз китапханәләре бәйгесендә җиңеп «Иң яхшы эшләүче китапханә» дипломы, 1986 елда «Профсоюзларның мәдәни-агарту учреждениеләрендә яхшы эше өчен» ВЦСПС билгесе белән бүләкләнә. 1989 елда «КамАЗ» профсоюз китапханәсе 23 филиал-



*«КамГЭСэнергострой» җитештеру берләшмәсенең профсоюз китапханәләре системасы хезмәткәрләре*

ны берләштерә, китап фонды 680 мең данәне тәшкил итә, укучылар саны 68 меңгә җитә.

Валентина Ивановна Прозапас – 1980–2008 елларда китапханә эшен үстерүгә зур хезмәт керткән җитәкче. Аның зур тырышлыгы белән 1980 елда китапханә 1/15 йортындагы матур киң мәйданнарга күчерелә. КамАЗ эшчеләренә хезмәт күрсәтү өчен уку залы, яшьләр, сәнгать, абонемент, китап саклау, балалар, күчмә, методик-библиографик бүлекләр эшли. Китапханә «КамАЗ»ның Заводара китапханәсе статусын ала. В. И. Прозапас китапханәдә эшләү дәверендә «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре», «КамАЗның атказанган хезмәткәре», «КамАЗ төзелеше ударнигы» (1978), «Чаллы шәһәре алдындагы казанышлары өчен» билгесе (2007), «Казанның 1000 еллыгы» медале белән бүләкләнә.



*В. И. Прозапас*

Бөтен ил белән бергә китапханә дә 1990 нчы еллар кризисын кичерә. Шулай да нәкъ менә шушы чорда китапханә заманча эшләү рәвешенә күчә. Шәһәр китапханәләре арасында беренчеләрдән булып китап фондын, вакытлы матбугаттагы мәкаләләрне электрон каталогка кертергә мөмкинлек бирүче «МАРК» автоматлаштырылган мәгълүмати-китапханәләр системасы алына.

1997 елда «КамАЗ» профсоюз китапханәләрендә миллионынчы укучыга хезмәт күрсәтелә, китап бирү 19 миллион данәне тәшкил итә. 2000 елда китапханә, «Интертат–2000» республика фестивалендә катнашып диплом ала.

2008–2011 елларда китапханә белән Карцева Галина Константиновна җитәкчелек итә.

2011–2013 елларда китапханә директоры булып Наталья Викторовна Самохвалова эшли.

2013 елда «КамАЗ» җәмгыяте карары нигезендә «КамАЗ» профсоюз китапханәсе системасы ябыла. Китап фонды һәм китапханә милке Казан федераль университетының Яр Чаллы институты китапханәсенә тапшырыла.

Мәгълүмә Фәйзрахман кызы Фәйзрахманова 34 ел дәвамында **Тукай районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының** алыштыргысыз җитәкчесе булып тора. Ул 1968–2002 елларда директор, 2002–2006 елларда директор урынбасары вазыйфаларын башкара. М. Ф. Фәйзрахманова 1963–1973 елларда Яр Чаллы шәһәр



*«КамАЗ» җитештеру берләшмәсенең профсоюз китапханәләре системасы хезмәткәрләпре*



*Г. К. Карцева*



*Н. В. Самохвалова*



*М. Ф. Фәйзрахманова*



*Район Үзәк китапханәсе хезмәткәрләре*



*«Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» хезмәткәрләре*

Советы депутаты итеп сайлана. Эшендәге казанышлары өчен аңа «КамАЗ төзелеше ударнигы» (1978) билгесе, «Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре» (1990) дигән мактаулы исем бирелә.

1984 елда, Тукай районы составына Минзәлә һәм Сарман районы авыллары күмәк хуҗалыклары кушылу нәтиҗәсендә, Тукай ҮКСында филиаллар саны 33-кә җитә. 1997 елда район составына Комсомол посёлогы кушыла һәм системада филиаллар саны 34-кә әйләнә.

Район Үзәк китапханәсе хезмәткәрләре Х. С. Гыйләҗетдинова, Г. Т. Юнысова, В. М. Кабалина, С. Х. Закирҗанова, Р. А. Сәйфуллина, Р. С. Миңнебаева, Р. Ә. Хөсәенова, Л. Д. Васина, Г. М. Фәхруллина, З. И. Сәйфетдинова, Л. Д. Хәертдинова, Р. М. Әхәтова, Г. А. Борисова һ. б. Яр Чаллы шәһәре һәм Тукай районы территориясендә яшәүчеләрне китап белән тәэмин итү буенча күпкырлы эш алып баралар.

Алар, авыл китапханәләренә методик һәм гамәли ярдәм күрсәтү белән беррәттән, китап сөючеләр өчен кызыклы чаралар уздыралар, язгы кыр эшләре вакытында, район агитбригадасы белән авылларга чыгып, төрле чыгышлар ясыйлар, эшчеләрне яңа газета-журналлар белән тәэмин итәләр.

«Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» хезмәткәрләре республика күләмендә оештырылган бәйгеләрдә актив катнаша. Халыкка хезмәт күрсәтүне яхшы оештырганы өчен «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы»на Татарстан Республикасы Министрлар Советының һәм Мәдәният хезмәткәрләре профсоюзы өлкә советының күчмә Кызыл байрагы тапшырыла (1976, 1986). Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карары нигезендә «Иң яхшы эшләүче үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» (1985) дигән исем бирелә. Авыл китапханәләре Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Иҗади эзләнү» (2002, 2003, 2004) премиясенең лауреаты исемен алалар.

2002–2006 елллардара китапханәләр ситемасы җитәкчесе булып Фәимә Гарифулла кызы Гыйниятуллина эшли. Фәимә Гарифулла кызы китапханә мөдире булып эшләү дәверендә Үзәк китапханәне компьютерлаштыру, яңа җиһазлар белән тулыландыру мөмкинлеген таба. Тырыш хезмәте өчен Ф. Г. Гыйниятуллина «Россия Федерациясе мәгариф отличнигы», «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» (1996) исемнәренә лаек була. 2002 елдан – Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданины.

2006 елның 7 февраленнән Тукай районы хакимияте башлыгы карары нигезендә (№ 2004; 29.11.2005) Тукай районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы бетерелә. Китап фонды һәм китапханә милке авыл китапханәләренә тапшырыла. Авыл китапханәләре авыл җирлекләре карамагына күчә.

2006 елның 1 июленнән Тукай районы авыл китапханәләренә методик-библиографик ярдәм күрсәтү, китапханәләр фондын бердәм туплау һәм оештыру максатыннан «Методик-китапханә үзәге (биб-коллектор)» муниципаль учреждениесе булдырыла. Хокукый статусы алмашыну сәбәпле, 2011 елның 7 октябреннән китапханә үзегенең исеме «Тукай муниципаль районы Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль учреждениесенә үзгәртелә һәм 34 авыл китапханәсе аның



*Ф. Г. Гыйниятуллина*



*Г. М. Фахруллина*



Д. М. Галләмова



Р. Р. Мәҗитов



В. М. Гайнуллина

карамагына керә. Системаның Үзәк китапханәсе Чаллы шәһәрендә, Тукай районы хакимияте бинасында урнаша. Әлеге системаның җитәкчесе булып 2006–2015 елларда Фәхруллина Гөлүсә Мансур кызы эшли.

Хәзерге вакытта «Тукай муниципаль районы Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» 29 авыл китапханәсен берләштерә.

1980 нче еллар башыннан 2005 елга кадәр **Чаллы шәһәре үзәкләштерелгән** китапханәләр системасының зур коллективы белән Галләмова Дания Мәннан кызы идарә итә. Ул иҗади, тәҗрибәле җитәкче буларак, китапханәчеләр коллективында зур ихтирам яулый. Дания Мәннан кызы идеясе белән Чаллы ҮКСында, республикада беренчеләрдән булып, махсус татар китапханәләре ачыла, өстәмә түләүле хезмәтләр күрсәтү кертелә. Озак еллар китапханәдә тырыш хезмәт күрсәткәне өчен Дания Галләмова «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә лаек була.

Елдан-ел **Чаллы шәһәре үзәкләштерелгән китапханәләр системасында** филиаллар саны үсеп килә: шәһәр Үзәк китапханәсеннән тыш, 1980 елда 14 филиал эшли (аларның 7-се балалар өчен), 1985 елда әлеге филиаллар саны 18-гә җитә. Бу елларның матур эш күрсәткече итеп 1981 елда шәһәр Үзәк китапханәсенә һәм аның 2, 6, 14, 15 нче санлы филиалларына халыкка китапханәдә иң яхшы хезмәт күрсәтелгән өчен «Югары хезмәт күрсәтүче» исеме бирелүне атарга кирәк. Китапханәләр системасына Татарстан Республикасы Министрлар Советының һәм Мәдәният хезмәткәрләре профсоюзы өлкә советының күчмә Кызыл байрагы тапшырыла.

1990 нчы еллар Яр Чаллы ҮКСы өчен яңа шартларга күчү чоры була. 1990 ел башына ҮКС 22 филиалны берләштерә. 1991–1993 елларда шәһәр китапханәләр системасы КамГЭСэнергостройның 7 китапханәсе хисабына тагын да киңәя, ә 1994 елда аңа Тукай районы Үзәк балалар китапханәсе кушыла.

Ул елларда китап фонды – 938207 данә, 103 714 укучыга хезмәт күрсәтелә, ике миллион китап бирелә.

2002 елда Д. М. Галләмова тырышлыгы һәм депутат Р. И. Вәлиев ярдәме белән шәһәр Үзәк китапханәсе 4/14 йортына, мәйданы 2500 кв. м. булган махсус төзелгән бинага күчә.

Яңа гасырның башы исә китапханә коллективының эш тәртибе җайга салынып, иҗади алымнар кулланып, төрле профессиональ бәйгеләрдә актив катнашып һәм җиңүләргә ирешеп эшләү белән сыйфатлана. Яр Чаллы ҮКСы республикада беренчеләрдән ТР Мәдәният министрлыгының «Лидер» премиясе лауреаты булып таныла (2001). «Ел китапханәсе» республика бәйгесендә 10 нчы санлы балалар китапханәсе (2004), 16 нчы санлы балалар китапханәсе (2006) җиңү яулыйлар. 2005 елда Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы «Елның иң яхшы мәдәният учреждениесе» исеменә лаек дип табыла һәм Яр Чаллы шәһәре хакимиятенең Дипломы белән бүләкләнә.

Әлеге дәрәҗәле үрләрне яулауда һөнәри яктан көчле булган китапханә хезмәткәрләренең өлеше зур. Алар арасында китапханә һөнәренә тугры калып, күп еллар эшләгән хезмәткәрләр шактый: А. М. Нигъмәтуллина, М. Г. Солтанова, Л. А. Горохова, Р. Х. Мәгъсүмова, Г. М. Закирова, Р. Н. Рәхмәтуллина, И. Ш. Динмөхәммәтова, Л. В. Казанцева, З. Х. Нигъмәтуллина, Ә. Ф. Бәдретдинова, Л. Б. Каюмова, В. А. Бәдретдинова, Т. И. Паклина, Р. М. Галиева, С. М. Степанова, Ф. Я. Гыйззәтуллина, М. Ш. Таюпова, Ә. А. Дускаева, Н. Н. Зарипова, Р. Г. Хәмидуллина, Л. Я. Московкина һ. б.



Чаллы шәһәре үзәк китапханәсе




*Чаллы шәһәре «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» хезмәткәрләре*

2005–2007 елларда коллектив белән Мәҗитов Рамил Риф улы җитәкчелек итә. Бу вакытта шәһәр китапханәләре мәгариф, мәдәният үзәкләренә, шәһәрдәшләребезнең үзара аралашу урынына әйләнә. Китапханәләрдә яңа информацион технологияләр кулланыла, Үзәк китапханә Интернет челтәренә тоташтырыла.

2006 елда Чаллы шәһәре «ҮКС»ы «Кеше һәм табигать» республика бәйгесендә «Шәһәрнең һәм авылның иң яхшы китапханәсе» төркемендә беренче урынны яулый һәм «Экология өлкәсендә белем бирү һәм тәрбияләү буенча эшләү» номинациясендә «Иң яхшы китапханә» дипломы белән бүләкләнә.

Хәзерге көндә Яр Чаллы шәһәре «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе – шәһәр мәдәният учреждениеләре арасында иң зурларның берсе.

2007 елдан «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе директоры итеп Гайнуллина Венера Марсил кызы билгеләнә.

Китапханәләр системасы үз эченә 19 китапханәне ала: шәһәр Үзәк китапханәсе, Үзәк балалар китапханәсе, 11 массакүләм китапханә филиаллары, 6 балалар филиалы. Аларда 125 китапханә хезмәткәре эшли.

Гомуми китап фондлары 769 500 данәдән артык булган шәһәр китапханәләре ел саен 63 меңнән артык укучыга хезмәт күрсәтә, китаплар бирелеше 1,3 миллионнан артып китә.

Заманча һәм югары дәрәҗәдә хезмәт күрсәтү максатыннан барлык китапханәләр Интернет, Wi-Fi челтәренә тоташтырылган, гомуми компьютерлар саны 100-дән артык.

Ел әйләнәсендә шәһәр халкы өчен китапханәләрдә һәм шәһәр мәйданчыкларында төрле эчтәлектәге 2000-нән артык чара үткәрелә, балалар һәм өлкәннәр өчен төрле темаларны яктырткан 20 иҗат клубы эшли. Шәһәр Үзәк китапханәсендә оештырылган «Компьютер мәктәбе»ндә алынган белем өлкән буын кешеләренә электрон рәвештә күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләреннән тулысынча файдаланырга мөмкинлек бирә.

Китапханәләрдә шәһәр халкына заманча информацион технологияләр кулланып үткәрелгән чаралар елдан ел арта. Хезмәткәрләр төрле программалар һәм проектлар әзерлиләр. Соңгы елларда «Театр дөньясы безгә үз сәхнәсен ача...» дигән театр атналыгы проекты, мәктәп музейлары белән берлектә «Татар мәдәнияте хәзинәсеннән», шәһәрнең картиналар галереясе белән берлектә «Әдәбият һәм графика» артпроекты тормышка ашырылды.

Шәһәр халкының уңай бәясен алган чаралар арасында: «F4» фантастика фестивален, «Яшел дулкын» экология фестивален, «Күп милләтле Чаллы», «Тылсымлы каләм = Волшебное перо» фестивальләрен атарга була. Шәһәрнең төрле мәйданчыкларында зур масштаблы мәдәни акцияләр, әдәби марафоннар, төрледән-төрле бәйгеләр, язучылар белән очрашулар оештырыла.

«Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе китапханәләре шәһәр, республика күләмендә оештырылган бәйгеләрдә актив катнашып киләләр. Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы шәһәрнең мәдәният учреждениеләре арасында «2014 елның иң яхшы мәдәният учреждениесе» (2014), «Иң яхшы сайт» (2016), «Мәдәни мохит» (2017) номинацияләрендә җиңүче дип табылды.

Шәһәр китапханәләре төрле елларда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Иҗади эзләну» (2010, 2011, 2013, 2015) премиясе лауреаты исемен яуладылар, «Елның балалар китапханәсе» Республика бәйгесендә «Китапханәдә мәктәпкәчә яшьтәге балалар», «Балалар китапханәсендә экологик тәрбия» номинацияләрендә җиңүче булып танылдылар (2017, 2018).

«Әдәбият тарихы музее» (2007), «Фантастика фестивале» (2012), «Безнең заман» патриотик үзәге» (2014) иҗади проектлары Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларына лаек булды. 2019 елда туган телне үстерү максатыннан әзерләнгән «Зыялы гаилә – миллэтем киләчәге» проекты шулай ук җиңүчеләр исемлегенә кертелде.

Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы хәзерге көндә дә шәһәр халкына хезмәт күрсәтүнең яңа алымнарын куллану буен-

ча иҗади эш алып бара. Шәһәр китапханәләренең бүгенге торышын яктырткан китапханә сайты (библиотека. челны. рф) 2019 елда Россия күләмендә узган бәйгедә Почётлы Дипломга лаек булды. 2020 елда рус язучысы В. Астафьев иҗатына багышланган Россия бәйгесендә катнашу икенче дәрәҗә Диплом китерде. Чаллы китапханәчеләре алдына киләчәктә шәһәребездә заманча таләпләргә туры килгән китапханәләр булдыру, аларның эшләрен шәһәр халкы яратып йөри торган мәгълүмат, мәдәният, аралашу үзәкләре буларак оештыру максаты куела.

*Кулланылган әдәбият*


1. Бадретдинова В. А. Из истории Централизованной библиотечной системы города Набережные Челны // Библиотечный вестник. – 2008. – №1 (25). – С. 42–46.
2. Библиотеке КамАЗа – 40 лет / руководитель проекта Н. В. Самохвалова. – Набережные Челны: ООО «Агентство «Дайджест», 2012. – 36 с.
3. Воспоминания одной из первых заведующих Челнинской районной библиотекой М. Грибовой // Знамя коммунизма. – 1967. – № 175.
4. Гайнуллина А. В. Библиотечное строительство в ТатАССР в 1917–1941 гг. – дис. на соиск. учен. степ. кандидата пед. наук. – Л., 1984. – 210 л.
5. Гараева М. Библиотечное строительство в Набережных Челнах: страницы истории // Библиотеки Татарстана: история и современные реалии. – Казань: Милли китап, 1999. – С. 9–19.
6. Гиматдинова Т. Трудовые именины Прозапас Валентины // Вести КАМАЗа. – 2005. – 11 авг. – С. 3.
7. Григорьева К. И. Приобщение к книге // Молодой коммунист. – 1981. – № 1. – С. 34.
8. Ермаков В. Челны изначальные // Казань. – 1994. – №1-2. – С. 55.
9. Закирҗанова С. Беренче көннәрдән үк халыкка хезмәттә: Тукай районы Үзәк китапханәсе тарихыннан // Татарстан китапханәләре тарихы. 4-нче чыгарылыш. – Казан: Милли китап, 2004. – Б. 26–35.
10. Заслуженные люди Тукаевского района. Изд. 2-е / сост. Х. Н. Мухаметшин. – Набережные Челны: ОАО «Набережночелнинская типография», 2005. – 368 с.
11. Муниципальное бюджетное учреждение «Централизованная библиотечная система» города Набережные Челны / сост. : В. А. Бадретдинова, Р. Г. Хамидуллина. – Набережные Челны, 2011. – [27] с. , ил.
12. Файзрахманова М. Перелистывая страницы истории // Светлый путь. – 1996. – 25 мая. – С. 3.
13. Хәмидуллина Р. Юл күрсәтүче йолдызым: [китапханәләр челтәренә – 35 ел] / Р. Хәмидуллина // Мәйдан. – 2011. – № 11. – Б. 154–158.
14. Энциклопедия города Набережные Челны / гл. редакторы Б. Л. Кузнецов, М. Ш. Бибишев, ответ. ред. Б. А. Канеев. – Казань: издательство «Идел-Пресс», 2007. – С. 41.


■


*Статья посвящена истории библиотек Набережных Челнов. Первым культурно-просветительским учреждением в Набережных Челнах стала открытая в 1904 году публичная библиотека им. А. С. Пушкина, расположенная в чайной купца Баутина.*

*В 1920 году Челнинский кантон вошёл в состав ТАССР. С этого момента началась реорганизация культурно-просветительских учреждений. В связи со сложным материальным положением в кантоне оставили только 19 библиотек, 90 изб-читален, 14 народных домов, остальным было предложено перейти на самообеспечение. В 1922 году сельские библиотеки были объединены в Центральную библиотеку во главе с директором М. Н. Грибовой.*

*На основе Указа ЦИК СССР о новом административно-территориальном делении от 10 августа 1930 года Челны получили статус города, а Центральная библиотека им. А. С. Пушкина стала Центральной библиотекой Челнинского района, в библиотеках произошли различные структурные изменения.*

*В 1970-е годы в связи с развитием города, ростом промышленных предприятий были организованы профсоюзные библиотеки: КамАЗа, КамГЭСэнергостроя и др. Всего, таким образом, в Набережных Челнах функционировали 2 районные, 4 городские, 6 профсоюзных и 5 школьных библиотек.*

*В ноябре 1975 года была создана Централизованная библиотечная система г. Набережные Челны, куда вошли 22 библиотеки.*

*Сегодня Набережночелнинская ЦБС является одной из крупнейших библиотечных систем Республики Татарстан. В нее входят 19 библиотек: Центральная библиотека, Центральная детская библиотека, 11 взрослых филиалов, 6 детских филиалов. ЦБС возглавляет Гайнуллина Венера Марсиловна. Библиотеки неоднократно становились лауреатами республиканских и российских конкурсов, награждены грамотами и дипломами разного уровня.*

***Гульшат АЮПОВА,***
*главный библиотекарь отдела выставок и культурных программ Национальной библиотеки РТ;*
***Наргиза ВАЛИАХМЕТОВА,***
*ведущий библиотекарь отдела выставок и культурных программ Национальной библиотеки РТ*

# Как мы работаем в сети

## Национальная библиотека Республики Татарстан и Интернет

СЕГОДНЯ Интернет занимает огромную часть нашей жизни – этот факт не может игнорировать даже самый отчаянный книголюб. Поэтому многие современные библиотеки создают и активно продвигают свои странички в социальных сетях, заводят собственные интернет-ресурсы, следят за трендами в сети. Национальная библиотека Республики Татарстан – не исключение: у нас есть страницы ВКонтакте, на Facebook и в Instagram. Мы регулярно обновляем материалы на официальном сайте и поддерживаем связь с читателями онлайн.

Каждая наша площадка в Интернете учитывает особенности своей аудитории. В Instagram мы делаем акцент на визуале, ВКонтакте размещаем видео и содержательные тексты, на Facebook общаемся с деловой аудиторией.

В нашем сообществе ВКонтакте около 2 000 подписчиков, а на страничку в Instagram подписаны более 8 000 человек. Мы нашли эффективный способ привлечения аудитории: в разных уголках библиотеки размещены таблички со ссылками на наши страницы в соцсетях, на которые мы обращаем внимание во время экскурсий по библиотеке.

Работа в соцсетях приобрела особую актуальность в период пандемии, когда единственным способом связи с читателями стал Интернет. Книжные выставки, запланированные на апрель и май, мы записали в видеоформате и



разместили на наших площадках в сети. Среди них были выставки книг о Великой Отечественной войне, тематические выставки периодических изданий, выставки книг на татарском и иностранных языках. Были сняты видеообзоры, мастер-классы, литературные чтения. Эта работа помогла сохранить и приумножить интерес читателей к книгам и материалам библиотеки в период самоизоляции. Таким образом нам удалось организовать увлекательный и полезный культурный досуг в сети для самой разной аудитории.

В то же время работа в онлайн-режиме оказалась полезной и для сотрудников библиотеки: мы попробовали новые форматы и инструменты, ближе изучили интересы и вкусы читателей. Пандемия заставила библиотекарей переосмыслить подходы к работе, чтобы оставаться востребованными, интересными и привлекать новую, более молодую аудиторию. ■







*Хәзерге заманда китапханәләр социаль челтәрләрдән актив файдалана. Алар китапханәгә яңа укучылар җәлеп итәргә, китапханәнең уңай имиджын булдырырга ярдәм итә.*

*2020 елда кешелек дөньясын яңа COVID-19 короновирусы кискен үзгәртте. Татарстан Республикасында да үз-үзеңне изоляцияләү режимын игълан иттеләр. Китапханәләр искәрмә булмады, Милли китапханә дә үзизоляция вакытында укучылары өчен онлайн форматта эшләде.*

*Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Facebook, Instagram, ВКонтакте кебек социаль челтәрләрдә үз аккаунтлары бар, аларда китапханә хезмәткәрләре актив эшчәнлек алып бардылар. Апрель, май айларына планлаштырылган китап күргәзмәләре, китап күзәтүләр, презентацияләр, мастер-класслар, әсәрләр уку виртуаль рәвешкә күчте. Онлайн киңлектә үткәрелгән әлеге чаралар төрле яшьтәге китап укучылар арасында киң популярлык казанды, аларда өлкәннәр дә, балалар да актив катнашты. Мисал итеп, Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышланган «Китапханә төне – 2020», «Үлемсез полк» акцияләрен, фронттан килгән хатларны уку кебек чараларны атарга мөмкин.*

*Кешелек дөньясына килгән зур сынау – пандемия чоры – китапханәләр һәм китапханәчеләргә катлаулы шартларда да сынатмыйча эшләү өчен чыныгу мәктәбе булды. Милли китапханәнең социаль челтәрләрдә актив эшчәнлеге хәзерге көндә дә дәвам итә. Кулланучылар саны көннән-көн арта гына бара. Китапханә хезмәтләренең зур өлеше виртуаль форматка күчү безне, китапханәчеләрне, заманча эш мөмкинлекләреннән файдаланырга өйрәтте.*

*Лирон ХӘМИДУЛЛИН,*
*язучы, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*

# Китапсыз дөнья сансыз

БОРЫНГЫ тормыш вакыйгаларын белергә, шулардан үрнәк алырга тырышкан халкыбызның бер мәкале шулай атала. Хәзерге тарихи язмаларда татар-төркиләр «надан күчмә халык булган» дип, көн саен тәкърарлап торылса да, дөреслектә алай булмаган шул. Дини һәм әдәби-җәмгыяви эчтәлекле китапларны күмәкләп уку тәртибе безнең милләт вәкилләренә борынгы заманнардан бирле хас күренеш санала. Узган гасырларда яшәгән байтак кына рус галимнәре дә шулай булганлыгын таный. «Яшьтән кулына китап алырга күнеккән татар солдаты хәрби уставларны да тиз үзләштерә», – дип язган кайбер гаскәр башлыклары да.



Әтием, аннан соң мин туган авылда (Сембер өлкәсе Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылы) биш мәчет, җиде-сигез сыйныфлы ике мәдрәсә һәм өч башлангыч мәктәп булган. Ике мәчетнең манарасын узган гасырның җитмешенче елларында гына сүттеләр – җилдавыл вакытында бала-чага өстенә ишелеп төшмәсен, дип. Бездә фәкать зур мәчет манарасы гына сүтелеп, 1930 нчы елларда ул мәчет клубка әверелдерелгән иде. Авылдашыбыз Фәйзулла Туишев кайтып концерт оештырганда, якын-тирә авыл кунакларын да сыйдырырлык клуб иде ул. Тагын ике искерәк мәчетне сугыш чорында, авыл картлары белән килешеп сүтеп, ирләре яу кырында булган күп балалы гаиләләргә утынга дип өләшүләре истә калган.

«Сезнең авыл мәдрәсәсенең шәкерт һәм хәлфәләре тарафыннан күчереп язылган китапларны мин борынгы кулъязма архивларында очраткалый идем», – дип әйткән иде бервакыт Нәкый ага Исәнбәт. Казанга килгән беренче чорда, алтмышынчы еллар башында без Хәсән Сарьян эшләгән «Азат хатын» журналы бүлмәсендә дә, Сарьяннарның финанс институты янәшәсендәге фатирында да аның белән ара-тирә очраша идек. Сарьян зур авыл өен хәтерләткән иске йортта яшәде ул чорда. Түрдәге зур бүлмәне ике китап шкафы белән бүлеп, үзенә «эш кабинеты» да ясаган иде. Шкафларның зуррагына төрле телдәге китаплар тутырылган. Икенчесендә Н. И. Ашмаринның 17 томлык чуаш теле сүзлеге һәм өем-өем кулъязмалар булды.

Яңарак ачылган Башкорт университетында укытуын ташлап Казанга килгән Сарьян өендә ул дәвердә «башкорт ягы»на бәйле кунаклар еш булды. Мин дә ул чагында ярты ел чамасы Уфада яшәп киткән, йорт хуҗасы белән шунда танышканнарның берсе идем. Әйе, ул елларда өй хуҗасы җәмәгатенең якын туганы булган Әмирхан Еники, Нәкый ага Исәнбәт татарның узган тарихы һәм бүгенге хәле турында уйлануларын сөйләрләр иде. Ара-тирә ул төркемгә тагын кемнәрдер килеп кушылгалады. Нурихан Фәттах белән беренче танышуым да шушы өйдә булды. Мәктәп елларыннан бирле борынгы тарих белән кызыксынуым, дүрт ел Казахстанда укыганлыктан, ул төбәк тарихы белән дә бераз таныш булуым сәбәпле, бу очрашулар минем өчен бик тә кызык иде. Нәкъ шул елларда әлеге өлкән әдипләребезнең дә, Нуриханның да: «Безнең тарихчыларга үз тарихыбызны чынчынлап өйрәнергә мөмкинлек бирмиләр», – дип зарланулары да истә калган. Әмирхан ага яки Сарьян мәрхүмнәр: «Үзләре дә

бик тырышмый инде. Мәскәү чыгарган дәреслектә ни язылса – шуны кабатлап утыралар», – дип тә куярлар иде. Бервакыт Нәкый аганың да алар әйткәнгә кушылып китүен хәтерлим. «Куликов кыры сугышы» турында сүз чыкты исә, безнекеләр дә, дәррәү килеп: «Аны Мамай хан башлаган. Ул Мәскәүгә яу оештырган», – дип язалар. Ә дөреслектә бит ул вакыйганы башлаучы, оештыручылар Рәзән кенәзе белән башка кенәзләр булган. Алар үзләреннән күпкә яшь булган Мәскәү кенәзенең Бөек кенәз итеп, алардан өстен куелуы белән килешмәгәннәр. Рәзән кенәзе Олег Мамайны гаскәр башлыгы буларак яллап китергән. Шул хакта Карамзин да, узган гасырның башка тарихчылары да яза», – дигәне хәтеремә сеңеп калган. Шуннан соң берникадәр вакыт үтте. Мин ул тарихи вакыйга белән кызыксынып, XIX йөз рус тарихчылары хезмәтләрен караштыргалап, бер мәкалә дә әвәләгән идем. Дөрес, ул мәкалә безнең матбугат вәкилләрен ул чорда бик кызыксындырмады. Үзәк сәясәтенә каршы килү кебегрәк итеп кабул кылганнардыр инде. Бик соңлап кына, туксанынчы елларда аның кыскартылган варианты «Мәдәни җомга» газетасы егетләре «Изге» ялган серләре» исеме белән чыгарырга батырчылык итте.

Үземнең китапханә туплый башлау вакыйгасын мин бервакыт бәян иткән идем. Ул вакыйга «Күңелдә калганнар» китабымда (2007 ел, Б. 12) китерелә. Мин әле мәктәпкә йөрми идем. Әмма өлкәнрәк яшьтәге малайлар белән аралашып, латин хәрефендә нәшер ителгән кайбер дәреслекләрдәге сүзләрне укыштыргаладым. Безнең авылдан биш-алты чакрымда зур базар тотучы Салаван бистәчеге бар. Киң урман аланында, Зур Чирмешән елгасына сыенып утыра ул. Утызынчы елларда анда агач эшкәртү заводлары белән бергә картон ясау фабрикасы да оештырыла. Татарча язмада латин хәрефләрен куллану тыелгач, 1939–1940 нчы елларда шул фабрикага олау-олау төяп дәреслекләр китерә башладылар. Бер-бер артлы тезелешкән шул олаулар безнең урамнан узалар иде. Без, малайлар, кызыксынып шулар артыннан чабышыр идек. Кайбер олаучылар безгә шулчак ике-өч китап ташлап киткәләде. Бервакыт



*Татарстан Президенты Р. Миңнеханов белән*

юкарак ике китап минем янәшәгә үк килеп төште. Дөрес, аларның берсенең битләре кара буяуга буялганрак булып чыкты. Өлкәнрәк яшьтәге малайлар андый битләрдә элек халык дошманнары сурәтләре булганлыгын, аларның шул сәбәпле буялган булуын әйтәләр иде. Миңа икенче китап бик ошады. Аның уртарак бер өлешендә боздә дә бик яратып җырлана торган җыр сүзләре һәм ике кулына мылтык тотып, атлыгып алга атлаучы матрос сурәте бар иде. Ул китапны элегрәк мин әни кулында да күргәләгән идем. Әнинең, шул китапны тотып, сәхнәдәш дуслары белән ниндидер бер бәйрәм көнендә җырлаганнарын да хәтерлим. «Матрос Железняк җыры» иде ул. (Ул җырның татарча варианты авторы шагыйрь Шәйхи Маннур икәнлеген Казанга килгәч кенә белдем). Менә шул китапны инде мин булачак китапханәләремнең нигезе дип кабул итәм. Аны мин бик озак сакладым. Ә 1945 елда, сугыш тәмамланган җәйдә, безнең күршебез, математикадан укытучы Зәкия апа һәм әнисе авылдан китәргә булдылар. Күрше әбинең исемен инде хәтерләмим. Хәер, авыл халкының күпчелеге аны «Мәскәү әби» дип кенә йөртә иде шул. Күбрәк аралашкан күршеләр буларактыр инде, менә шул әби белән кызы безгә ике зур бәйләм китап кертеп калдырдылар. Шулар арасында латинча һәм яңача язулы татар китаплары күпчелек булып, русча язылганнары да бар иде. Русча китаплар арасында Аркадий Гайдарның нәкъ сугыш вакыйгаларына кагылышлылары да берничә иде. Без, малайлар, аларны алмаша-алмаша укыдык. Латинча язулылары арасында М. Горький томнары да ишле генә иде. Шул җәйдән соң килгән кышта исә, берничә сыйныфташ бергә җыелып, Лев Толстойның татарча латин хәрефендә нәшер ителгән «Хаҗи Морад» романын укып чыккан идек. Ул романны кайчандыр Афзал ага Шамов тәрҗемә иткән булган. Укытучы Зәкияападан калган китаплар безнең өйдә үскән биш малай өчен зур хәзинә булды. Киләчәктә безгә «китап җене кагылу» шушы вакыйгага да бәйледер, мөгаен.

Казанга килеп төпләнгәч тә мин китап туплый башладым. Ул китаплар арасында әдәбие дә, тарихие да бар, әлбәттә. Сарьяннар өендәге бер очрашуга Нурихан Фәттах Чыңгыз хан чоры тасвирланган «Сокровенное сказание» китабын тотып килгән иде. Мәскәүдә, Фәннәр академиясе тарафыннан нәшер ителгән китап. Шул вакыйгадан соң мин дә Мәскәүдә булган саен берәр төрле тарихи китапны алып кайтырга тырыша башладым. Ә эчтәлеге белән

«Сокровенное сказания»гә тартым «Мэн да бэйлу» китабы исә, 1965 елда бугай, Казан кибетендә дә сатылды. (Бүген генә аны кемгә биргәнемне хәтерләмим).

Соңгы елларда инде өйдәге шкафларга сыймый башлаган китапларны өләшергә кирәклеге турында да уйланырга туры килә. Берничә ел элек берничә йөз китапны Бөтендөнья татар конгрессы идарәсенә дә тәкъдим иттем. Аннан Миләүшә ханым Гомәрова берничә кеше белән килеп, рәхмәтләр әйтеп, «Без аларны башка өлкәләргә таратачакбыз», – дип, алып китте. Башкорт, казакъ, каракалпак, үзбәк, төрекмән, чуаш, мари һ. б. телләрдәге яисә шул телләрдән тәрҗемә ителгән йөзләп китапны да бер оешма берничә ел элек төяп киткән иде. Төрле телләрдәге дистәләгән басма булган һәм шулай ук татарча, русча ике йөзгә якын китаптан торган тупланманы быел менә бик рәхәтләнеп Халыклар дуслыгы йортына тапшырдык. Үзләре килеп, рәхмәтләр әйтеп алып киттеләр. Безнең гаилә моңа бик шат. Төрле милләт вәкилләрен бергә туплап, берләштереп торган оешма белән киләчәктә дә араны өзмәскә ниятлибез.

Авылларга кайтканда да берничә бәйләм китапны үзебез белән алырга тырышабыз. Татарстаннан читтәге авылларга хәзер татар телендәге китаплар кайтмый диярлек. Минем яшүсмер чорым Оренбург өлкәсенең көнчыгышрак өлешендә үтте. Әмма 1957 елгы «Хрущев чоры» указы чыкканчы безнең төбәктәге татар авылларына даими рәвештә дәреслекләр дә, әдәби-тарихи китаплар да Казаннан килеп тора иде. Мәсәлән, Һади Такташның ил өчен иң хәтәр вакыт саналган 1942 елда нәшер ителгән китабы безнең тирәдәге җидесигез татар авылының барысына да бер вакыттарак килде. Күрше авыл яшьләре белән очрашканда без Такташның ул китабын еш искә ала идек.

СССР Югары Советының 1957 елгы беренче чакырылышында «Милли республикалардан читтә урнашкан милли мәктәпләр язмышын ата-аналар хәл итәчәк», – дигән карар кабул ителә. Шул карар чыгу белән үк өлкә мәгариф оешмаларындагы милли мәктәпләр белән эш итүче кадрлар эштән җибәрелә. Бер-бер артлы милли мәктәпләр, ул мәктәпләр өчен укытучылар әзерләүче уку йортлары ябыла башлый. Карар чыгып өч ел үтмәстән Оренбург өлкәсендәге ике милли педагогия училищесы, татар-башкорт мәктәпләре өчен укытучылар әзерләүче Учительский институт, Оренбург һәм Орск шәһәрләрендәге пединститутларның татар-башкорт бүлекләре ябылды. Шундый ук хәл Куйбышев, Ульяновск өлкәләрендә дә кабатланды. Казан университетын тәмамлап, Төмән, Тобол шәһәрләрендәге югары уку йортларына укытырга җибәрелгән Азат Әхмәдуллин, Фәрит Хатипов һ. б. , уку йортлары ябылу сәбәпле, эш эзләргә мәҗбүр булдылар. Бу вакыйганы кайбер Татарстан галимнәре исә Сталин чорына нисбәтләп, Сталин «өстенә» аударырга да тырышты. Шулар арасында әлеге Югары Совет утырышында катнашкан ике-өч дистә депутатны – «үз кешеләрен» якларга тырышучылар да булды бугай. Кабат 1980–1990 нчы еллар матбугатын күздән кичерсән, шундыйрак эчтәлектәге язуларга да тап булачаксың. ■

*Автор статьи писатель, лауреат Государственной премии им. Г. Тукая Республики Татарстан Лирон Хамидуллин на примере татарской книги размышляет о перипетиях истории татарского народа, его культуры и письменности. Татары издревле отличались книжностью, стремлением к грамоте и просвещению. Недаром, как пишет Л. Хамидуллин, в деревне, откуда родом его отец и он сам, в то время было пять мечетей, два медресе и три начальные школы.*

*В основе его воспоминаний лежит история формирования личной библиотеки писателя, описанная автором в книге «Мои воспоминания» (2007). Как утверждает сам автор, её начало было положено ещё в детстве. Помог случай. В связи с реформой татарской графики в 1939–1940 гг. многие «устаревшие» татарские книги привозились в качестве макулатуры на переработку на местную картонную фабрику. Рабочие, видимо, чтобы порадовать местную детвору, подкидывали им эти книги. Так в руки маленькому Лирону попали первые татарские книжки.*

*Через несколько лет его ждал ещё один подарок. Соседи, решившие переехать в Москву, оставили им целую стопку книг, где были сочинения на татарском и русском языках, среди которых автору запомнились книги Аркадия Гайдара и Льва Толстого. Личная библиотека росла, прирастая новыми книгами…*

*Страсть к библиофильству не прервалась и после переезда Лирона Хамидуллина в Казань. В книжной коллекции появились исторические сочинения, произведения художественной литературы и др. Немало книг было привезено из Москвы.*

*В последние годы коллекционер активно передаёт свои книги в библиотеки различных учреждений, среди которых была и библиотека Всемирного конгресса татар. Среди изданий – книги на башкирском, казахском, каракалпакском, узбекском, туркменском, чувашском, марийском и других языках, а также переводы оригинальной литературы на татарский и русский языки. Автор уверен, что книги из его личной библиотеки ещё послужат татарскому народу…*

***Раиф Мәрданов,***
*Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең*
*редакция-нәшрият бүлеге баш китапханәчесе*



# Сугыш хатлары

Бөек Ватан сугышы чорында яуларда катнашкан һәм каһарманнарча көрәшеп, гомерләрен халык бәхете өчен корбан иткән күпсанлы хәрбиләрнең, тылдагы хезмәт ияләренең фидакярлекләре төрле документаль чыганакларда сакланып калган. Шундыйлардан фронт хатлары дәһшәтле заманның хәл-халәтен һәм эчке рухын ачып бирүгә, тагын да тирәнрәк төшенүгә ярдәм итә.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә тупланган Бөек Ватан сугышы чоры истәлекләре – фронтовиклар язган хатларны Җиңүнең 75 еллыгында искә алып китү изге бурычыбыз.

Китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган йөзләрчә хатның күпчелеге гарәп хәрефләре белән теркәлгән. Хатларның гомуми саклanыш дәрәҗәсе уртача һәм еш кына начар хәлдә дияргә мөмкин. Һәлак булучының бердәнбер истәлеге буларак, күп мәртәбә укылганга һәм сугыш вакыты кәгазьләренең түбән сыйфатына күрә, ул заман хатлары табигый сәбәптән тузган һәм таушалган. Аларның бөтенесе дә фронтның алгы сызыгыннан язылмаган һәм андый хәл мөмкин дә булмаган. Чөнки алгы сафтагы канкойгыч бәрелешләр вакытында (мәсәлән, Сталинградта) ут эчендәге сугышчыларның гомере берничә тәүлек белән чикләнгән. Хатлар сугышка дип алынгач, Казан шәһәрендә, Бөгелмәдә, Үзбәкстанда, Саратов өлкәсендә һәм башка урыннарда хәрби хәзерлек үткән лагерьлардан, сугышка барганда эшелоннан, фронтның алгы сафыннан – Мәскәү белән Смоленск тирәләреннән, Ленинград яныннан, Украинадан, Финляндия чигеннән, Польшадан, Венгриядән, Германиядән, партизан отрядыннан язылганнар. Шулай ук, сугышта яраланганнан соң Вологда өлкәсендәге, Иваново, Пермь, Оренбург һәм башка шәһәрләрдәге госпитальләрдән, әсирлектән соң Донбасс шахтасында мәҗбүри эш урыныннан җибәрелгәннәре дә бар.

Дәһшәтле яуларда катнашып, сугыш кырларында һәлак булган һәм авыр яралар алып булса да, әйләнеп кайту бәхетенә ирешкән хат авторлары хәзерге Татарстанда һәм күрше өлкәләрдәге татарлар яшәгән урыннарда туып-үскән кешеләр. Мәсәлән, Миңнулла Хәлиуллин (1910–1943), Хәбибрахман Яппаров (1914–1994) һәм Нурулла Хәбибуллин (1900–1979) – Татарстанның Арча районы; Гали Җәләев

(1906–1942) һәм Зиннәт Бәдриев (1919–1945) – Теләче районы; Әхәт Фәйзрахманов (1913–1942) – Балтач районы; Әмирҗан Шакиров (1921–1997) – Баулы районы; Миңнехан Миндубаев (1901–1945) – Мамадыш районы; Габделхак Балтин (1905–1946), Шиһабетдин Гайнетдинов (1912–1944) – Әгерҗе районы; Мифтах Шакиров (1908–1943) – Лаеш районы; Гатуф Дәүләтгәрәев (1903–1943) – Тукай районы; Мирза Тарханов (1897–1984) – Мենделеев районы; Габдерәүф Урапин (1909–1945), Әхмәтсафа Мамин – Ульяновск өлкәсе; Абдуллаҗан Шәйхетдинов (1911–1944) – Самара өлкәсе; Рәүф Тәхаветдинов – Башкортстан, аның хатына өстәп язган Нурмөкамбәт Бикбаев – Оренбург өлкәсе; Габделхак Урапин (1916–1945) – Пенза шәһәре кешеләре. Аерым авторларның хатлары берәр генә түгел, кайберләренеке (мәсәлән, М. Хәлиуллин һәм Г. Җәләевнең) дистәләрчә данә булуы белән дә әһәмиятле.

Хатларның кайберләренә мөрәҗәгать итик. Мәсәлән, Абдуллаҗан Шәйхетдинов үзенең соңгы хатында мондый юллар язган: «өченче линиядә торабыз сәгать-минут көтеп. Аллаһы Тәгалә ни язган – күрмичә чара юк. Сугыш каты бара». Аның һәлак булуы турында иптәше һәм командиры исеменнән язылган, гаиләсенә җибәрелгән хатта: «Шәйхетдинев раный булды, ягъни уң кулбашына тиде. Шуннан аны (кулын) бәйләп, үзенең окобына төшеп утырды. Көннәр утыргач, кичкә таба иптәшем Шәйхетдинев безнең арадан югалды, ягъни үзенең утырган окобына эснәрәд төшеп, шулай булды. Иптәшем Шәйхетдинев хәзерге көндә безнең арада юк инде. Ягъни, без аны бик яхшы итеп күмдек, апа. Һәм үзебезчә, командир һәм мин... Сезгә бу да мәгълүм булсын: аның окопта язып калдырган шигыре дә бар. Мин аны шушы үземнең Сезгә язган хатым эченә тыгып җибәрдем...Мин үзем бу хатны язган көнне исәнме әле, Алла безгә дә ни язгандыр?», «Мин командир, бу хатка кулым куеп утырам. Апай, без дә Алладан ким...Алда ни була – белмибез. Алла үзе ярдәмче булсын!»

Совет бәйрәмнәре уңаеннан сугышчыларга, котлаулар белән бергә, кайвакытларда тылдан җибәрелгән күчтәнәчләр дә ирешкән. Кайбер хатларда андый очраклар да чагылган: «Казан бөтенләй онытып бетерми әле, Октябрь празнигенә падаркы җибәргән. Өйдән күчтәнәчләр алып ашаган күк тиеп киттек», «Менә без бүген 1 нче май бәйрәм итәбез һәм дә рабочийлардан посылкә алдым: бер кило ярым чамасы прәник, тәмәке, кәнпут һәм сары май. Шулай итеп бәйрәм көне берничә кешене бүләкләделәр». Окопта ятканда да балаларын бер минутка да исләреннән чыгармаган аталары фронтта үзләренә бирелгән күчтәнәчтән газизләренә дә өлеш чыгарырга тырышканнар. Мәсәлән, «Менә, Сәидә, әгәр барса, малайларга ун-унбишләп кенә җимеш тыгам хат эченә. Малайларга «Атагыз җибәргән» дигән булып, бирерсез. Безгә бүләк биргәннәр иде, шуны балаларга авыз иттерәсем килеп кенә тыгам. Мин хатлар язып ятып, Зәбикъ аны җепкә тезеп утырды. Аңар да хат яздык, ул да шулай берничәләп кенә җимеш тыга».



Хатларның берсе Җиңү көнендә – 1945 елның 9 маенда язылган. Шатлыклы көндә Габделхак Балтинның гаиләсенә язган хатта мондый юллар бар: «Менә бүген, дөресендә кичә, төнге 12 сәгатьтә бөтен җир йөзенә радио хәбәр бирде: безнең рәхәт тормышны бозучы дошман һәм бөтен Европа халкын үзенә кол итәргә теләгән, шәһәрләрне яндырган, авылларны яндырган, картларны-карчыкларны, балаларны аткан-үтергән дошман Кызыл Армия алдында үзенең җиңелүен Советлар Союзына белгертеп, бөтен коралын Кызыл Армиягә тапшырырга сүз бирде. Сугыш бүгенге көннән фашистик Германиясе берләнбетте. Без бүген һәм сез, бөтен җир йөзендә иркенлекне сөюче халык-


Газиз у... ...дәр.
Сезгә бик к... ...рынып сәламсиңа.
Күп сәлам ук... Әбие..., Әниеңә.
һәм Сәләм... ...нә һәм
Висмәгә, һәм Фәнүргә.
Сәламәт Равылга, Хатирәгә, Мин-
нуллага, Сәмигуллага Фирдәүсгә
Тагын сәлам әйтерсең Гөмәр
абыеңа Галимәапаңа һәм Минсылу
апаңа. Үзем исән-сау улым
дошманны яхшыгына кыйнадым.
Безнең җирдән бераз куаладык һәм
һаман куылыйлар. Мин үзем әзрәк
яраландым сул кулымны белләзектән.
Әле ятам гуспитальда. Тиздән
савыгам инде. Мин дошман
белән корәштә алдан барам от-
личнa. Синдә тырышып укы.
Укытучылар сүзен тыңла өйгә
биргән эшләрне эшләп килс. Тың-
нап утыра кур. Ясме, Шулай ук
Әбиең белән Әниең сүзен тыңла
Рәмзәне Фәритне Фәнүрны кара
кыйнама.
Мин сиңа шушы хат белән
2 перо җибәрдәм алар сандугач
бик саклап кына яз Китапларың-
ны дәфтәрләреңне саклап тот.
Дәфтәрең булмаса Гөмәр абыең-
нан сора әти сорагон диген
ул сиңа бирер.

лар зур бәйрәм итәләр. Менә без бүген төнге сәгать 12-дән бирле йоклый алмадык. Бу көнне без дүрт ел көттек һәм дошман берлән көрәштек. Юлбашчыбыз иптәш Сталин безне бу көнгә ирештерде. Тиз көннән сугыш берлән уалган-җимерелгән халык хуҗалыгын төзәргә кайтырбыз. Бу инде тиз көннән булыр. Кайгырмый, тыныч рәвештә минем кайтуны көтегез. Бу көн озак түгел».

Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм һәлак булган кешеләрнең дәһшәтле елларда язылган хатлары – кыйммәтле тарихи истәлек. Фронтта ятып калган кайберәүләрнең фоторәсемнәре сакланмаса да, күңел-бәгырьләреннән саркып чыккан садә хатлары – хәзергәчә килеп ирешкән һәм гаиләләрендә, якын туганнарында кадерләп сакланган ядкәрләр. Аларда авторларының уй-фикерләре, теләкләре һәм кичерешләре, хисләре һәм тойгылары ачык чагылган.

* * *

Сугыш хатлары уңаеннан кайбер күзәтүләребез белән уртаклашыйк. Элеккерәк археографик экспедицияләр вакытында Бөек Ватан сугышы чорындагы хатларны кешеләр үзләре риза булып һәм теләп биргән очракларда гына ала идек. Чынлыкта, фронт хатларын туплау максаты куелмый да иде. Чөнки әле XX гасыр ахыры һәм XXI гасыр башында фронтовикларның хатыннары исән һәм алар, гадәттә, ирләренең бердәнбер истәлеге булган кадерле әйберләрен чит кулларга яки дәүләт оешмасына бирәселәре килми иде. Шундый караш хөкем сөргән белгәнгә күрә, археографлар да олы яшьтәге апаларның йөрәкләрендәге иң авыр җәрәхәтләрен кузгатырга базмады. (Хәзер, әлбәттә, буыннар алмашуга һәм дөньяви кыйммәтләр белән гомуми карашлар үзгәрүгә бәйле рәвештә, вазгыять үзгәрде. Бабаларының ядкәрен кемнәрдер кадерләп саклавы белән беррәттән, бөтенләй санга сукмаучылар да бар). Әйтелгән сәбәпләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Милли китапханәсендәге Бөек Ватан сугышы чоры хатларының да иң элеккеләре 1996 елда алынган



булып, башкалары бары тик 2001, 2003, 2013, 2016–2020 елларда гына тупланды.

Үземнең 35 еллык археографик тәҗрибәмдә сугыш чоры хатларына бәйле кайбер күзәтүләрем белән бергә, шәхси тәэсирләремне уртаклашып китү дә мәсьәләнең элекке торышын аңларга ярдәм итәр. 1980–1990 нчы елларда археографик сәфәрләр вакытында гарәп хәрефле борынгы язма истәлекләр эзләп һәм туплап өйдән-өйгә йөргәндә бик еш кабатланган бер күренеш хәтергә уелган. Каурый каләм белән язылган кульязма китапларны тапшыргач, еш кына хуҗабикә аерым төенчеккә чорналган тагын бер төргәкне күкрәгенә кысып алып килә. Гүяки, җанлы кош баласын тоткандай, орынып авырттырудан курыккан кебек, җиңелчә калтыранган бармаклары белән бик сак кына сүтә-сүтә, гарәп хәрефләре белән язылган булса да, боларын бирмәячәген искәртеп куя. Чөнки анда яудан кайтмый калган иренең (әтисенең яки абыйсының) сугыш хатлары. Йөзләрчә мәртәбә укылудан тузып-таушалып беткән хатлар бу апалар өчен дөньядагы бөтен нәрсәдән дә кадерле, иң газиз кешеләре белән тоташтырып торган хәсрәтле һәм, шул ук вакытта, якты истәлекләре белән сагындырган күңел юанычы. Әлбәттә, шул хатларны күрсәткән кеше – иренең (әтисенең яки абыйсының) бердәнбер истәлеге булганга, хисләре ихтыярсыз яңарып, күзләре мөлдерәмә тула, тәгәрәшкән яшьләрен тыя алмый. Шул вакытка инде мәрхүм яисә мәрхүмә булган әтисе яки әнисенең соңгы көненә кадәр улларын көтеп, ачы хәсрәттә гомер кичерүләрен дә искә алып куя. Кайчагында үзләре хатларның аерым өлешләрен йөгерек кенә итеп укып та күрсәтәләр. Ә гарәп язуын танымасалар, укып карар өчен бирәләр дә, хат текстындагы ятрак сүзгә яки исем-атаманы укый алмыйча мизгелгә генә тоткарлансаң да, шунда ук әйтеп җибәрәләр. Укыганда еш кына телдән кабатлап торалар – чөнки әлеге хатларда язылган һәр сүзне алар яттан белә. Кешенең фаҗигале һәм шул ук вакытта мөкатдәс ядкәрен сорап алып китәргә, әлбәттә, вөҗдан рөхсәт итми иде.

*В отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан хранятся письма фронтовиков Великой Отечественной войны, большинство которых написаны арабской графикой.*

*Авторами писем являются уроженцы Агрызского, Актанышского, Арского, Бавлинского, Балтасинского, Лаишевского, Мамадышского, Менделеевского, Тукаевского и Тюлячинского районов Республики Татарстан, также выходцы из Башкортостана, Самарской и Ульяновской областей и др.*

*Письма фронтовиков-татар охватывают широкую географию боевых действий: это Подмосковье, Смоленск, Ленинград, Украина, Финляндская граница, Польша, Венгрия, Германия. Есть одно письмо из партизанского отряда, письма шли также из госпиталей Иванова, Перми, Оренбурга и др.*

*Авторами многих писем являются М. Халиуллин (25 писем) и Г. Заляев (24 письма), а другие представлены одним или несколькими письмами.*

*В одном из писем сослуживец и командир А. Шайхутдинова сообщают его супруге о последних часах жизни и гибели солдата.*

*Письмо Г. Балтина датировано 9 мая 1945 года – Днём Великой Победы.*

*Ильяс МӨСТӘКЫЙМОВ,*
*Татарстан Милли китапханәсе кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты*

# «Әхмәт мирза кире кайткан, ислам динен сагынып»

## РЕВОЛЮЦИЯГӘ КАДӘР БУЛГАН ВАКЫЙГА ТУРЫНДА БӘЕТ

Язучыбыз Рабит Батулла тарафыннан 2020 елда Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә күренекле татар драматургы һәм театр эшлеклесе Кәрим Тинчуринның җәмәгате Заһидә ханым Тинчурина (1897–1988) архивының сакланып калган өлеше тапшырылды. Ул тупланма Кәрим Тинчурин кульъязмаларыннан, Кәрим Гали улына һәм Заһидә Шаһбазгәрәй кызына төрле кешеләр тарафыннан язылган хатлардан, «Кызыл дөнья» һәм «Юксыллар сүзе» газеталарының аерым саннарыннан һәм башка язма чыганаклардан гыйбарәт.

Шулар арасында – Әхмәт мирза исемле затның, рус кызына гашыйк булып, мөселман диненнән язганы турындагы бәет кульъязмасы. Кәгазьнең баш өлеше ертык булганга, бәетнең исеме сакланмаган. Аңа шартлы рәвештә «Диннән язган Әхмәт мирза бәете» дигән исем бирдек. Текстның башлам өлеше дефектлы булуына карамастан, аерым сүзләрдә сакланып калмаган хәрефләр чагыштырмача җиңел чамалана.



Бәет вакыт үтү белән саргылт төскә кергән 21,5х26,5 см зурлыгындагы яхшы сыйфатлы ак кәгазьгә шәмәхә төстәге кара белән язылган. Монда сүз барган вакыйганың кайчан булганын әлегә ачыклап булмады. Контексттан чыгып, аның XIX йөзнең икенче яртысы – XX йөз башына караганлыгын фаразлыйбыз. Текстта очраган географик атамалар (Бүздәк, Чиркү Каран) бәеттә әйтелгән хәлләрнең хәзерге Башкортстан җирләрендә булганлыгына ишарәли.

Шакмак җәяләр ([]) эченә куелган фрагментлар кульязманың ертылганлыгы сәбәпле сакланмаган, алар безнең тарафтан өстәлде. Унөченче юлда җием (җим) сүзендә почмак җәяләр (<>) эченә куелган е фрагменты шигъри юлның аһәңлелеген (ритм һәм рифманы) саклап калу өчен куелганга охшый. Тексттагы тыныш билгеләре безнең тарафтан куелды.

## [Диннән язган Әхмәт мирза бәете]

Әхмәт [мир]за күк айгырын Котлыкай мирза атланган,
[Ә]хмәт динс[ез бо]зылганга бик күп дошман шатланган.
[Ә]хмәт мирза атлары парлап-парлап пар җирән,
[Т]уймас кебек җөргән идең, туйдыңмы инде, карт бирән?
[Ә]хмәт мирза юргасын су буенда куйганнар,
[Ә]хмәт мирза бозылгачтын янга керис куйганнар.
[Ә]хмәт мирза ындырында уникe кибән, бер зурат[1],
Бу бәетне әйтмәс өчен бикә бирә бер туры ат.
Гөлсем бикә чия җыя көмеш тәлинкәсендә,
Гөлсем бикә җавап бирә Бүздәк ярминкәсендә.
Гөлсем бикә тышка чыккан калын шәлен ябынып,
Әхмәт мирза кире кайткан, ислам динен сагынып.
Гөлсем бикә җи<е>м сибә өем-өем казларга,
Әхмәт динсез малы калган Габит ише тазларга.
Әхмәт мирза силниге, силнигендә шүрлеге,
Әхмәт диннән язмас иде, бар да марҗа ширлеге.
Чиркү Каран буенда куш буразна сызылган,
Башкортларның яше төшеп Әхмәт диннән бозылган.
Әхмәт мирза басуында уңган икән арышлар,
Әхмәт диннән чыкмас иде, төшкән икән каргышлар.
Әхмәт мирза келәтенең тау җагына ишеге,
Әхмәт, диннән бозылгач, булган марҗа диншиге.

[1] Сүзнең укылышында шөбһә бар.

**Сүзлекчә**

*Диншик (рус. денщик)* – хезмәтче

*Зурат (рус. зарод)* – басуда ашлык көлтәләреннән ясалган озынча зур өем; печән кибәне

*Керис (рус. крест)* – тәре

*Силник (рус. сенник)* – печән лапасы

*Ширлек* – шуклык, чаялык, чытлык

*Среди переданных народным писателем Татарстана Р. Батуллой Национальной библиотеке Республики Татарстан материалов личного архива Загиды Тинчуриной – супруги драматурга Карима Тинчурина – имеется список баита (эпического стихотворного рассказа) второй половины XIX – начала XX в. о некоем мурзе Ахмеде, отпавшем от ислама, чтобы соединиться с возлюбленной. По всей вероятности, баит основан на реальном событии. Произведение исполнено тонкой иронией и написано весьма богатым языком.*

***Эльвира ХУСАИНОВА,***
*главный библиотекарь*
*научно-методического отдела*
*Национальной библиотеки*
*Республики Татарстан*

# Структура чтения пользователей библиотек Татарстана

В 2019 году Национальной библиотекой Республики Татарстан проведено социологическое исследование «Что читают сегодня пользователи муниципальных библиотек Татарстана». Этой работе предшествовала серия исследований, проведённых в период с 2016 по 2018 годы, в ходе которых была получена модель чтения пользователей муниципальных библиотек республики. Однако возник вопрос: не является ли полученная модель во многом представлением читателей о том, каким должно быть чтение? И насколько эта модель отличается от реального чтения респондентов?

Поэтому основной целью социологического исследования «Что читают сегодня пользователи муниципальных библиотек Татарстана» стало изучение реального чтения пользователей библиотек как основы оптимизации обслуживания в библиотеках республики.

Базами исследования стали 13 ЦБС, принимавших участие в изучении чтения в республике в 2016–2018 годах. В их числе библиотеки Алексеевского, Верхнеуслонского, Кайбицкого, Камско-Устьинского, Кукморского, Муслюмовского Сармановского и Спасского муниципальных районов республики, а также городов Бугульма, Казань, Лениногорск, Набережные Челны, Чистополь.

Основной вывод, сделанный по результатам исследования, заключается в том, что полученная ранее модель чтения, основанная больше на субъективном мнении респондентов, в целом соответствует объективной структуре чтения пользователей библиотек республики. В то же время, выявлены некоторые несоответствия между заявленным и реальным чтением респондентов.

Анализ всех читаемых респондентами в апреле 2019 года книг позволяет представить структуру чтения пользователей муниципальных библиотек Татарстана в этот период. Из 1473 участников исследования читали:

35% татарскую литературу,

17% – современную русскую литературу,

15% – зарубежную литературу,

9% – литературу советского периода

8% – отраслевую литературу,

6% – русскую классическую литературу,

5% – произведения писателей татарской национальности, пишущих на русском языке (диаграмма 1).




*Диаграмма 1*




*Диаграмма 2*

Подавляющее большинство участников исследования – 92% – читали произведения художественной литературы, и лишь 8% – отраслевую литературу.

Баланс чтения татарской (в т. ч. в переводе на русский язык) и русской литературы примерно одинаков. Чтение татарской художественной литературы рассматривалось в обобщённом виде, включая чтение произведений современных писателей, писателей прошлых лет и классиков татарской литературы (в целом 35%). Чтение русской художественной литературы анализировалось по периодам, включающим чтение произведений классиков, писателей советского времени и современности. В общей сложности эту литературу читали 33% от числа всех участников исследования. В отдельную группу было выделено чтение произведений авторов татарской национальности, пишущих на русском языке (5%).

Очевиден первоочередной интерес респондентов к чтению произведений современных авторов. Особенной популярностью пользуются произведения современных татарских писателей, что неоднократно подчёркивалось в ходе всех предыдущих исследований чтения. В период проведения исследования 2019-го года современную татарскую литературу читали 70% от числа респондентов в этом сегменте. В сегменте литературы писателей татарской национальности, пишущих на русском языке, произведения современных авторов читали 94% респондентов. В сегменте русской литературы в процессе чтения произведений современных авторов находился 51% респондентов, в сегменте зарубежной литературы – 49%.

В общей сложности современную литературу читали 53% от числа всех участников исследования (диаграмма 2) и 61% от числа всех читателей художественной литературы.

Наиболее популярными жанрами литературы среди пользователей муниципальных библиотек республики являются детектив, проза, любовный роман, фантастика. Например, детектив стал самым читаемым жанром в сегменте современной русской литературы, проза – в сегментах татарской литературы, литературы советского периода и зарубежной литературы.

Реальное чтение респондентов не подтвердило приоритет русской классической литературы, декларировавшийся участниками предыдущих исследований чтения (2016–2018 гг.). Лишь 6% от общего числа респондентов в период проведения исследования читали произведения классиков русской литературы. Основным мотивом при этом называлось выполнение учебной программы.

Интерес к классике невелик во всех изучаемых сегментах. Если в сегменте русской литературы это 20% респондентов, то в сегменте татарской литературы всего лишь 2%, а в сегменте зарубежной – 14%. В общей сложности классическую литературу читали 9% от общего числа участников исследования (диаграмма 3) и 10% от




*Диаграмма 3*




*Диаграмма 4*

числа читателей художественной литературы.

Ещё одной тенденцией в репертуаре чтения респондентов является большой процент числа художественных произведений, написанных авторами-женщинами. Самой популярной книгой в муниципальных библиотеках Татарстана в апреле 2019 года был роман Гузель Яхиной «Зулейха открывает глаза», самым популярным автором – современная татарская писательница Зифа Кадырова.

В целом 39% респондентов от общего числа участников исследования читали произведения художественной литературы, написанные авторами-женщинами. Это 44% от числа всех читателей художественной литературы.

Впервые за время изучения чтения Национальной библиотекой Республики Татарстан в круг рассматриваемых тем включено изучение чтения отраслевой литературы. В период проведения исследования её читали 8% от общего числа респондентов. Наибольшей популярностью пользовались книги по психологии, истории, педагогике, медицине и искусству. Большая часть читавшейся отраслевой литературы – учебники, справочные издания, научная и научно-популярная литература (диаграмма 4).

Основным мотивом чтения большинство респондентов по-прежнему называют отдых и развлечение. Также подтверждена верность изучаемого контингента традиционным изданиям на бумажном носителе.

Подтвердились и языковые предпочтения пользователей библиотек. Если по итогам предыдущих исследований чтение на русском языке было предпочтительно для 60% участников исследования, то в режиме реального времени читали книги на русском языке 63% респондентов. Кроме того, в период проведения исследования 2019-го года книги на татарском языке читали 33% респондентов, что также укладывается в рамки предыдущих исследований.

Не вызывает сомнений и достойное место библиотеки в ряду информационных, культурно-образовательных учреждений. В целом у 60% респондентов спрос на читаемую книгу сформировался уже в стенах библиотеки, что ещё раз подтверждает значительную роль библиотеки в деле популяризации и продвижения книги.

В данном контексте большая ответственность ложится на плечи библиотекарей, от компетентности и уровня культуры которых во многом зависит репертуар чтения пользователей библиотек.

■

*2019 елда Татарстан Республикасы Милли китапханәсе тарафыннан «Татарстанның муниципаль китапханәләреннән файдаланучылар нәрсә укый?» дигән социологик тикшеренү уздырылды.*

*Сораштырудан күренгәнчә, укучыларны хәзерге заман авторларының әсәрләре күбрәк җәлеп итә. Катнашучыларның 70%-ы заманча әдәбият укыган.*

*Әдәби жанрларга килгәндә, детективлар, мәхәббәт романнары, фантастика – иң киң таралганнары. Рус әдәбиятында детектив жанры күп укылган булса, татар әдәбиятында – совет чоры прозасы. Шулай ук чит тел әдәбияты да популяр.*

*Укучылар арасында классик әдәбият белән кызыксыну 9% кына тәшкил итә.*

*Мисал өчен бер кызыклы мәгълүмат: 2019 елның апрель аенда иң күп укылган китап – Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» романы, иң яратып укылган автор – татар язучысы Зифа Кадыйрова.*

*Психология, тарих, педагогика, сәнгать һәм медицина буенча китаплар, дәреслекләр, белешмәлекләр, фәнни-популяр әдәбият еш укыла торганнар рәтендә.*

***Наиля КЛДРОВА,***
*ведущий библиотекарь*
*Национальной библиотеки*
*Республики Татарстан*

# Как организовать фандрайзинговую кампанию

## из опыта работы

ПРИВЛЕЧЕНИЕ внебюджетных средств в деятельность библиотек по-прежнему остаётся актуальной проблемой, решением которой может стать фандрайзинговая кампания (фандрайзинг – работа по привлечению денежных средств граждан, бизнеса или государства в некоммерческий сектор, в том числе на благотворительность), требующая многоаспектной подготовки.

Один из аспектов подготовки к данной деятельности – психологический настрой: человеку, привыкшему добиваться всего самостоятельно, не прибегая к посторонней помощи, будет сложно обращаться с какими бы то ни было просьбами, тем более просить деньги, даже на благо библиотеки. Чтобы психологически справиться с этой проблемой, не один раз придётся повторять себе: «Это очень нужно нашему дорогому читателю». Убедив себя – легче убедить потенциального спонсора.

Залогом успешности проведения акции станет пошаговая программа фандрайзинговой кампании, которую нужно держать под рукой и почаще в неё заглядывать. Поверьте, это помогает!




